**КАЗАН ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ**
**Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты**
**Г. Тукай исемендәге милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбе**
**Гомуми тел белеме һәм тюркология кафедрасы**

**Р.С. НУРМӨХӘММӘТОВА**

# ТЕЛ БЕЛЕМЕНӘ КЕРЕШ

**Уку-укыту ярдәмлеге**

**КАЗАН**
**2019**

**УДК 81(075.8)**
**ББК 81я73**
**Н90**

*Казан (Идел буе) федераль университетының*
*Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты*
*Укыту-методик советы*
*(18 ноябрь, 2019 ел, 3нче номерлы беркетмә)*
*гомуми тел белеме һәм тюркология кафедрасы утырышы*
*(13 ноябрь, 2019 ел, 6нчы номерлы беркетмә)*
*карары белән басыла*

**Фәнни мөхәррир**
филология фәннәре докторы, профессор **Р.Р. Җамалетдинов**

**Рецензентлар:**
филология фәннәре докторы, профессор **Ә.Ш. Юсупова** (КФУ);
филология фәннәре кандидаты, доцент **Л.Г. Гыйләҗева**
(Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты)

**Нурмөхәммәтова Р.С.**
**Н90** **Тел белеменә кереш**: уку-укыту ярдәмлеге / Р.С. Нурмөхәммәтова. – Казан: Казан университеты нәшрияты, 2019. – 120 б.

Әлеге уку-укыту ярдәмлеге югары уку йортларының педагогик белем, филология юнәлешләрендә белем алучы I курс студентларына тәкъдим ителә. Хезмәтнең максаты – студентларны тел турындагы теоретик мәгълүмат белән коралландыру, тел турындагы фәннең нигезләре белән таныштыру.

**УДК 81(075.8)**
**ББК 81я73**

**© Нурмөхәммәтова Р.С., 2019**
**© Казан университеты нәшрияты, 2019**

# КЕРЕШ

«Тел белеменә кереш» фәне – югары уку йортларында укытыла торган беренче лингвистик курс. Аның максаты – студентларга тел турындагы фәннең нигезләрен төшендерү. Шунлыктан ул беренче курста, беренче семестрда ук укытыла.

«Тел белеменә кереш» фәне буенча татар телендә басылган дәреслекләр күп түгел. Ф.С. Сафиуллинаның «Тел белеменә кереш» (2 кисәктә, 1987, 1988), «Тел гыйлеменә кереш» (2001) дәреслекләре, Ф.С. Сафиуллина, Х.Х. Сәлимов, Д.Ә. Сәлимова авторлар коллективы тарафыннан төзелгән «Тел гыйлеменә кереш» (2000) теоретик мәгълүматлар, күнегүләр һәм мәсьәләләр җыентыгы, Р.С. Нурмөхәммәтованың «Тел белеменә кереш» (2010) теоретик мәгълүматлар һәм телләр турында кызыклы мәгълүматларны туплап биргән дәреслек-кулланмасын атап үтәргә мөмкин. Бу фән буенча төп мәгълүматларны Р.Р. Җамалетдинов, Р.С. Нурмөхәммәтова авторлыгында эшләнгән «Тел белеме нигезләре» (2014) укыту әсбабыннан алырга була.

«Филология», «Педагогик белем» юнәлешләрендә татар телендә белем алучы студентлар өчен төзелгән әлеге уку-укыту әсбабы югары белем бирү стандартларына яраклаштырып эшләнде.

Тәкъдим ителә торган әсбап «Тел белеменә кереш» курсы программасы нигезендә төзелде. Ул әлеге фән кысаларында дәресләрдә каралачак фәнни материалны туплап бирүне күздә тота. Темалар укыту планында бирелгән лекцияләр санына туры китереп бүленде. Һәр лекциянең планы, кыскача теоретик материаллар, һәр тема ахырында сораулар биреп барылды. Ахырдан әдәбият исемлеге, электрон ресурслар күрсәтелде, фәнни терминнар сүзлеге китерелде.

Уку-укыту әсбабы студентларга һәм әлеге фәнне укытучыларга файдалы булыр дип уйлыйбыз.

# Тема: ТЕЛ ТУРЫНДАГЫ ФӘН БУЛАРАК ТЕЛ БЕЛЕМЕ, АНЫҢ БАШКА ФӘННӘР БЕЛӘН БӘЙЛӘНЕШЕ

1. Филологик фәннәр системасында тел белеменең урыны.
2. Тел белемен тәшкил итүче фәннәр турында мәгълүмат.
3. Тел белеменең аспектлары.
4. Тел белеменең башка фәннәр белән бәйләнеше.

## 1. Филологик фәннәр системасында тел белеменең урыны.

Тел кешеләрнең билгеле бер эшчәнлек төренә бәйле рәвештә кулланыла һәм үсә. Телнең кулланылышын һәм үсешен тулаем тикшерү, аның үсеш-яшәешенә шартлар тудыру белән ***филологик фәннәр*** шөгыльләнә. Филологик фәннәргә тел белеме һәм әдәбият белеменә караган гаять күп сандагы фәннәр керә, аларны гамәли, норматив, фундаменталь (нигез) фәннәргә аерып йөртәләр.

Барлыкка килү вакыты ягыннан караганда, ***гамәли филологик фәннәр*** борынгырак санала, чөнки бу фәннәр буенча белемнәр турыдан-туры кеше эшчәнлеге белән бәйле, аларның һәркайсы аерым бер төр текст булуны таләп итә. Болар: каллиграфия, орфоэпия, эш кәгазьләре башкару, архив эше, китапчылык белеме, телләргә өйрәтү методикасы һәм дидактикасы, тел семиотикасы, мәгълүмат хезмәте күрсәтү һ.б.

Телдән һәм язма сөйләмнең дөрес нормаларын билгели торган ***норматив филологик фәннәр*** (фонетика, грамматология, орфография, грамматика, лексикология, лексикография, риторика, поэтика, сөйләм әдәбе һ.б.) җәмгыятьтә кулланылышта йөргән барлык төр текстларны күздә тоталар: нормалар телне тулаем тасвирлый, ул аерым текст төренә бәйле була алмый.

***Фундаменталь филологик фәннәр*** иң соңгылары булып барлыкка килгән, алар турыдан-туры практикага барып тоташмый, әмма аңа булыша: фундаменталь тикшеренүләр норматив кагыйдәләрнең эшләнеше өчен база барлыкка китерәләр. Боларга чагыштырма тел белеме, чагыштырма-тарихи тел белеме, телләр типологиясе, әдәбият теориясе,

диалектология, әдәбият тарихы, тел тарихы, әдәби тел тарихы, матур әдәбият теле тарихы кебек фәннәр керә.

**2. Тел белемен тәшкил итүче фәннәр турында мәгълүмат.**

***Каллиграфия*** – язу тамгаларын (хәрефләрне) ачык, төгәл һәм матур язу турындагы фән. Ул иң борынгы фәннәрнең берсе. Каллиграфиягә өйрәтүнең максаты, бер яктан, стандарт язу, язуның җәмгыятькә хас стилен барлыкка китерү булса; икенче яктан, индивидуаль почерк, язуның шәхси стилен тудырудан гыйбарәт.

***Орфоэпия*** – дөрес һәм матур сөйләү турындагы фән. Кешенең сөйләменә карап аның мәдәни үсеше һәм укымышлылык дәрәҗәсе турында фикер йөртәләр.

***Методика*** педагогка ничек эшләргә, аңлату алымнарын һәм методларын ничек сайларга икәнлекне өйрәтә; ***дидактика*** өйрәтү тәҗрибәсенә нигезләнгән һәм аны камилләштерү юлларын күздә тоткан дәреслек, әсбап, хрестоматия һәм башка уку-укыту материаллары рәвешендә укыту предметын барлыкка китерүдән гыйбарәт.

***Тел семиотикасы*** телдән һәм язма сөйләмдә тел мәгънәсен чагылдыру ысулларын, яңа тамгаларының барлыкка килү тенденцияләрен өйрәнә. Кайчандыр барлыкка килгән язу тамгалары да үзгәрешсез тормый. Мисал өчен, XVIII гасырда формалашкан рус алфавиты шулкадәр стилистик үзгәрешләр кичергән ки, бүген хәтта күпме шрифт гарнитуралары[1] кулланылганын билгеләү дә мөмкин түгел. Яңа гарнитуралар текстка яңа матурлык бирү өчен уйлап табыла: төрле шрифт гарнитуралары белән басылган бер үк текстның эстетик эчтәлеге дә үзгәрә.

***Мәгълүмат хезмәте күрсәтү*** – мәдәният предметларын (“җимешләрен”) файдалану теориясе һәм практикасы турындагы фән. Мәгълүмат хезмәте күрсәтү системаларында теге яки бу текстның кайда булуы, аны ничек табу һәм абонентка ничек

[1] Гарнитура – французча “комплект” – басма тамгалар суммасы, аңа хәрефләрнең төрле зурлыклары (алар кегльләр белән үлчәнә), хәреф элементларының калынлыклары, туры һәм авыш (курсив) язу рәвешләре керә.

җиткерү юллары ачыклана. Китапханә каталогын иң гади мәгълүмат системасына мисал итеп китерергә мөмкин.

***Фонетика*** – телнең авазлар составын һәм аваз тезмәләрен өйрәнә торган норматив фән.

***Грамматология*** хәрефләрнең санын һәм формаларын, аларның авазларны белдерү өчен мөмкин булган тезмәләрен билгели. Аваз һәм хәрефләр арасында туры тәңгәллек юк, шунлыктан бер аваз белдерә торган хәрефләр төркеме һәм бер хәреф белән белдерелә торган авазлар төркеме билгеләнә.

***Грамматика*** сүзләрнең җөмләдә ярашу кагыйдәләреннән, шулай ук моңа бәйле рәвештә сүз формаларының үзгәреш кагыйдәләреннән гыйбарәт.

***Орфография*** язу нормалары һәм кагыйдәләре турындагы өйрәтмә, ул сүзләрне язганда алфавит хәрефләрен куллану кагыйдәләрен дә үз эченә ала.

***Лексикология*** – сүз турында өйрәтмә, аңа сүз һәм аларның мәгънәләре тарихы да (этимология) керә.

***Лексикография*** – сүзлекләр төзү турындагы фән. Сүзлекләрдән башка бер генә әдәби тел дә яши алмас иде. Лексикография сүзлекләр тарихын һәм типларын, телнең тулаем сүзлек байлыгын, тел һәм, гомумән, сөйләм әдәбе өчен сүзлекләрнең ролен өйрәнә.

***Сөйләм әдәбе*** – сөйләмдә тел элементларын урынлы куллану, телнең сүзлек байлыгыннан һәм грамматикадан дөрес файдалану турындагы фән. Ул шулай ук нормадан тайпылышларның кайсылары рөхсәт ителүен, кайсыларына юл куелмавын да билгели, стилистик нормалардагы үзгәрешләр динамикасын да күзәтә.

***Чагыштырма тел белеме*** грамматик тасвирламаларда һәм текстларда бирелгән ике (һәм күбрәк) телне чагыштырып өйрәнә. Телләрне чагыштыруның иң гади формасы – икетелле сүзлек, аларда бер тел сүзе икенче телнеке белән аңлатып бирелә. Шушы ук принциплар нигезендә чагыштырма грамматика, чагыштырма фонетика, чагыштырма фразеология һ.б. барлыкка килергә мөмкин.

Дөньяда билгеле булган барлык тел системалары ***типологик тел белеме*** (телләр типологиясе) предметын тәшкил итә һәм нәтиҗәләр барлык телләр өчен дә чыгарыла. Тикшеренүләр һәм

нәтиҗәләр телләрнең билгеле бер массивын өйрәнгәндә тулы булмаган индукция нигезендә чыгарыла, ә нәтиҗәләр башка барлык тел системаларына да таратыла.

***Чагыштырма-тарихи тел белеме*** (компаративистика) телләр арасындагы матди охшашлык билгеләрен ачыклау һәм тел үсеше проблемалары белән шөгыльләнә. Тел гаиләләре үзара генетик, ягъни мәдәни-тарихи мөнәсәбәтләрдә өйрәнелә һәм тасвирлана. Шул рәвешчә алынган белемнәр язусыз телләр үсешен һәм тел системаларының диалектларга таркалу нигезендә барлыкка килүен тикшерергә ярдәм итә.

***Диалектология*** – диалектларны, ягъни җирле сөйләшләрне, аларга хас тел үзенчәлекләрен өйрәнә торган фән. Телнең аерым бер төбәктә генә таралган төрен *диалект, җирле сөйләш* дип атыйлар. Мәсәлән, татар телендә өч диалект аерыла: урта, көнбатыш (мишәр) һәм көнчыгыш (себер татарлары) диалект. Шушы төбәккә генә хас булган сүзләрне *диалекталь сүзләр* дип, ә андагы әдәби телдән аермалы башка фонетик, грамматик аермалыкларны *диалекталь үзенчәлекләр* дип йөртәләр. Диалектология фәне әнә шуларны тикшерү белән шөгыльләнә.

**3. Тел белеменең аспектлары.**

Һәрбер фән үзенең өйрәнү объектын һәм предметын билгеләүдән башлана. Тел белемендә исә боларны тел, аның статикасы һәм динамикасы, үткәне һәм бүгенгесе тәшкил итә. ***Тел белеме*** – телләрне (шул исәптән аерым кеше телен дә, һәм, гомумән, кайчандыр яшәгән, хәзерге һәм кайчан да булса барлыкка килергә мөмкин булган телләрне дә) өйрәнә торган фән.

Тикшеренү максатларыннан чыгып, тел белеме ***теоретик*** һәм ***гамәли тел белеме*** дигән төрләргә аерыла.

Төрле телләрдәге аерымлык һәм гомумилек, шулай ук конкрет телләрдәге хосусыйлык ***теоретик тел белеме*** эчендә *гомуми* һәм *хосусый тел белемен* аеруга нигез булып тора.

***Гомуми тел белеме*** кеше теленең үзенчәлекләрен, телнең нигезен һәм табигатен, килеп чыгышын һәм үсешен өйрәнә, телне өйрәнү теориясен һәм методларын булдыру белән шөгыльләнә. Аны һәр телгә хас гомуми сыйфатларны бербөтен

буларак өйрәнә торган теория дип карау дөрес булыр. Гомуми тел белеме – телнең бер система буларак яшәвен һәм барлык телләр өчен дә уртак булган үзенчәлекләрне өйрәнүне күз алдында тоткан, тел белеменең катлаулы теоретик мәсьәләләрен үз эченә алган курс.

***Хосусый тел белеме*** аерым, яисә кардәш телләрне (славян, төрки телләр һ.б.) өйрәнү белән шөгыльләнә. Хосусый тел белеме *тасвири* (синхроник) булырга, ягъни тел фактларын теге яки бу тел тарихындагы конкрет бер чорга бәйле рәвештә тасвирларга мөмкин (күп очракта – бүгенге телләр), яисә *тарихи* (диахроник) була ала. Бу очракта инде телнең конкрет бер вакыт эчендәге үсеше күздә тотыла. Диахроник тел белемен еш кына чагыштырма-тарихи тел белеме белән тәңгәлләштереп карыйлар. Ул, тугандаш телләрне үзара чагыштырып, аларның тарихи үткәнен өйрәнә.

***Гамәли тел белеме*** тел кулланылышына бәйле булган гамәли мәсьәләләрне чишү белән шөгыльләнә. Ул аерым бер телгә караган проблемаларны да, барлык телләргә мөнәсәбәтле мәсьәләләрне дә тикшерә: чит телгә өйрәтү, алфавит уйлап табу, язуны камилләштерү, текстны ЭВМнар кулланып эшкәртү, транскрипция һәм стенография системалары төзү, сукырлар өчен язу уйлап табу, фәнни-техник терминологияне стандартлаштыру һ.б.

Телне өйрәнү аспектларына бәйле рәвештә рәвештә тел белемен **тышкы** һәм **эчке лингвистика**га да бүлеп карыйлар. Бу бүленеш телләрне өйрәнүдәге *эчке* (телнең төзелешен мөстәкыйль күренеш буларак тикшерү) һәм *тышкы* (экстралингвистик) аспектларга (тел үсешенең һәм яшәешенең тышкы шартларын, факторларын өйрәнү) нигезләнә.

***Тышкы лингвистика*** барыннан да бигрәк тел һәм җәмгыять бәйләнеше проблемалары, телнең җәмгыятьтәге функцияләре, телләрнең территориаль таралышы, халыкның теле һәм мәдәнияте мөнәсәбәтләре һ.б. бик күп проблемалар белән шөгыльләнә. Бу атама астына бик күп фәнни юнәлешләр берләшә – социолингвистика, лингвогеография, этнолингвистика, психолингвистика, лингвокультурология һ.б.

***Эчке лингвистика*** тел системасын һәм төзелешен мөстәкыйль күренеш буларак өйрәнә, ул тел белеменең күп

тармаклы өлкәләренә керә. Аның үз эчендә мөстәкыйль фәннәрне аерып чыгарырга мөмкин[2]: фонетика һәм фонология, лексикология һәм семасиология, морфология һәм синтаксис, сүз ясалышы.

## 4. Тел белеменең башка фәннәр белән бәйләнеше.

Кешелеккә мәгълүм булган барлык фәннәрне ике зур төркемгә бүлеп йөртәләр: иҗтимагый фәннәр һәм табигать фәннәре[3]. Табигать фәннәре табигать күренешләренең яшәү һәм үсү закончалыкларын өйрәнә. Аларга география, астрономия, зоология, ботаника, физика, математика һ.б. фәннәр керә. Иҗтимагый фәннәргә җәмгыять турындагы фәннәр, ягъни фәлсәфә, әдәбият, тарих, археография, этнография, психология, логика һ.б. фәннәр карый. Тел – иҗтимагый күренеш, димәк тел турындагы фән дә иҗтимагый фәннәр рәтенә керә. Иҗтимагый фән буларак тел белеменең тарих, икътисади география, психология, педагогика һ.б. фәннәр белән тыгыз бәйләнештә торуы аңлашыла. Гомумән алганда, тел белеме ике төркем фәннәр белән дә тыгыз бәйләнештә тора, аның әлеге фәннәргә мөнәсәбәте төрлечә. Мәсәлән, тел белеменең антропология белән бәйләнеше сөйләм барлыкка килү мәсьәләләре белән генә чикләнә, ә логика (мантыйк), психология, әдәбият белеме белән бәйләнешләр тирәнрәк. Тел белеменең башка фәннәр белән тыгыз мөнәсәбәттә торуы аның үзенчәлекле мөстәкыйль фән булуына шик тудырмый. Тел белеме фәне телне төрле яклап өйрәнә, ә башка фәннәр исә аны аерым бер яктан гына тикшерә.

Тел белеме һәм әдәбият белеме чигендә ***поэтика*** – сәнгатьле сөйләм нормалары, язучыларның сәнгать стильләре үзенчәлекләре, язучылар куллана торган сурәтләү чаралары җыелмасы турында өйрәтмә тора. ***Стилистика*** һәм ***әдәби тел***

---

[2] Һәр милли тел белемендә тел турындагы фәннең төрле структур өлкәләре аерылып чыгарга мөмкин. Мәсәлән, рус һәм татар тел белемендә фонетика һәм фонология, лексикология һәм семасиология, морфология һәм синтаксис, сүз ясалышы, стилистика лингвистиканың мөстәкыйль өлкәләре буларак танылa. Американың бик көчле һәм абруйлы дескриптив лингвистика һәм трансформацион грамматика мәктәпләрендә телнең төп структур өлкәләренә туры килә торган аермачык бүленеш юк. Дескриптив лингвистика барысын да бик үзенчәлекле рәвештә аңлана торган морфологиягә, ә трансформацион грамматика исә шулай ук үзенчәлекле рәвештә кабул ителгән синтаксиска кайтарып калдыра.

[3] Фәннәрне физика-математика, техник, табигать һәм гуманитар фәннәр дигән төркемнәргә бүлү дә бар.

***тарихы*** фәннәре исә бу ике фәннең үзара мөнәсәбәтен тагын да ачыграк чагылдыра.

Тел белеме кешелек җәмгыятенең үсешен өйрәнә торган ***тарих*** фәне белән бәйләнгән булу гаҗәп түгел, чөнки тел тарихы халык тарихының бер өлешеннән гыйбарәт. Телнең сүзлек составы җәмгыять тарихы белән аеруча бәйләнгән.

Аерым алганда, тел белеме ***археология*** (тарихны матди чыганаклар – хезмәт кораллары, төрле кораллар, бизәнү әйберләре, тормыш кирәк-яраклары һ.б. буенча өйрәнә торган фән) һәм ***этнография*** (халыкларның көнкүреше һәм мәдәнияте турындагы фән) кебек тарихка бәйле фәннәр белән дә мөнәсәбәттә тора. Тел белеменең этнография белән бәйләнеше диалекталь сүзләрне өйрәнгәндә, телләр һәм халыкларны төркемләгәндә, халык аңының телдә чагылышын тикшергәндә ачык сизелә.

***Археография*** фәне борынгы кульъязмаларны туплау белән шөгыльләнә, тел ягыннан эшкәртеп бастырып чыгара һәм тарих өчен материал бирә. Галимнәр әлеге язмалар ярдәмендә халыкның тормышын, рухи дөньясын, башка халыклар белән мөнәсәбәтен һәм тел үзенчәлекләрен өйрәнәләр.

***Эпиграфика*** фәне кабер ташларындагы язмаларны туплый, өйрәнә. Ул тел белеме һәм тарих өчен кыйммәтле чыганак.

Кешенең сөйләм эшчәнлеге факты буларак тел бер үк вакытта ***психология***нең һәм тел белеменең предметы да. Психология фәне күп кенә тел проблемаларын чишүгә үзеннән зур өлеш кертә. Ул сөйләмне барлыкка китерү һәм тоемлау белән бәйле психик процессларны, ягъни телнең психофизиологик механизм белән бәйләнешен өйрәнә. Психология шулай ук баш миенең функцияләре, реаль чынбарлыкның чагылышы кебек психик күренешләрне дә (сизү һәм тоемлау, уй-фикер, тойгы һәм теләкләр, ихтыяҗ һәм кызыксынулар, омтылыш һәм сәләтләр) күзәтә.

***Психолингвистика*** телне кешенең сөйләмен көйли торган динамик, хәрәкәтчән система буларак кабул итә. Аның максаты – сөйләм процессларын һәм механизмнарын (сөйләмне барлыкка китерү, кабул итү) тел системасы белән чагыштырып өйрәнү. Бу фәннең игътибары тел берәмлекләренә (авазлар, сүзләр,

җөмләләр, текстлар) түгел, ә бәлки кешегә, аның психологик чынбарлыгына, сөйләмне барлыкка китерүгә һәм кабул итүгә, шулай ук телне өйрәнүгә һәм куллануга юнәлдерелгән. Ул индивидның сөйләм эшчәнлеге һәм психофизиологик сөйләм модельләрен булдыру, аларны эксперименталь тикшерү белән шөгыльләнә.

Натуралистик (биологик) тел белеме яссылыгында психология, лингвистика һәм нейрология (нейрофизиологиянең бер бүлеге буларак) чикләрендә тагын ***нейролингвистика*** дип исемләнгән фән дә яшәп килә. Нейролингвистика нәтиҗәләре сөйләмне барлыкка китерү һәм аңлау механизмнарына төшенүдә мөһим урын алып тора. Әлеге фәндә афазияләргә[4] аеруча зур игътибар бирелә. Афазияләрне өйрәнү лингвистларга нормаль сөйләмне аңлау өчен генә түгел, бәлки тел төзелешен һәм аның яшәешен өйрәнү өчен дә күп мәгълүмат бирә.

Тел белеме ***педагогика*** белән дә бәйләнгән, телне укыту методикасы кебек хосусый дидактик фән гамәли тел белеменең бер бүлеге буларак карала. Телгә өйрәтү методикасында тел белеме, психология һәм педагогика нигезләре дә бар. Хәзерге методика туган телгә өйрәтү методикасын гына түгел, ә чит телгә өйрәтү методикасын да үз эченә ала.

XX гасыр башында тел белеме белән чиктәш тагын бер фән – ***лингвосемиотика*** барлыкка килә. ***Семиотика*** (грекча “тамгалар турында өйрәтмә”) барлык тамгаларны, аларның гомуми үзенчәлекләрен өйрәнә: телеграф коды, флаглы сигнализация, юл тамгалары (знаклар), хәрби тамгалар, жест телләре һ.б. Табигый тел иң төп һәм аеруча катлаулы классик тамгалар системасы булганлыктан, семиотика телне дә башка тамга системалары белән бергә өйрәнә.

Башка фәннәр белән чагыштырганда тел белеме ***фәлсәфә*** белән ныграк табигый бәйләнештә тора. Фәлсәфә кешенең дөньяда тоткан урынын, безнең аңыбызның нәрсә икәнлеген

---

[4] Афазия – баш миенең сөйләм зоналары җәрәхәтләнү белән бәйле сөйләм кимчелекләре. Афазияләрнең төрләре: а) динамик афазия (семантик дәрәҗәдәге кимчелекләр, ягъни сөйләмнең мәгънә схемасын төзүдәге кыенлыклар белән бәйле очрак); ә) синтаксик афазия, аграмматизм (синтаксик дәрәҗәдәге кимчелекләр, ягъни сөйләмнең грамматик яктан проблемалы булуы); б) эфферент мотор афазия (мотор дәрәҗәсендәге кимчелекләр, ягъни сөйләмнең мотор кинетик төзелешендәге кыенлыклар).

билгели, материянең, табигатьнең, чынбарлыкның һәм аңның нинди тәртиптә килүе хакында фикер йөртә. Кешенең фикерләве тел ярдәмендә тормышка ашырылганга күрә, фәлсәфә, һичшиксез, уйлау процессының телдә ничек чагылуын, ягъни кешенең әйләнә-тирәсендәге чынбарлыкны танып белү мәсьәләсен урап уза алмый.

Тел шулай ук ***логика*** (мантыйк) фәненең дә өйрәнү предметы. Билгеле булганча, логика – фикерләү берәмлекләрен (төшенчә, фикерләү, нәтиҗә) аңлату формаларын өйрәнә. Логика тел ярдәмендә фикерләү законнарын ачу белән шөгыльләнә. Телче исә, тел законнарын өйрәнә һәм фикерләү законнары аны бары тик телнең төзелешенә мөрәҗәгать иткәндә генә кызыксындыра.

Тел белеменең ***дин*** белән бик борынгы һәм тыгыз мөнәсәбәтләренә тукталып үтми мөмкин түгел. Беренче лингвистик метафизик идеяләр дини тәгълиматларга барып тоташа, нәкъ менә алар күп кенә халыкларда тел белеменең барлыкка килүенә этәргеч була. Сүзнең илаһилык идеясе һәм аның чиксез кодрәте (моннан Изге текстларның төрле телләрдәге вариацияләреннән курку килеп чыккан) Борынгы Һиндстанда һәм Борынгы Көнчыгышта тел белеменең үсешенә китерә.

Тел белеме фәне кеше организмын өйрәнә торган фәннәр, аерым алганда ***физиология*** белән тыгыз элемтәдә тора. Тел белеменең физиология белән бәйләнешләре борынгыдан килә. Физиология һәм нейрофизиология сөйләм аппаратының төзелешен, анда сөйләм авазларының ясалышын, ишетү органнары ярдәмендә сөйләм агымын кабул итүне, телнең рефлекслы физиологик нигезен өйрәнәләр.

XIX гасырның урталарында, Ч.Дарвинның эволюция теориясе тәэсире белән, лингвистика һәм ***биология*** фәннәренең тыгыз берләшмәсе оеша, телгә табигый күренеш буларак карау – тел белемендә натуралистик юнәлеш барлыкка килә. Аңа нигез салучы – немец тел белгече А.Шлейхер (1821-1868). XX гасырда генетик код һәм табигый телнең төзелеш охшашлыгы табылу нәтиҗәсендә нейролингвистика, биология белән тыгыз берләшеп, үз чикләрен киңәйтә бара.

Тел белеменең ***география*** белән бәйләнешләре дә шактый нык. Лингвистика һәм географиянең үзара бәйләнештә торуы XIX йөз ахырында ***лингвогеография*** дип аталган гибрид фән туугa сәбәп була. Бу фән телләрнең һәм диалектларның, шулай ук аерым тел күренешләренең территориаль таралышын өйрәнү белән шөгыльләнә.

Тел белеменең ***физика***, бигрәк тә аның бер бүлеге булган *акустика* белән бәйләнешенә борынгы греклар ук игътибар иткәннәр, алар сөйләм авазларын яңгыраш ягыннан өйрәнгәннәр. Акустика белән бәйләнеш бүгенге фәндә дә актуаль булып кала һәм бу хәл яңа лингвистик фән – сөйләм авазларын өйрәнүдә приборлар куллана торган ***эксперименталь фонетика***ның тууына сәбәп була.

XX гасырның 50 нче елларында математика һәм лингвистика чикләрендә ***математик лингвистика*** барлыкка килә, ул табигый телләрне тасвирлау өчен формаль аппаратлар эшкәртә. Математик методларны куллану төрле тел фактларын сан ягыннан өйрәнергә, аларны төркемләргә, ешлык сүзлекләре төзергә, тел берәмлекләренең формаль ярашуын өйрәнергә, сөйләм барлыкка килү һәм аны кабул итү процессларының модельләрен төзергә, телне система буларак аңлауда математик идеяләрне кулланырга, язма текстның кайбер үзенчәлекләрен (авторлык, язылу вакыты һ.б.) ачыкларга ярдәм итә.

Тел белеменә мөнәсәбәттә торган математик дисциплиналар арасында ***информатика*** да бар, ул телне мәгълүмат саклау, эшкәртү һәм тапшыру чараларының берсе буларак өйрәнә. Лингвистика белән берлектә, информатика мәгълүмати-эзләү системалары һәм автоматлаштырылган идарә системалары эшчәнлеген оештыруны тәэмин итә.

Хәзерге лингвистика ***кибернетика*** фәне белән дә тыгыз бәйләнгән. Тел белеменең кибернетика белән багланышлары ***инженер лингвистика***сын барлыкка китерә, ул телне компьютерларга, текстларны машина белән эшкәртү мөмкинлекләренә һәм кеше тавышларын синтезлауга һ.б. проблемаларга мөнәсәбәттә өйрәнү белән шөгыльләнә.

Тел белеме фәне буенча элементар белемнәрне **тел белеменә кереш** курсы бирә. Анда түбәндәге мәсьәләләр карала: телнең

табигате һәм асылы ачыклана, аның фикерләү белән мөнәсәбәте, телнең иҗтимагый характеры, тел үсешенең төп закончалыклары, сөйләм теленең килеп чыгышы тикшерелә. Тел – системалар системасы. Телдәге авазлар, сүзләр, җөмләләр, интонация, сүз төркемнәре һ.б. ныклы оешкан катлаулы бер система барлыкка китерәләр. Тел белеме телнең эчке бердәмлеген өйрәнүне максат итеп куя. Бу фән телнең төзелеше, структурасы белән бәйле проблемаларны хәл итә, телнең аваз ягын, лексикасын, грамматик төзелешен тикшерү белән шөгыльләнә. Тел белеменә кереш фәне телләрне төркемләү принциплары һәм тел гаиләләре белән дә таныштыра.

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар**

1. Филологик фәннәр дип нинди фәннәргә әйтәләр?
2. Филологик фәннәрне нинди төркемнәргә бүләләр?
3. Тел белеме дип нинди фәнгә әйтәләр?
4. Филологик фәннәрнең кайсылары тел белемен тәшкил итә?
5. Тикшеренү максатларыннан чыгып, тел белеменең нинди төрләре була?
6. Гомуми тел белеме нинди мәсьәләләр белән шөгыльләнә?
7. Эчке лингвистика телне кайсы яктан өйрәнә?
8. Тышкы лингвистикага нинди фәннәр керә?
9. Нинди фәннәр иҗтимагый фәннәр дип атала?
10. Табигать фәннәре дип нинди фәннәргә әйтәләр?
11. Тел белеменең иҗтимагый фәннәр белән бәйләнеше турында сөйләгез.
12. Тел белеменең табигать фәннәре белән бәйләнешен конкрет мисаллар белән исбатлагыз.
13. “Тел белеменә кереш” курсының максаты һәм бурычлары турында сөйләгез.

## Тема: ТЕЛНЕҢ ТАБИГАТЕ, АСЫЛЫ ҺӘМ ФУНКЦИЯЛӘРЕ

1. Тел һәм җәмгыять.
2. Тел – тамгалар (знаклар) системасы.
3. Телнең функцияләре.
4. Тел һәм фикерләү.
5. Тел һәм сөйләм.

### 1. Тел һәм җәмгыять.

Тел – кешеләр аралашуында иң мөһим чараларның берсе. Телдән башка кешеләр аралаша алмый, аралашудан башка җәмгыять тә, шул исәптән кеше үзе дә була алмас иде. Телдән

башка фикерләү дә юк. Әмма болар барысы да кешеләр бергә яшәгәндә генә, ягъни җәмгыятьтә генә була ала. Кеше җәмгыятьтән аерым яши алмый, ул телиме-теләмиме иҗтимагый мөнәсәбәтләрне чагылдыра, шуларга буйсына. Тел җәмгыятьтә генә, билгеле бер коллективта гына барлыкка килә һәм үсә. Тел җәмгыять һәм аның тарихы белән бик тыгыз бәйләнгән. Болар бар да аның иҗтимагый табигатеннән килә.

Кеше телен хайваннарның аваз сигнализациясе белән чагыштырганда аның иҗтимагый асылы аеруча ачык күренә. Кеше сөйләм авазларын әйткәндә (сөйләшкәндә) билгеле бер органнардан файдалана. Кешеләрдәге кебек органнар, шул исәптән ми, сизү-тою органнары, борын һәм авыз куышлыгы һ.б. хайваннарда, кошларда да бар. Әмма алар чыгарган төрле авазларны сөйләшү дип әйтеп булмый, чөнки алар фикерләү белән бәйләнмәгән.

Баланың кайсы телдә сөйләшә башлавы тәненә, чәченә, күзенә һ.б. билгеләренә карамый, ә аның тирәсендәге кешеләрнең нинди телдә аралашуына бәйле була. Чөнки ул телне башкалар, әйләнә-тирә (гаилә, мәктәп, тәрбиячеләр, урам һ.б.) тәэсирендә өйрәнә.

Конкрет бер тел буыннан-буынга күчми, баланың нинди телдә сөйләшәчәге генетик яктан алдан билгеләнми. Баланың аерым органнары гына генетик дәрәҗәдә сөйләм механизмына яраклаштырылган. Әмма бу механизм тиешле шартлар (тел әйләнәсе, социум) булганда гына хәрәкәткә килә. Әгәр бала телсез-чукрак булып туа икән, җәмгыятьтә яшәү генә аны сөйләшергә өйрәтә алмый, чөнки аның кирәкле физиологик механизмы формалашмаган була. Физиологик механизм эшчәнлегенә зыян килгәндә (төрле имгәнүләр, һәлакәтләргә очрау һ.б.), олы кешедә дә төрле сөйләм кимчелекләре килеп чыгарга, кеше хәтта сөйләшүен онытырга мөмкин.

Җәмгыятьтәге һәртөрле үзгәрешләр телләрнең дә үсеш-үзгәрешенә китерә: алар уңай да (телләр көчәеп, күтәрелеп китә), тискәре дә (телләр юкка чыгуга, "үлемгә" дучар ителә) булырга мөмкин. Шул ук вакытта тел үзе дә җәмгыятьнең үсешенә йогынты ясый ала. Җәмгыятьтә барлык кешеләргә дә хезмәт итә торган, аңлаешлы, язуда беркетелгән бер әдәби тел булу

дәүләтнең үсешенә тәэсир итә, мәдәни һәм икътисади бәйләнешләрне көчәйтә, аның дөньядагы урынын билгели. Дәүләттә телләрнең күплеге, таркаулыгы, күбесенең язуы булмау (мәсәлән, Африка дәүләтләрендә) бу илләрдә рәсми өлкәдә колонизаторлар телен куллануга сәбәп була.

Шул рәвешчә, тел иҗтимагый характерга ия, ул билгеле бер җәмгыятьтә генә, кешеләр арасында гына барлыкка килә, үсә, ныгый ала. Тел һәм җәмгыять үзара тыгыз мөнәсәбәттә яши.

**2. Тел – тамгалар (знаклар) системасы.**

Кешелек җәмгыятендә мәгълүмат алмашу, фикер алышу түбәндәге тәртиптә бара: сөйләүче (адресант) тыңлаучыга (адресатка) сөйләмдә сүз бара торган предметның, әйбернең үзен түгел, ә аны алыштыра, аларга ишарә итә һәм атый торган тамгаларны (знакларны) җиткерә. Мондый алмаштырулар кешеләр тормышында шактый еш күзәтелә, хәтта кешеләр чын предметлар арасында түгел, бәлки тамгалар дөньясында яши дигән тәэсир туарга мөмкин. Кеше бу тамгалардан аңлы рәвештә, максатчан, белеп файдалана.

Икенче бер күренешләрне, предметларны белдерә, алыштыра ала торган матди предметлар ***тамга*** дип атала. Тамга табигатьтән алынырга яки махсус ясалырга мөмкин һәм ул шартлы мәгънәгә ия була: аларны кайчандыр, кемдер билгеле бер мәгънәдә куллану турында алдан сөйләшеп куйган була.

*Билге* яки *симптом*нарны тамгалардан аера белү мөһим. Симптомнар объектив чынбарлыкка карый, шартлы булмый. Симптом, гәрчә күзәтүчегә тиешле нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирсә дә, махсус нәкъ менә шул нәтиҗәләрне күздә тотмый. *Симптом* – әйберләрнең күзәтелә һәм теркәлә торган сыйфаты, асылы. Мәсәлән, үлчәм, авырлык һ.б. кебек. Симптомнар – нинди дә булса мәгълүматны тапшыру өчен максатчан рәвештә файдаланылмый торган билгеләр. Аларда эчтәлек һәм белдерелү планы сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтләрендә була.

Ә *тамгалар* шартлы. Аларны ишетеп, күреп була, алар кабул ителә һәм башка күренешләр белән бәйләп карала. Бу очракларда тамга белән ул белдергән күренеш турыдан-туры бәйләнмәгән, ягъни арасында детерминация юк. Мәсәлән, юлдагы хәрәкәт

белән полицейский да идарә итә ала. Кешеләр, алдан сөйләшеп куйса, светофорда башка төсләр дә кулланыла алыр иде. Башкача әйткәндә, алда мисалга китерелгән тамгалар шартлы, тамга белән ул белдергән күренеш арасында турыдан-туры, табигый бәйләнеш юк, аларны кешеләр алдан килешеп, билгеле бер мәгънә белдерү өчен куллана башлаганнар. Алар шул тел вәкилләре тарафыннан кабул ителә, мәҗбүригә әйләнә, буыннан-буынга тапшырыла.

### *Тамга (знак) системалары турында төшенчә*

Семиотик системаларны *интеграль* һәм *махсус* дигән төрләргә дә бүлү кабул ителгән.

*Интеграль* системалардан җәмгыятьнең барлык әгъзалары да бердәй файдалана. Боларга тел, гореф-гадәтләр, уеннар һәм санау чаралары керә. Мәсәлән, барлык кешеләр дә сөйли һәм тыңлый ала; аларның билгеле бер гореф-гадәтләр буенча кушылган исемнәре бар; һәркем нинди дә булса уенда катнаша; кешеләр төрле санау чараларын кулланалар һ.б.

*Махсус* семиотик системалар белгечләр тарафыннан эшкәртелә, алардан барлык кешеләр дә файдаланмый. Әйтик, барлык кешеләр рәсем ясаса да, җәмгыятьтә профессиональ рәссамнар бар, алар бу һөнәрне саклыйлар, үстерәләр, традицияләрне дәвам иттерәләр, башкаларны өйрәтәләр. Махсус системалар дүрт төркемгә бүленә:

- прогноз системалары (сынамышлар, күрәзәчелек, багу);
- гамәли булмаган сәнгать системалары (музыка, бию, сурәтләү-нәкыш);
- гамәли сәнгать системалары (костюм, дизайн, архитектура);
- идарә системалары (ориентирлар, сигналлар, командалар һ.б.).

Семиотик системалар хезмәт бүленеше шартларында җәмгыятьнең күмәк эшчәнлек оештыру мөмкинлекләрен күрсәтәләр. Бу тамгаларның барысы белән дә тел идарә итә, ул үзе дә тамгалар системасы буларак үзенчәлекле сыйфатларга ия.

### *Семиотик система буларак тел*

Тел иң катлаулы һәм нык үскән тамгалар системасыннан гыйбарәт. Ул катлаулы төзелеше һәм тамгаларының күплеге белән генә түгел, ә куәтле семантик мөмкинлекләре, ягъни күзәтелә яки күзаллана торган төрле өлкәләрдә мәгълүмат тапшыра алу сәләте белән дә аерылып тора.

Бүгенге көн тел белемендә тел үзенчәлекле семиотик сыйфатларга ия булган система буларак өйрәнелә. Беренчедән, башка тамгалар (знаклар) белән чагыштырганда, тел беренчел. Башка тамга системалары табигый тел нигезендә формалаша. Барлык ясалма тамга (знак) системалары, табигый тел белән чагыштырганда, икенчел, уйлап табылган. Икенчедән, башка тамга (знак) системалары чикләнгән мәгълүмат тапшыру өчен барлыкка китерелгән, алар кеше тормышының конкрет бер өлкәсе өчен генә кирәк. Тел исә мәгълүмат саклау һәм тапшыруда универсаль чара, ул кешегә, яки аерым бер җәмгыятькә тормышның барлык өлкәләрендә дә зарур.

Телнең башка тамга (знак) системаларыннан тагын бер аермасы – телнең фикер барлыкка китерү һәм тапшыру чарасы булуы. Ул, шулай ук, кешенең хис-тойгыларын, ихтыярын белдерә, ә башка системалардагы тамгалар исә, музыкаль тамгалар һәм жестлардан калганнары, эмоциональ яктан нейтраль.

Телнең башка системалардан аермалы тагын бер сыйфаты – аның һәрвакыт камилләшүе, бу исә аңа иң көчле фикерләү чарасы исемен бирә. Тел, күп очракта, үзеннән-үзе үсә, аның сәбәпләре сизелмәскә дә мөмкин.

Ясалма тамга (знак) системалары үзләреннән-үзләре камилләшә алмый. Телдән аермалы буларак, алар статик. Алардагы үзгәрешләр яңа шартлар нигезендә теге яки бу тамга (знак) системасын камилләштерергә кирәк булган очракта кеше ихтыярына бәйле рәвештә барлыкка килә.

Тел башка тамга (знак) системаларыннан берәмлекләр саны, алар арасындагы тагын да төрлерәк һәм катлаулырак мөнәсәбәтләр буенча да аерылып тора.

### ***Тел тамгалары турында төшенчә***

Телнең кайсы берәмлекләрен (элементларын) тамга дип атарга була соң? Бу сорауга җавап бирү өчен иң элек телнең элементларын һәм алар арасындагы мөнәсәбәтне билгеләргә кирәк. Тел берәмлекләрен аеру әйтелмәне (высказывание), сөйләмне, текстны кисәкләргә бүлү белән бәйләнгән.

Аерым әйтелмә сөйләм ярдәмендә аралашуның төп берәмлеген тәшкил итә. Теләсә нинди аралашу очрагында

әйтелмәнең ике ягын билгелиләр: *тәгъбир итү планы* – әйтелмәнең ишетеп кабул ителә торган матди, аваз ягы. *Эчтәлек планы* – әйтелмәдә белдерелгән фикер, мәгълүмат һәм аларга бәйле эмоциональ моментлар. Тел белемендә эчтәлек планы һәм тәгъбир итү планы тыгыз бәйләнештә өйрәнелә. Әйтелмә бер-бер артлы килгән җөмләләргә бүленә, ул шулай ук бер генә җөмләдән дә торырга мөмкин. Җөмлә үз чиратында тагын да мәгънәле өлешләргә таркала. Арада безнең өчен гадәти элемент – сүз. Телдәге сүзләр гаять күп төрле, әмма барысы да кечерәк мәгънәле кисәкләргә – морфемаларга таркала. Телнең алда санап үтелгән берәмлекләре *ике яклы берәмлекләр*, чөнки аларның тәгъбир итү планы һәм эчтәлек планы бар. Болардан тыш телдә *берьяклы берәмлекләр* – фонемалар (авазлар) да яши.

Тел тамгаларына ике яклы берәмлекләрне – беренче чиратта, сүз һәм морфеманы кертергә мөмкин. Боларны коммуникатив яктан тулы булмаган яки *өлешчә* тамгалар дип тә атыйлар. Телнең иң югары берәмлеге – җөмлә – тел тамгаларының комбинациясеннән гыйбарәт. Әйтелмә, текст – телнең *тулы* тамгалары була, алар коммуникатив яктан тәмамланган, җитәрлек дәрәҗәдә камил берәмлекләр. Тел тамгаларын башка төрле дә төркемлиләр, мәсәлән, фонеманы – сигналь тамга, морфеманы – ярым тамга, сүзне – өлешчә тамга, ә менә җөмләне тулы тамга буларак кабул итәләр. Телнең төп тамгасы – сүз, аның эчтәлеге кумулятив характер йөртә, ягъни, тарихта тупланган мәгълүмат нигезендә барлыкка килә.

***Тел тамгаларының симметриясе һәм асимметриясе***

Тел – кешеләр аралашу максатларында файдалана торган күп төрле тамга системаларыннан берсе генә. Кешенең дөньяны танып белү мөмкинлеге бик зур, әмма хәтере шактый чикләнгән. Тел билгеле бер сандагы элементлар ярдәмендә күп санлы яңалык тапшырырга сәләтле итеп корылган. Телнең запасында морфема һәм сүзләр, сүзтезмә, җөмлә һәм текст тибындагы тамгалар саны, яңа, кабатланмас һәм катлаулы тамгалар кушылмасы ясау конструкцияләре чагыштырмача күп түгел. Күпчелек тамгалар белән алар белдергән предмет, күренеш, билге һ.б. арасында бәйләнеш шартлы, бу бәйләнеш табигый факторлар белән дә, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре белән дә

аңлатыла алмый. Шунлыктан бер тел тамгалары икенче телнеке белән туры килми. Шулай да бер тел коллективында тел тамгасы белән предмет, күренеш арасындагы бәйләнеш мәҗбүри була, аерым бер кеше генә бу бәйләнешне боза алмый, юкса, ул башкаларга аңлашылмас иде.

Тел гасырлар дәвамында стихияле рәвештә формалашкан һәм үзгәргән, шунлыктан һәр телдә логикага сыймаган, рациональ булмаган нәрсәләр шактый, ягъни тәгъбир итү планы белән эчтәлек планы арасында симметрия юк. Мәсәлән, барлык телләрдә дә омоним сүзләр (бер тамга берничә предмет, күренеш һ.б. белдерә) бар, абсолют синонимнар (бер предмет, күренешне һ.б. белдерә торган ике яки берничә тамга) яши, бер сүз, бер фикер эчендә бер үк мәгънә берничә тапкыр кабатланырга мөмкин (мәсәлән, фигыльдә дәрәҗә кушымчасы, затны белдерә торган сүз һәм фигыльдә зат-сан кушымчасы) һ.б. Ясалма системалардан аермалы буларак, тел тамгаларының мәгънәсенә еш кына эмоциональ момент та (мәсәлән, иркәләү-кечерәйтү мәгънәсе һәм, киресенчә, ачулану сүзләре) кушылырга мөмкин.

### 3. Телнең функцияләре.

Телнең функцияләре һәм аларның характеры турында хәзерге лингвистикада уртак фикер юк. Бу мәсьәләне кабат-кабат тикшерү нәтиҗәсендә телнең *иҗтимагый* һәм *эчке төзелеш функцияләре* аерып карала башлады.

Телнең ***иҗтимагый функцияләре*** аның кешелек җәмгыятендәге роленнән килеп чыга. Бу функцияләр арасында иң мөһиме – *коммуникатив функция*, ягъни телнең кешеләр аралашуында универсаль чара булуын билгели торган функция. Бу – телнең төп функциясе. Тел ярдәмендә кешеләр бер-берсенә фикерләрен, хис-тойгыларын, эчке кичерешләрен җиткерәләр, шуның белән бер-берсенә тәэсир итәләр һәм иҗтимагый аң формалаштыралар. Тел кешеләргә үзара аңлашырга ярдәм итә, тормышның барлык өлкәләрендә бердәм эшчәнлек оештырырга мөмкинлек бирә. Тел – кешелек җәмгыятенең яшәве һәм үсешендә төп көчләрнең берсе.

Телнең икенче төп иҗтимагый функциясе – *аккумулятив функция,* ягъни телнең иҗтимагый тәҗрибә һәм белемнәр туплау

чарасы, матди һәм рухи мәдәният формалаштыру һәм үстерү коралы булуын күрсәтә торган функциясе. Телдә, язма текстларда мәгълүмат туплана һәм шәхестән шәхескә, буыннан буынга тапшырыла. Бу мәгълүматта табигать законнары һәм җәмгыять турындагы белемнәр җыйнала, эстетик һәм мәдәни кыйммәтләр саклана. Кешелекнең һәр буыны үзенә мирас булып калган белемнәрне үстерә, шул рәвешчә мәдәният, фән, җитештерүчәнлек үсешен канәгатьләндерә, иҗтимагый аңны үстерә.

*Когнитив функция* – телнең эчтәлекне белдерү, тапшыру һәм саклау функциясе. Ул әйләнә-тирәдәге предмет һәм күренешләрне атауда, аларга бәя бирү мөмкинлегендә чагылыш таба. Когнитив функция дигәндә, җөмләнең аралашуда тапшырыла торган мәгънәсеннән тыш, аның абстракт, формаль мәгънәсен дә аера белү мөһим. Ул фикерләү нәтиҗәсен, җөмләнең конкрет эчтәлеген – мәгънәне формалаштыру һәм тапшыру чарасы булып кына хезмәт итә. Когнитив функция аерым кешеләр аралашканда гына күзәтелми, ул халыкның тел тәҗрибәсендә чагылыш таба, киләчәк буыннар өчен җәмгыять һәм табигать, фикерләү һәм тел турында төрле белемнәрне саклый. Мәсәлән, *сөңге, чикмән, киле* кебек предметлар кулланылыштан чыксалар да, аларны белдерә торган сүзләр текстларда сакланып калган.

Телнең алда әйтеп үтелгән төп иҗтимагый функцияләреннән башка, ***икенчел функцияләр***ен дә аерып карыйлар, алар телнең төп функцияләренә бәйле һәм бер-берсенә тәэсир итәләр. Тел зыялы, акыллы хәбәрләрне белдереп һәм тапшырып кына калмый, шул ук вакытта хисләрне, тойгыларны да чагылдыра. Шул җирлектә телнең *эмотив* (хис-тойгыларны белдерү), *волюнтив* (ихтыярны тапшыру) һәм *интеррогатив* (сорау) кебек өстәмә функцияләре дә барлыкка килә. *Раслау (констатацияләү) функциясе* – нинди дә булса факт турында “битараф” хәбәр итү; *экспрессив функция* – сөйләүченең кәефен һәм хисләрен чагылдыру функциясе; *контакт урнаштыру* яки *фатик функция* – әңгәмәдәшләр арасында җитди мәгълүмат тапшыру ихтыяҗы булмаган очракта (һава торышы, сәламәтлек һ.б. турында репликалар алмашу) контакт урнаштыру һәм контактны саклау функциясе; *эстетик функция* – тел ярдәмендә

шәхескә эстетик тәэсир итү функциясе (әдәбият, театр, кино һ.б.); *апеллятив функция* – нинди дә булса эш-гамәлләргә чакыру, өндәү функциясе һ.б. Өстәмә функцияләр арасында билгеле бер төркем кешеләргә караганлыкны белдерә торган *индикатор (күрсәткеч) функциясе* аерым урын алып тора. Бу функциядән аңлы рәвештә файдаланган очракта ул җәмгыятьтә шәхеснең үзенчәлекле үзбилгеләнү чарасына әверелә.

***Эчке төзелеш функцияләре*** телнең асылын һәм табигатен чагылдыра. Гомумән, бу функцияләр турында сүз йөрткәндә, билгеле бер эчтәлекне, мәгънәне тел формалары белән белдерүне аңлыйлар. Моннан телнең мөһим функцияләреннән берсе – *фикер формалаштыру функциясе* килеп чыга, ягъни тел фикерләрне формалаштыру һәм белдерү чарасы булып хезмәт итә. Фикер тел формалары аша белдерелгәндә һәм сөйләмдә әйтелгәндә генә оеша һәм кабул ителә ала. Тел фикерне иң беренче чиратта сүз аша матдиләштерә һәм белдерә, ә сүз предметлар, күренешләр, эш-гамәлләрне атый.

Сүзнең предмет һәм күренешләрне атау сәләте тагын бер мөһим эчке төзелеш функциясен – *номинатив функция*сен билгели. Сүзнең әйберләрне атау үзенчәлеге атаманы фикер коралы итеп файдалану мөмкинлеге бирә. Әйбер атамалары фикернең тамгасына әйләнә, ә бу исә җисем (матдә) турындагы фикерләргә таянырга ярдәм итә: предметлар турында төшенчә чыгарырга, аларның үзлекләрен чагылдырырга, хөкем һәм нәтиҗә формалаштырырга булыша.

Телнең кеше фикерләве һәм аның чынбарлыкка мөнәсәбәте белән бәйле эчке структур (фикер формалаштыру һәм номинатив) функцияләреннән тыш, тел системасының төзелешенә бәйле тел берәмлекләренең функцияләрен аера белергә кирәк. Бу очракта сүз фонема, морфема һ.б. тел төзелеше берәмлекләре; ия, хәбәр, тәмамлык һ.б. функцияләре турында сүз бара. Телнең бу функциясен *метател функциясе* дип атыйлар, ул телнең үзен тасвирлау өчен хезмәт итә.

### 4. Тел һәм фикерләү.

*Фикерләү* – уйлау һәм фикер йөртү сәләте. Фикер – фикерләүнең конкрет нәтиҗәсе.

Фикерләү вербаль (телдән) һәм вербаль булмаган (телдән булмаган) төрләргә бүленә. ***Вербаль булмаган*** фикерләү чынбарлык тәэсирләрен кабул итү нәтиҗәсендә туган, хәтердә саклау һәм күзаллау ярдәмендә яңадан барлыкка китерелгән хисси-күрсәтмә образлар ярдәмендә тормышка ашырыла. Бу төр фикерләү күпмедер дәрәҗәдә кайбер хайваннарда, кош-кортларда да үсеш алган, нәкъ менә шул хайваннарга дөрес ориентлашырга, максатчан карарлар кабул итәргә булыша. Вербаль булмаган фикерләүнең югары үсешкә ия формалары кешедә табыла.

***Вербаль фикерләү*** сүзләрдә теркәлгән төшенчәләр, хөкем, фикри нәтиҗәләргә таяна, анализлый һәм гомумиләштерә, гипотезалар һәм теорияләр кора. Ул телдә ныгыган формаларда бирелә, тышкы һәм эчке сөйләм процессында тормышка ашырыла. Тел кешенең дөнья турындагы белемнәрен билгеле бер тәртиптә оештыра, тарката, аларны ныгыта һәм алдагы буыннарга тапшыра дип әйтергә була. Төшенчәле фикерләү икенчел, ясалма телләргә, кеше уйлап тапкан махсус аралашу системаларына таянырга мөмкин. Вербаль (телдән) фикерләү – кеше фикерләвенең иң әһәмиятлеләреннән саналса да, нибары бер компоненты гына.

Тел һәм фикерләү аерылгысыз бәйләнгән, әмма аларны тәңгәлләштерергә дә, бер-берсеннән аерырга да ярамый. Фикерләүнең камилләшүе, үсеше, яңа төшенчәләрне белдерү өчен, үзенә тәңгәл формалар таләп итә. Шул ук вакытта фикерләүнең дә алга таба үсеше телдән башка мөмкин булмас иде. Фикерләү белән тел тыгыз бәйләнештә яши: фикерләү никадәр төзегрәк булса, аның телдә белдерелүе дә шулкадәр төгәлрәк була һәм, киресенчә, фикер никадәр ачыграк белдерелсә, ул шулкадәр тулырак, төгәлрәк аңлашыла да.

**5. Тел һәм сөйләм.**

***Тел*** термины белән телнең төзелешен дә, әдәби телне дә, аерым бер кеше телен дә (мәсәлән, Пушкин теле, Тукай теле) атыйлар. Бу билгеле бер дәрәҗәдә дөрес тә, чөнки тел – катлаулы күренеш, ул иҗтимагый һәм шәхси кулланылыштан тыш яши алмый. Сөйләмне телгә каршы куеп, сөйләм

күнекмәләрен, сөйләм актын, сөйләм нәтиҗәсе – текстны һәм хәтта сөйләм эшчәнлеген гомумиләштереп ***сөйләм*** дип йөртәләр.

***Тел*** төп төшенчә буларак саналырга хаклы. Ул, чыннан да, кешеләр аралашуында иң әһәмиятле чара. Тел билгеле бер коллективның иҗат җимеше һәм тарихи күренеш. Ул билгеле бер вакыт аралыгындагы барлык сөйләш һәм диалектларны, телдән һәм язма сөйләм формаларын берләштерә. Аерым бер кеше теле булмый һәм аны бер генә кеше уйлап чыгара да алмый, чөнки ул гомуми телдән төрлечә файдалана торган бик күп кешеләрне һәм төрле төркемнәрне туплый. Шуңа күрә элек һәм хәзерге көндә инглиз, француз, кытай, гарәп телләре һ.б. яшәгән һәм яши; нәкь шул рәвешчә хәзерге татар теле, иске татар теле, борынгы төрки тел турында да әйтергә була.

Тел – аралашу коралы, сөйләм – аралашу ысулы, димәк, сөйләм – телнең хәрәкәттәге формасы. Сөйләм – телнең кулланылышы дигән сүз. Шулай булгач, аралашу чарасы булган тел нәрсәдән торса, сөйләмдә шул (телнең төрле берәмлекләре һәм аларның бәйләнеш кагыйдәләре) чагыла. Сөйләм тел белән чагыштырганда, үзгәрүчәнрәк, хәрәкәтчәнрәк. Яңа күренешләр башта сөйләмдә барлыкка килә, аннан телгә күчәләр.

Тел һәм сөйләм икесе ике күренеш түгел, ә бер үк күренешнең төрлечә чагылышы гына. Сөйләм нәтиҗәсендә текст барлыкка килә, ул төгәлләнгән һәм нинди дә булса сөйләм материалында нindидер сөйләм коралы белән башкарыла. *Сөйләм материалы* дип сөйләм текстын үзенә алган предметларны әйтәләр – боларга һава (әгәр текст телдән төзелсә), балчык яки балавыз такта, папирус, пергамент, кәгазь, электромагнит тасма һ.б. керә. Текст бу материалларда *сөйләм кораллары* (әйтү органнары, язу әсбаплары, басу кораллары, электрон җайланмалар) ярдәмендә барлыкка килә. Сөйләмне нәкь менә нинди сөйләм материалында барлыкка килүенә һәм нинди кораллар белән башкарылуына карап төркемлиләр: телдән (әйтмә), язма һәм әйтмә-язма сөйләм төрләрен аерып карыйлар.

Телдән сөйләм текстлары һава кисәкчәләренең тирбәнешләре буларак яши, аларны ишетү органнары тотып ала һәм сөйләм сигналы буларак кабул итә; бу тирбәнешләр кешенең артикуляция аппаратын барлыкка китерә. Әгәр сөйләм ишетү буенча язып

алынса, башка материал (кәгазь яки башка язу материалы) кулланырга кирәк була: бу очракта ул икенче сөйләм төренә күчә. Әгәр язганда магнитофон кулланылса, сөйләм магнитлы тасмага теркәлә һәм массакүләм коммуникация тексты оеша.

Яңа сөйләм төрен уйлап чыгару шактый кыен, кешелек бүген яши торганнарын да бик авырлык белән барлыкка китергән. Кешеләр язарга өйрәнеп, *язма сөйләм* барлыкка килгәнче дә күп меңнәрчә еллар үткән. Бары XX гасырда радио, кино, магнитофон, телевизор һәм компьютерлар пәйда булгач кына, *массакүләм коммуникация*не формалаштырган *әйтмә-язма сөйләм* дип аталган катлаулы сөйләм төре оешкан.

Сөйләмнең төрле төрләре мәгънә-эчтәлек белдерүдә төрле мөмкинлекләргә ия. Телдән сөйләм әйтүгә юкка чыга: ул бары әйтү моментында гына яши, шунлыктан аны кешедән аерып карап булмый һәм телдән сөйләм текстын саклау мөмкинлеге дә хәтергә генә бәйле.

Язма сөйләм текстларын исә язучы һәм укучы кешедән аерырга һәм кешедән читтә озак вакытлар сакларга мөмкин. Алар теләсә нинди әйбер кебек саклана, кирәк вакытта аларны яңадан укып була, истә калдыру да мәҗбүри түгел.

Массакүләм коммуникация текстларында тиз, оператив файдалану (телдән сөйләм кебек) һәм озак вакытлар саклану (язма сөйләм кебек) сыйфатлары берләшә.

Телдән (әйтмә), язма һәм әйтмә-язма сөйләм үз эчләрендә тагын да ваграк төрләргә аерылалар.

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар**

1. Тел һәм җәмгыять үзара нинди бәйләнештә тора?
2. Телнең иҗтимагый күренеш булуын конкрет фактлар ярдәмендә исбатлагыз.
3. Тамга һәм симптомны бер-берсеннән ничек аерырга?
4. Нинди тамга системаларын беләсез?
5. Тамгалар системасы буларак телнең үзенчәлекләре турында сөйләгез.
6. Телнең төп иҗтимагый функцияләрен аңлатыгыз.
7. Телнең нинди өстәмә функцияләрен беләсез?
8. Фикерләүнең нинди төрләре бар?
9. Нәрсә ул тел?
10. Сөйләм дип нәрсәгә әйтәләр?
11. Әйтмә (телдән) сөйләм формалары турында сөйләгез.
12. Язма сөйләмнең нинди формаларын аерып карыйлар?
13. Әйтмә-язма сөйләм формаларына нәрсәләр керә?

## Тема: ТЕЛНЕҢ КИЛЕП ЧЫГЫШЫ. ТЕЛЛӘРНЕҢ ТАРИХИ ҮСЕШЕ

1. Телнең барлыкка килүе.
2. Телләрнең килеп чыгуы турында теорияләр.
3. Телнең килеп чыгуына карата хәзерге фәндәге карашлар.
4. Телләр үсешендә төп процесслар.
5. Төрле тарихи чорларда телләрнең һәм диалектларның үсеше.

### 1. Телнең барлыкка килүе.

Моннан 50-100 мең еллар элек Җирдә кеше теле бер генә булганмы, әллә берничә тел янәшә яшәгәнме – бу турыда төгәл генә әйтеп булмый. Турыдан-туры телнең килеп чыгу (глоттогенез) проблемалары белән шөгыльләнүчеләрнең дә моногенез яки полигенез файдасына дәлилләре юк. Шуңа күрә кешелекнең Көнчыгыш Африкада килеп чыгуына, аннан кешеләрнең Азия һәм Европа киңлекләренә таралып утыруларына, соңрак исә Америка, Австралия материкларында һәм Океания утрауларында пәйда булуларына ышанасы гына кала. Аларның этносларга ничек таркалуы, Җирдә күпме этнос яшәп китүе һәм аларның нинди телләрдә сөйләшүе хакында төгәл мәгълүматлар шулай ук юк.

Кайбер соруларга палеоантропология, археология кебек фәннәр җавап эзли. Күптәнге үткәннәрне ачыклауга кайбер борынгы мәдәният истәлекләре, аеруча, борынгы дешифрланган һәм әле укылып өлгермәгән язма текстлар ярдәмендә ерак булмаган тарих ярдәм итә.

Хәзерге көндә яши торган һәм элек яшәп киткән конкрет телләрнең килеп чыгышын тарихи мәгълүматларга таянып хәл итеп була. Тел аны кулланучылардан башка була алмаганга күрә, теге яки бу телнең барлыкка килү, формалашу һәм үсү проблемасын төрле фәннәрдән алынган фактлар нигезендә ачыкларга мөмкин.

### 2. Телләрнең килеп чыгуы турында теорияләр.

Телләрнең килеп чыгуы турында 400 дән артык теория яши. Аларны биологик һәм иҗтимагый теорияләргә берләштереп тә өйрәнәләр. ***Биологик теорияләр*** телнең килеп чыгышын кеше

организмының – ис сизү, тәм тою органнарының, сөйләм аппаратының эволюциясе белән аңлаталар (аваз ияртемнәре, ымлыклар, балалар теле теорияләре һ.б.). ***Иҗтимагый теорияләр*** исә телнең барлыкка килүен кешенең аң үсеше һәм хезмәттә туган иҗтимагый ихтыяҗлар белән бәйләп карыйлар (иҗтимагый килешү, ымнар, хезмәт тавышлары теорияләре һ.б.).

Телнең килеп чыгышы турындагы теорияләрнең кайберләрен карап үтү урынлы булыр.

***Логосик теория (дини тәгълимат).***

Цивилизациянең иң башлангыч этапларында телнең килеп чыгуы турында логосик теория барлыкка килгән (грекча “логос” – төшенчә, аң, фикер). Бу теория берничә төрле була. Безнең эрага кадәр X гасырда яшәгән Һиндстан һәм Алгы Азия халыкларының күзаллауларында тел Алла тарафыннан барлыкка китерелгән дип кабул ителә. Рухи башлангычны белдереп, борынгы кешеләр *бог, слово, логос, дао* терминнарын кулланганнар. Иң борынгы әдәби истәлекләр – һинд Ведалары. Аларда исемнәрне Алла кушкан, әмма бөтен исемнәрне дә түгел, ул бары үзенә буйсынган аллаларның гына исемнәрен куйган, диелә. Матур сөйләм һәм шигърият илһамчысы булган икенче бер алла ярдәмендә әйберләргә исемнәрне кешеләр үзләре кушкан.

Грек мифологиясендә телне барлыкка китерүче Гермес исемле алла (сәүдә һәм элемтә чаралары яклаучысы) булу турында сюжет бар. Гермес мисырлыларның зирәклек һәм язу алласы Тот белән тиңләштерелә. Борынгы грек фәлсәфәсендә бу идея бик үк популяр булмый, чөнки телнең килеп чыгышы турындагы сорауга табигый дәлилләргә таянып кына җавап бирергә мөмкин дип санала.

Библиядә Сүзнең иясе дип Алла санала; “В начале было Слово, и Слово было у Бога, и Слово было Бог. Оно было в начале у Бога. Все через Него начало быть, и без него ничто не начало быть, что начало быть” (Еванглие от Иоанна). Библия буенча Алла кешеләргә сөйләшү сәләте биргән һәм кешеләр бу сәләтне әйберләргә исем кушу өчен файдаланганнар.

Коръәндә тел кешеләргә Алла тарафыннан бирелгән иң зур нигъмәтләрнең берсе диелә. Мәсәлән, “Тәкәсүр” сүрәсенең 8 нче аятендә: “... Аллаһ сезгә гакыл-фикерне, күз, колак, телне һәм

аяк-кулны дөньяда яшәр өчен генә түгел, бәлки ахирәткә хәзерләнер өчен биргән иде...” дип язылган.

***Аваз ияртемнәре теориясе***

Бу теориягә борынгы грек фәлсәфәсендә стоиклар нигез сала. Аның асылы: сүзләр кешенең табигатьтәге төрле тавышларга охшатып авазлар чыгару омтылышыннан килеп чыккан. Теләсә кайсы телдә шактый күләмдә аваз ияртемнәре дип аталган сүзләр яши. Мәсәлән, рус телендә – *ку-ку, кря-кря, хрю-хрю, дзинь-дзинь, апчхи* һ.б. Алардан ясалган *куковать, крякать, хрюкать* һ.б. сүзләр. “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”ндә аларның саны 800 дән артып китә: *бак-бак, мияу-мияу, тып-тып, һау-һау* һ.б.

Аваз ияртемнәре теориясен тулысынча инкяр итеп булмый, әмма телләрнең сүзлек составында табигатьтәге авазларга охшатып ясалган сүзләр әлләни күп түгел.

***Ымлыклар теориясе***

Бу теория борынгы Грециядә стоикларга каршы лагерь – эпикурчылардан ук килә. Асылы: сүзләр кешенең җан халәтен чагылдыралар. Эпикур (341-270) һәм эпикурчылар кеше сөйләме барлыкка килгәнче башлангыч, физиологик этап үткән дип саныйлар. Әйләнә-тирәдәге әйберләрдән алынган тәэсирләр белән бәйле эмоциональ кычкырыклар (тавышлар) һәм алар тора-бара әлеге предметларны билгели торган сүзләргә әверелгәннәр. Борынгы кешеләрнең инстинктив тавышлары табигый авазларга (ымлыкларга) әйләнгән һәм башка сүзләр дә шул рәвешле барлыкка килгән, имеш.

***Ымнар теле (кинетик) теориясе***

Бу теория асылы белән ымлыклар теориясенә якын, әмма аны тулыландыра һәм киңәйтә. Бу теория буенча, беренче сүз – кешенең эчке дөньясы, бу дөньяның психик хәрәкәтләре тудырган аңсыз продукт. Телнең чишмә башы предметларның ачык, күзгә ташланып торган билгеләреннән килә. Әлеге билгеләр тудырган беренче авазлар эмоциональ кычкырыклар да, предметлар чыгарган тавышларга охшатып ясалган авазлар да булырга мөмкин. Тел үсешенең беренче этабында эмоциональ реакцияләргә кешенең эчке халәтен чагылдырган мимик һәм пантомимик хәрәкәтләр дә өстәлгән. Авазлар ярдәмендә – хисләр,

жестлар ярдәмендә предметлар турында күзаллаулар, кешенең ихтыяры аңлатылган. Кул һәм мимика белән рөхсәт һәм тыю, боеру һәм үтенү, янау һәм мактау белдерелгән. Тора-бара аваз теле камилләшкән, жестлар теле ярдәмче роль генә үти башлаган.

***Иҗтимагый договор (килешү) теориясе***

Иҗтимагый килешү теориясенең төп идеяләрен инглиз фәлсәфәчесе Т.Гоббс (1588-1679) XVII гасырда ук формалаштыра. Аның фикеренчә, кешеләр, китап басуны уйлап тапкан кебек, телне уйлап тапканнар. Борынгы кешеләрнең башына әйберләргә "исем кушу" фикере килгән. Шул исемнәр ярдәмендә кешеләр үз фикерләрен хәтерләрендә саклау һәм аларны үзара файдалы итеп бер-берсенә тапшыру мөмкинлегенә ия булганнар.

***Хезмәт тавышлары (кычкырыклары) теориясе***

Бу теориянең асылы телнең килеп чыгышын коллектив хезмәт вакытында туган тавышларга бәйләп калдырудан гыйбарәт. Бергә эшләгәндә чыккан тавышлар хезмәтне җиңеләйткәннәр һәм оештырганнар. Башта кешеләр эшләгәндә табигый предметлардан файдаланганнар. Тора-бара хезмәт кораллары ясый башлаганнар, бу аларның хезмәтен ритмга салырга булышкан. Эшләгәндә кешеләр теге яки бу дәрәҗәдә ритмик тавышлар чыгарырга өйрәнгәннәр. Башта ирексездән әйтелгән бу тавышлар әкренләп хезмәт процессының символына әйләнеп киткән. Шул рәвешчә, беренче тел фигыль тамырларыннан гыйбарәт булган. Хезмәт тавышлары теориясен, асылда, ымлыклар теориясенең бер варианты дип карарга була.

## 3. Телнең килеп чыгуына карата хәзерге фәндәге карашлар.

Телнең килеп чыгуы күп кенә тышкы һәм эчке факторларга бәйле булган дип карала:

- табигый, шул исәптән космик шартлар;
- биологик (антропологик) алшартлар;
- җәмгыять һәм кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең характеры;
- хезмәт, предметлы эшчәнлек һ.б.

Тышкы, ягъни табигый шартлар Җирдә тормышның булуын гына түгел, бер үк вакытта телнең дә яшәешенә мөмкинлек тудырган. Чөнки тел бары тик Җир тирәсендә һава сүрүе булганда гына барлыкка килә ала (һава барлык тереклек ияләренә сулау һәм аваз чыгару өчен мөһим). Димәк, әлеге табигый шартлар телнең төп берәмлеге – аваз барлыкка килү өчен алшарт булып торган.

Телнең килеп чыгуында икенче әһәмиятле шарт – биологик алшартлар, алардан башка телнең барлыкка килүе турындагы мәсьәләне куеп та булмас иде. Боларга кешенең туры басуы барлык органнарының башкача төркемләнүенә китергән. Бу бигрәк тә сөйләм барлыкка китерүдә һәм сөйләмне кабул итүдә катнаша торган органнарга кагыла. Антропологлар фикеренчә, бары тик әлеге шартлар булганда гына аңлаешлы, анык авазлар туа алган.

Кешенең вертикаль хәләтенә бәйле рәвештә алгы очлыкларның бушавы кешенең үз-үзен тотышын үзгәрткән, эшгамәлләрен, эшчәнлеген катлауландырган. Кеше кораллардан файдалана башлаган, бу аны хайваннардан аера барган.

Хезмәтнең үсеше җәмгыять әгъзаларының тыгызрак туплануына ярдәм иткән, чөнки хезмәт үсеше аркасында бергәләп эшләү очраклары ешайган һәм бу рәвешле эшләүнең һәр кеше өчен файдалы булуы ачыклана барган. Әлеге процесста кешеләрнең бер-берсенә нәрсәдер әйтү ихтыяҗы туган.

Гәүдәнең туры торуы кешенең күз күремен киңәйтә, әйләнәтирәне кабул итүгә һәм аны чагылдыруга тәэсир итә, аваз дулкыннарының чагыштырмача ерак араларга иркен таралуына мөмкинлек бирә. Кешенең туры басуы аңа хезмәт эшчәнлегендә генә булышып калмаган, бәлки билгеле бер органнарны тел барлыкка китерүдә кулланырга ярдәм иткән, ягъни бу органнарның икенчел функцияләрен тудырган.

Телнең килеп чыгуы турындагы теорияләргә, гипотеза һәм карашларга таянып, түбәндәге нәтиҗәләрне ясап була:

1. Телнең килеп чыгу мәсьәләсен тел белгечләре генә хәл итә алмый, ул төрле фәннәргә (этнография, антропология, археология, палеонтология һ.б.) карый.

2. Телнең килеп чыгышын фәнни яктан исбатлап булмый, бары теге яки бу дәрәҗәдә ихтимал фаразлар гына корырга мөмкин.

3. Телнең килеп чыгуын кеше барлыкка килүдән аерып карарга ярамый.

4. Тел кеше белән бергә барлыкка килгән икән, димәк, кешелекнең телсез чоры булмаган.

5. Тел кешенең иң беренче “билге”ләреннән берсе булган; телдән башка кеше “кеше” булмас иде.

6. Тел иң әһәмиятле аралашу чарасы икән, димәк, ул аралашуга ихтыяҗ барлыкка килгәч формалашкан.

7. Тел хайваннарда булмаган төшенчәләрне белдерү өчен кирәк, тел белән бергә шул төшенчәләрнең дә булуы кешене башка җан ияләреннән аера.

8. Беренчел тел турындагы фактларда чын телнең барлык функцияләре чагылыш табарга тиеш: а) тел хәбәр итә; ә) чынбарлыктагы күренешләрне һәм әйберләрне атый; б) төшенчә белдерә; в) теләк һәм хисләрне аңлата. Болардан башка тел “тел” була алмый.

9. Кешенең теле, барлыкка килгәндә үк, аваз теле булган.

10. Телнеке булмаган аралашу чаралары (жестлар, хәрәкәтләр, мимика һ.б.) аваз теле белән параллель кулланылган.

**4. Телләр үсешендә төп процесслар.**

Хәзерге кешенең бик борынгы формалары (homo sapiens) Җирнең уңай климатлы районнарында – Урта диңгез буенда (Азиянең алгы өлеше, Көнчыгыш Европа, Төньяк Африка) яшәгәннәр. Евразиянең кеше яшәми торган киңлекләре һәм түбән җитештерүчәнлек аларны Җирнең башка урыннарына да чәчелергә мәҗбүр иткән. Шул рәвешчә алар хуҗалык рәвеше һәм телләре ягыннан аерылып торган коллективларга әйләнгәннәр. Җылы климаттан салкын климатка күчү торакка һәм кием-салымга, йорт хайваннарына, хезмәтнең яңа төрләренә ихтыяҗ тудырган. Хезмәт үзе буыннан-буынга төрлеләнә һәм камилләшә барган. Озын-озак үсеш кичергән кеше сөйләменнән төрле телләр һәм диалектлар барлыкка килгән.

Шул рәвешле, телләр үсешендәге ике төп процесс күзаллана: телләр яки диалектлар бүленү һәм кушылу. Алар бер-берсенә капма-каршы күренешләр. Телләр бүленү күренеше ***дифференциация*** яки ***дивергенция*** дип атала, бу вакытта бер телдә сөйләшүчеләр территория һәм иҗтимагый яктан таралып урнашалар, шуның нәтиҗәсендә кардәш телләр һәм диалектлар барлыкка килә. Дифференциация телләрнең саны артуга китерә. Телләр кушылу процессы ***интеграция*** яки ***конвергенция*** дип атала, бу очракта телләр һәм диалектлар берләшә, нәтиҗәдә, телләр саны кими. Дифференциация дә, интеграция дә – иҗтимагый күренешләр, телләрнең бүленүе һәм кушылуы икътисади, хәрби, сәяси, мәдәни һәм фәнни сәбәпләр белән аңлатыла. Нәкъ менә шул факторлар аерым телләрнең конкрет үзенчәлекләрен билгелиләр.

Конвергенция һәм дивергенция процесслары капма-каршы юнәлешләрдә төрле тизлек белән, төрле вакытта бара. Ыруглык җәмгыятендә телләрнең һәм диалектларның бер-берсеннән ерагаю күренеше көчлерәк була, бу кешеләрнең төрле яңа территорияләргә күченеп урнашу хәрәкәте белән аңлатыла. Феодализм чорында дәүләтләр барлыкка килү уртак телгә ихтыяҗ тудырганлыктан, кардәш телләр һәм диалектлар берникадәр якыная башлый, бу процесс хәзер дә дәвам итә. Ләкин бу ике процессны бер-бер артлы бара торган күренешләр дип аңлау дөрес булмас. Тарих дәвамында бу ике процесс бер-берсен алыштырырга да мөмкин, ләкин, гомумән алганда, телнең үсеше беркайчан да бу ике процессның берсенә генә кайтып калмый.

Дивергенция төшенчәсен, күп очракта, кардәш телләрнең яки бер тел диалектларының үсеш процессына бәйләп кулланалар. Үсешнең мондый юнәлеше иҗтимагый-тарихи шартлар белән бәйле. Кардәш этносларның миграция юллары кайчакта туры килмәскә мөмкин (аеруча, халык тыгыз урнашкан территорияләрдә). Бу – аларның географик аерымлануына китерә. Моннан тыш кардәш этнослар (яки бер этносның аерым өлешләре) төрле илләр составына керү нәтиҗәсендә таркалырга мөмкин.

Һәр этнос үзенең ареалында башка кардәш яки кардәш булмаган этнослар белән мөнәсәбәткә керә. Бу мөнәсәбәтләр тел һәм диалект арасындагы аермалыкларга китерә. Дивергенция процесслары бер

этносның зур территориядә утыруы яки элек бердәм булган телнең / диалектларның таркалуы нәтиҗәсендә урын алырга мөмкин. Бу исә үз чиратында, кардәшлек мөнәсәбәтләрендә булган, тел гаиләсе барлыкка китергән, аерым мөстәкыйль телләр туугa сәбәп була. Кардәш телләр нәсел башы булган баба телнең (праязык) дәвамчылары булып тора.

Телнең дивергенциясенә сәбәп булган факторлар белән беррәттән, телдә конвергенциягә китерүче факторлар да аз түгел. Бер үк илдә урын алган, озак һәм интенсив мөнәсәбәтләргә юлыккан, бер территориядә яшәүче, ләкин төрле телләрдә (диалектларда) сөйләшүче этнослар конвергенциягә дучар була. Конвергенция процесслары кардәш һәм кардәш булмаган телләрне, шулай ук бер телнең төрле диалектларын үз эченә алырга мөмкин. Бу процесслар лексик алынмаларга, фонологик, морфологик, синтаксик системаларның структур үзгәртелеп корылуына китерергә мөмкин.

## 5. Төрле тарихи чорларда телләрнең һәм диалектларның үсеше.

***Кабилә диалектлары һәм кардәш телләр барлыкка килү***

Аз санлы кешеләрдән торган телләр ыруглык җәмгыятенә хас күренеш була. Ыруг борынгы кешеләр көтүе базасында барлыкка килә, анда туганнар арасында никах рөхсәт ителми (экзогамия), ике яки берничә ыруг кабиләгә берләшә, алар бер территориядә яшиләр, үзләренең исемнәре һәм гомуми телләре була, диалектларда аермалар яши. Берничә ыругны берләштергән һәр кабилә үзенә генә хас теле белән аерылган. Вакытлар узу белән, төрле факторлар тәэсирендә теге яки бу кабиләләр берничә мөстәкыйль кардәш кабиләгә таркалган. Аларның күчеп утырулары кайчандыр гомуми булган телдә үзгәрешләр тудырган, кабилә диалектлары барлыкка китергән. Телләрнең таралышы ике юл белән барган: бер яктан, халыкның табигый рәвештә артуы һәм буш территорияләргә күчеп утыруы (миграция); икенче яктан, бер телнең икенче тел тарафыннан кысрыклануы. Территориаль таралыш вакыт үтү белән телләрдә аерымлыклар китереп чыгарган. Кардәш диалектлар әкренләп бер-берсеннән ерагайган, мөстәкыйль телләр формалашкан.

Әмма бер чыганакка барып тоташучы телләр гомуми тамырлар, аффикслар, бердәм фонетик закончалыкларын саклыйлар. Кардәш телләр барлыкка килү – кешелек теленең үсеш үзенчәлекләреннән берсе.

Алга таба берничә кабиләнең кабилә союзына берләшүе, кабилә эчендәге тыгыз бәйләнешләр аларның телләрендә һәм диалектларында охшаш сыйфатларны арттырган. Кайчак көчлерәк төркемнең теле җиңеп чыккан, көчсезләре җиңүчеләрнең телен үзләштерергә тиеш булган. Кагыйдә буларак, бер кабилә союзына кардәш кабиләләр берләшкәнлектән, кабилә союзының теле дә генетик гомумилекне саклаган. Бер телдән килеп чыгу күрсәткече булып *гомум баба тел* хезмәт итә.

### ***Халык телләре барлыкка килү***

Борынгы ыруглык җәмгыяте таркалып, хосусый милекчелек мөнәсәбәтләре һәм сыйныфлар барлыкка килгәч, кабиләләргә алмашка халыклар килә, ягъни халыклар кабиләләр һәм кабилә союзлары нигезендә оеша. Нәтиҗәдә *халык телләре* формалаша башлый. Иҗтимагый-тарихи берләшмә буларак халык территория, мәдәният һәм тел бердәмлеген күздә тота. Европада халыклар һәм аларның телләре феодализм үсеше белән бәйле рәвештә, IX-X гасырларда формалаша.

Феодализм кабилә берләшмәләрен һәм вак кабилә телләрен юкка чыгара. Ул кешеләрнең һәм телләрнең территориаль, икътисадый һәм сәяси багланышлар нигезендә таркалу тенденциясен барлыкка китерә. Кабилә диалектлары, акрынлап, бер гомуми телнең һәм халыкның җирле теле булган өлкә диалектлары белән алышына. Феодаль җәмгыятьтә диалект барыннан да элек җирле берәмлек, чөнки билгеле бер диалектта шул территориядә яшәүче барлык халык – крестьяннар да, феодаллар да сөйләшә.

Язу барлыкка килү һәм таралуга бәйле рәвештә, язма телләр формалаша башлый. Телнең язма формасы барлык халыкларда да эшкәртелми. Кайбер очракларда билгеле бер еллар дәвамында язма тел функциясен башка бер чит тел башкара. Мәсәлән, урта гасырларда Европада – латин теле, Якын Көнчыгышта гарәп теле кулланыла. Монголиядә бу чорда берничә язма тел була:

рәсми документлар маньчжур телендә языла, ә дини өлкәдә тибет теле гамәлдә була. Массакүләм наданлык шартларында язма телгә бик тар катлам кешеләр генә өйрәнә. Язма тел консерватив була, ул абруйлы үрнәкләргә таяна; ә сөйләм теле исә үз законнары буенча үсә. Тора-бара язма тел һәм сөйләм теле арасында аерма арта.

Халыклар формалашу процессы әле дә тәмамланмаган, хәзерге вакытта ул Азия, Көньяк Америка, Океаниядәге кайбер илләрдә дәвам итә.

***Милли әдәби телләр барлыкка килү***

Феодаль таркаулыкны бетерү һәм капитализм үсеше белән халыклар милләтләр булып оеша һәм халык телләре *милли тел* дәрәҗәсенә үсә. Милли тел әдәби телнең иң югары формасы санала, ул милләт барлыкка килгән чорда формалаша. Бу процесс механик, турыдан-туры әверелеш кенә булмый, әлбәттә. Кайбер очракларда халык теле милли телгә әйләнми, икенче бер очракта бер халык теленнән берничә милли тел килеп чыга. Европада милләтләр формалашу капитализм чорына туры килә.

Милли телләр өч юл белән барлыкка килә дип билгелиләр: 1) булган материалның үсеше нигезендә (мәсәлән, инглиз теле); 2) диалектларның туплануы нәтиҗәсендә (мәсәлән, рус теле); 3) телләр һәм диалектлар кушылу аркасында (инглиз теле). Төрле телләрдә әлеге юллар төрлечә чагыла, шул ук вакытта бер генә юл белән барлыкка килгән милли тел дә юк.

Милли тел, халык теле кебек, телдән аралашу өлкәсендә генә кулланылып калмый, ә мәҗбүри рәвештә әдәби тел сыйфатында язма аралашу теле булып йөри. Әдәби тел (литературный язык) сүзгә сүз тәрҗемә иткәндә язма тел дигәнне аңлата (латинча “литера” – хәреф дигән сүз), шуңа күрә милли телләрнең язма формасы булу зарур. Әмма телнең язма формасы булу аның милли тел булуына дәлил дә булып тора алмый. Халыкның белем дәрәҗәсе күтәрелү белән язма тел киң халык массаларының аралашу коралына әйләнә. Язма тел функциясен чит тел үтәгән җирләрдә дә язу әкренләп халык теленә күчә. Матур әдәбият артыннан фән дә, сирәк кенә булса да, дин дә халык теленә якыная. Бу чорда бердәм нормалы язма һәм сөйләмә әдәби тел мәсьәләсе күтәрелә башлый. Бердәм телгә

ихтыяҗ һәм әдәби тел арасында каршылык туа. Күпчелек очракта бу проблема түбәндәгечә хәл ителә: бердәм нормалар нигезе итеп тарихи үсеш барышында беренче урынга чыккан (чыгарылган) бер диалект алына. Мәсәлән, рус әдәби теле Мәскәү һәм аның тирәсендәге сөйләшләргә нигезләнә. Билгеле, әдәби тел нормалары башкала диалекты үзенчәлекләрен күчереп кенә алмый, аның формалашуында башка диалектларның да тәэсире зур була.

Шул рәвешчә, телләр үсешендә тарихи закончалык күзәтелә: кабилә телләренә һәм диалектларына алмашка еш кына язма формага да ия булган халык телләре һәм диалектлары килә; аннан әдәби формасы да булган милли телләр мәйданга чыга. Бу закончалыктан телләр язмышының халык язмышыннан аерылгысыз булуы күренә. Кабилә телләреннән башта халык, аннары милләт теленә таба закончалыклы хәрәкәт җәмгыять, халык, дәүләт үсешенә бәйләнгән. Әмма телләрнең аерым якларындагы үзгәрешне җәмгыять үсеше белән генә аңлатып бетереп булмый.

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар**

1. Телләрнең барлыкка килү проблемасы турында сөйләгез.
2. Телләрнең килеп чыгуы турында нинди теорияләр бар?
3. Телләрнең килеп чыгышын бүгенге фән ничек аңлата?
4. Телләрнең үсешендә нинди төп процессларны атый аласыз?

## Тема: ДӨНЬЯДАГЫ ТЕЛЛӘР ҺӘМ АЛАРНЫ ТӨРКЕМЛӘҮ ПРИНЦИПЛАРЫ

1. Дөньядагы телләр һәм аларны төркемләү.
2. Телләрне төркемләү принциплары.
3. Телләрнең генеалогик классификациясе.
4. Тел гаиләләре.
5. Телләр типологик классификациясе.
6. Телләрнең ареаль классификациясе.
7. Телләрнең функциональ классификациясе.

### 1. Дөньядагы телләр һәм аларны төркемләү.

Җир шарында төрле чорларда төрле сандагы халык яшәгән. Чама белән палеолит чоры ахырында (б.э.к. 2 меңенче ел) җирдә 3 миллион тирәсе кеше булган. Неолит ахырына бу сан 50

миллионга җиткән. Безнең эра башында Җир шарында 230 миллион халык тормыш иткән. Беренче меңьеллык ахырында аларның саны 275 миллион булган. 1800 елда – 1 млрд.; 1900 елда – 1,6 млрд.; 1960 елда – 3 млрд.; 1999 елның 12 октябренә – 6 млрд.; 2009 елның 1 июленә китерелгән мәгълүмат буенча Җир шарында барлыгы 6 768 167 712 кеше яши дип исәпләнә[5]. 2011 елның 31 октябрендә Җир шарындагы 7 миллиардка җитте[6]. Шушы кадәр халык үзара бик күп телләрдә сөйләшә һәм аралаша.

Җир шарындагы табигый юл белән (кешенең һәм аерым этносларның биологик-социаль үсеше нәтиҗәсендә) килеп чыккан телләрнең санын төгәл генә билгеләү мөмкин түгел. Фәндә мең ярым-ике мең тел турында сүз алып барыла, ләкин бик еш аларның саны өч, дүрт, биш, алты, җиде, сигез меңгә кадәр җитә. 1982 елда СССРның ФА Тел белеме институты тарафыннан әзерләнгән "Дөнья телләре һәм диалектлары" дип аталган белешмәлегендә, 30 меңләп "диалект" дигән тамга астындагы лингвонимнарны исәпләмәгәндә, барлыгы 8 меңнән артыграк "чиста" тел бирелә. АКШдагы Лингвистика җәйге институты (Summer Institute of Linguistics) тарафыннан әзерләнгән исемлектә исә барлыгы 6 700 дән артык тел күрсәтелә.

Шул рәвешчә, дөньядагы телләрнең төгәл санын билгеләү бик кыен. Моның сәбәпләре төрле булырга мөмкин. Әмма шунысы мәгълүм: дөньяда телләр бик күп һәм аларны бер-берсеннән аерып тора торган билгеләр дә, охшаш сыйфатлар да җитәрлек. Менә шулар телләрне төркемләүгә этәргеч бирәләр.

## 2. Телләрне төркемләү принциплары.

Телләрне төркемләү – дөнья телләрен билгеле бер уртак сыйфатлары буенча бүлү дигән сүз. Әлеге уртак сыйфатлар тикшеренүләр нәтиҗәсенә бәйле рәвештә табыла. Шунлыктан телләрне төркемләүгә төрле яклап якын килергә мөмкин. Тел белемендә шундый берничә классификация яшәп килә, алар арасында дүртесе төп (ареаль, генеалогик, типологик һәм

[5] Википедия энциклопедиясе мәгълүматлары буенча.
[6] БМО фаразларына караганда, 2100 елга кешеләр саны 10 миллиардка җитәргә мөмкин.

функциональ) классификация[7] санала. Шулай да генеалогик һәм типологик классификацияләр чагыштырмача яхшырак эшкәртелгән.

Телләр әле җитәрлек өйрәнелмәгән очракта, алар турында мәгълүматлар аз булганда телләрне төркемләүдә *географик* яки *территориаль принцип* сайлап алына. Телләр турында мәгълүматлар тирәнәйгән саен, алар арасындагы кардәшлек мөнәсәбәтләренә, аларның типологик охшашлыкларына игътибар арта. Шул рәвешчә, телләрне төркемләүдә *генеалогик* һәм *типологик принциплар* барлыкка килә. Генеалогик классификация телләрнең кардәшлегенә, бер уртак телдән килеп чыгуларына нигезләнә. Типологик яки структур-типологик классификация нигезендә телләрнең тышкы охшашлыклары ята. *Ареаль классификация* генеалогик һәм типологик классификацияләрнең казанышларыннан файдалана, ул дөньяда телләрнең һәм тел күренешләренең таралыш ареалларын өйрәнүне күздә тота. *Функциональ классификация* телләрнең үтәгән мәдәни һәм иҗтимагый функцияләрен барлый.

**3. Телләрнең генеалогик классификациясе.**

***Генеалогик классификация*** телләрнең тарихи кардәшлегенә нигезләнә һәм ул халыкларның тарихи язмышы белән тыгыз бәйләнгән. Телләрнең кардәшлеген өйрәнү чагыштырма-тарихи тел белеменә карый. Чагыштырма-тарихи метод телләрнең тарихи үткәнен ачыклауга багышланган чагыштыруларны күздә тота. Дөнья телләрен кардәшлек буенча төркемләү теге яки бу телләрнең бер телдән килеп чыгуын өйрәнә. Мондый телне *нигез тел* яки *баба тел* диләр. *Баба тел* – кардәш телләр төркеменең нәсел башы, ул телләрнең үсеш тарихында төрле кардәш телләргә таркала.

Кардәшлек билгеләре буенча телләр берничә зур төркемгә бүленә. Бөтен кардәш телләрне үзенә җыйган телләр берләшмәсе *гаилә* дип атала. Бер тел гаиләсенә кергән телләрнең

[7] Классификацияләр саны шулай ук төрле хезмәтләрдә төрлечә. А.А.Гируцкий 4 классификация турында искә ала; Ф.С.Сафиуллина хезмәтендә генеалогик һәм морфологик классификацияләр турында сүз алып барыла; А.А.Реформатский ике генә классификация бар дип билгели; В.И.Кодуховта 4 классификация турында мәгълүмат бирелә һ.б.

төзелешендә нигез телгә барып тоташа торган уртак сыйфатлар була. Гаилә эчендәге телләрнең кардәшлеге якын да, ераграк та булырга мөмкин, шуңа бәйле рәвештә гаилә эчендә телләр *төркем*нәргә, төркемнәр – *төркемчә*ләргә таркала.

Хәзерге тел белемендә тел гаиләләренең саны төгәл билгеле түгел, бу күпмедер дәрәҗәдә телләрнең өйрәнелеп җитмәве белән дә аңлатыла. Шунлыктан тел гаиләләре төрле хезмәтләрдә төрлечә билгеләнә. Генеалогик классификацияләрнең күпчелегендә искә алынган тел гаиләләре әллә ни күп түгел. Алар түбәндәгеләр (бәхәсле моментларның да булуын истә тоткан хәлдә, 15 тел гаиләсен билгеләгән бүленеш бирелә)[8]: ***һинд-европа, семит-хәмит (афразия), кавказ, дравид, урал, алтай, чукот-камчатка, нигер-кордофан, нил-сахара, койсан, кытай-тибет, тай, австро-азиат, австронезия, эскимос-алеут телләре гаиләләре***[9].

**4. Тел гаиләләре.**

***Һинд-европа телләре гаиләсе*** иң күп таралган һәм күпсанлы халыклар сөйләшә торган телләрне үз эченә ала. Һинд-европа халыклары Европаның (Россияне дә кертеп) зур өлешендә, Әрмәнстан, Таҗикстан, Иран, Әфганстан, Көньяк Азиянең төньяк һәм үзәк районнарында, Америка, Австралиядә яшиләр. Һинд-европа телләре 12 төркемгә бүленә:

1) *һинд* төркеменә һинди һәм урду (һиндустани), бенгали, панджаби, непали, чегән һ.б. телләр керә. Үле телләр – санскрит һәм пракрит;

2) *иран* төркеме һинд төркеменә аеруча якын. Аңа фарсы, әфган, таҗик, көрт, осетин һ.б. телләр керә. Бу төркемдә үле телләр дә шактый – борынгы фарсы, авеста, лидий, пәхләви, скиф һ.б.;

3) *славян* төркеме үз эчендә өч төркемчәгә аерыла: көнчыгыш төркемчә (рус, украин, белорус телләре), көнбатыш төркемчә (чех, словак, поляк, кошуб, үле полаб телләре), көньяк төркемчә (болгар, серб-хорват, македон, словен, үле иске славян телләре);

4) б*алтыйк* төркеме зур түгел. Аңа литва, латыш телләре һәм үле прусс теле керә;

---

[8] Сафиуллина Ф.С. Тел белеменә кереш. – Б. 269-270.
[9] Кайбер мәгълүматлар төрле хезмәтләрдә берникадәр аерылырга мөмкин.

5) *герман* төркемен гадәттә икегә (өчкә) бүләләр: төньяк герман (Скандинавия) төркемчәсе (дат, швед, норвег, исланд, фарёр телләре һ.б.), көнбатыш герман төркемчәсе (инглиз, голланд, фриз, немец, идиш телләре). Өченчесе – көнчыгыш герман төркемчәсе, ул үле телләрдән (вестгот һәм остгот телләре) генә тора;

6) *роман* төркеменә француз, итальян, испан, португал, румын, молдаван һ.б. телләр керә. Үле телләрдән – латин теле;

7) *кельт* төркеменә ирланд, шотланд, бретон, валлий телләре һәм үле галль, корноуль телләре керә.

*Әрмән, грек, албан* телләре үзләре генә аерым төркем хасыйл итәләр. *Хетт* һәм *тохар* төркемнәрендә бары тик үле телләр генә булуы мәгълүм.

***Семит-хәмит (афразия) телләре гаиләсе.*** Бу гаилә дөньядагы 5% халыкны үз эченә ала дип исәплиләр, алар Төньяк һәм Төньяк-көнчыгыш Африкада, Гарәбстан ярымутравында һәм аңа төньяктан чиктәш булган илләрдә (Сирия, Ливан, Иордания, Иордан елгасының көнбатыш яры, Гыйрак) яшиләр. Бу гаилә алты тел төркемен берләштерә:

1) *бәрбәр-ливий телләре* төркеменең тере телләре Төньяк Африкада Мисыр һәм Ливиядән Мавританиягә кадәр таралган, шулай ук Сахара оазисларында, Нигерия, Сенегалда да очрый. Марокко халкының 40%-ы, Алжирда 25% халык бәрбәр телендә сөйләшә. Мисыр, Ливия, Тунис, Мавританиядә бәрбәр телендә сөйләшүчеләр азрак. Тере телләрнең күбесендә язу юк. Туарег кабиләсендә (Сахарада) көнкүрештә тифинаг дигән язу кулланыла;

2) *борынгы Мисыр теле* – үле тел. Нилның урта һәм түбәнге үзәнлекләрендә таралган була (хәзерге Мисыр). Беренче язма истәлекләр б.э.к. IV гасыр ахыры – III гасыр башы белән билгеләнә. Бу тел б.э.ның V гасырына кадәр яшәгән. Аңа якын кардәш телләр табылмаган;

3) *кушит телләре* төркемендә тере телләр генә билгеле, алар Төньяк-Көнчыгыш Африкада (Суданның төньяк-көнчыгышында, Эфиопия, Джибути, Сомали, Кениянең төньягында, Танзаниянең көнбатышында) таралган;

4) *омот телләре* – тере, язусыз телләр, Эфиопиянең көньяк-көнбатышында таралган. Афразия телләр гаиләсенең аерым тармагы буларак соңгы елларда гына карала башлады;

5) *семит телләре* төркеме – телләр саны ягыннан караганда иң зуры. Хәзерге тере телләрдән гарәп, мальта, иврит, эфиосемит (амхар, тигре, тиграй) һ.б. телләр керә. Бу телләр Гарәп Көнчыгышы, Израиль, Эфиопия һәм Төньяк Африкада таралган, урыны-урыны белән Азия һәм Африканың башка илләрендә дә очрый;

6) *чад телләре* төркеменә якынча 150 тере тел һәм диалект төркемнәре керә. Үзәк һәм Көнбатыш Суданда, Чад күле районында, Нигерия, Камерунда таралганнар.

***Кавказ телләре гаиләсе*** үз эченә Кавказ төбәгендә таралган 40 тан артык җирле телне ала. Бу телләрдә сөйләшүчеләрнең 50% чамасы – грузиннар, 10%-тан артыгы – чеченнар. Бу гаилә телләренең кардәшлеге фән тарафыннан хәл ителеп бетмәгән. Әлеге гаилә телләрен тарихи-генетик яктан өч төркемгә бүләргә мөмкин:

1) *көнбатыш төркем – абхаз-адыг телләре* (абхаз, абазин, адыгей, кабардин, убых һ.б. телләр);

2) *көнчыгыш төркем – нах-дагестан телләре* (чечен, ингуш, авар, даргин, лак, лезгин, табасаран һ.б. телләр);

3) *көньяк төркем – картвель телләре* (мегрель, лаз, грузин, сван һ.б. телләр). Кайбер классификацияләрдә бу төркем аерым гаилә итеп карала башлады.

***Дравид телләре гаиләсе*** Һиндстанның көньягында һәм Шри-Ланканың төньяк-көнчыгышында яшәүчеләрне берләштерә. Бу гаиләгә, нигездә, Һиндстанга европалылар килгәнчегә кадәр яшәгән җирле халыкларның телләре керә. Дравид телләренең төгәл санын билгеләү шактый кыен, чөнки бу телләрнең материалы тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәгән. Хәзерге минималь бәяләүләр буенча 25 ләп, ә күп дигәндә 80 чамасы тел керә. Дравид телләрендә сөйләшүчеләрнең саны Һиндстан халкының гомуми саны артуга бәйле рәвештә үсә бара. Бу гаилә телләренең генеалогик классификациясе бүгенге көндә бәхәсле кала. Дравид

телләрендә сөйләшүчеләрнең 90%-ы дүрт “зур” телдә – *телугу, тамиль, малаялам, каннада* телләрендә сөйләшә: Тел гаиләсе эчендә дүрт төркем аерыла (башка классификацияләр дә бар):

1) *көньяк төркем;*
2) *үзәк төркем;*
3) *төньяк-көнчыгыш төркем;*
4) *төньяк-көнбатыш төркем.*

***Урал телләре гаиләсе***нә кергән телләр Россиядә, Эстония, Венгрия, Финляндия һәм Скандинавиянең төньягында таралган. Гаилә эчендә ике тармак аерыла:

1) *фин-угор тармагы*ның үз эчендә 4 төркемчә:

– балтыйк буе-фин төркемчәсе (фин, эстон, карель һ.б. телләрдән тора);

– пермь төркемчәсе (удмурд, коми-зырян, коми-пермяк һ.б. телләреннән гыйбарәт);

– Идел буе төркемчәсе (мари, мордва һ.б. телләрне үз эченә ала);

– угор төркемчәсе (венгр, хантый, мансый һ.б. телләрне берләштерә);

2) *самодий тармагы* (ненец, энец, нганасан, селькуп һ.б. телләр керә). Кайбер аз санлы халыклар юкка чыгу чигендә тора, ә *вод* теле инде үле телгә әйләнгән булса кирәк, дүрт самодий теленең дә өчесе үлеп бара.

***Алтай телләре гаиләсе*** дөнья халкының якынча 6%-ын берләштерә, Балкан ярымутравыннан алып Япон утрауларына кадәр һәм Төньяк Боз океаныннан Үзәк Азиягә чаклы тоташмаган ареалларны үз эченә ала. 4 төркемгә бүленә: *төрки* (30 лап тере һәм үле тел), *монгол, тунгус-маньчжур* һәм *япон-корея* (соңгысы аерым да карала). Бу төркемнәр үз эчендә түбәндәгечә сурәтләнә.

1. *Төрки* телләр ике тармакка бүленә:

а) *көнбатыш хун* тармагы эчендә түбәндәге төркемчәләр аерыла:

– болгар төркемчәсе (болгар, чуваш телләре керә),

– кыпчак төркемчәсе (караим, комык, карачай-балкар, татар, башкорт, каракалпак, казах, ногай телләре һ.б.),

– угыз төркемчәсе (төрекмән, әзербайҗан, төрек, кырым татарлары теле һ.б.);

– карлук төркемчәсе (үзбәк, уйгыр телләре);

ә) *көнчыгыш хун* тармагы ике төркемнән тора:

– уйгыр-угыз төркеме (тува, тофалар, якут (долган), сары уйгырлар, хакас, шор һ.б. телләр);

– кыргыз-кыпчак төркеме (кыргыз, алтай (телеут) һ.б. телләр).

2. *Монгол* телләренә хәзерге монгол (халха) теле, бурят, калмык, ойрат һ.б. телләр керә;

3. *Тунгус-маньчжур* телләренә әкренләп югала бара торган эвенк, эвен, маньчжур телләре карый.

4. *Япон* һәм *корея* телләре, озак вакытлар генеалогик классификациядә урыннарын таба алмый йөргәннән соң гына, соңгы елларда гына Алтай телләре гаиләсенә кертеп карала башладылар.

***Чукот-камчатка телләре гаиләсе*** аз санлы гаилә, бу телләр Россиянең ерак төньяк-көнчыгышында (Себердә) таралган. Бу гаиләне икенче төрле шартлы рәвештә ***палеоазиат телләре*** дип тә йөртәләр һәм аңа географик билгеләре ягыннан палеоазиат телләрен дә кертеп карыйлар. Палеоазиат телләрен ике төркемгә бүләләр:

1) Чукотка һәм Коряк милли округында, Якутиядә таралган *чукот-камчат төркеме* (чукот, коряк, ительмен, алютор, керек телләре);

2) *себер (Енисей) төркеме* (кет, юкогир, нивх телләре), алары күбрәк Красноярск өлкәсендә таралган.

Кайбер хезмәтләрдә эскимос-алеут телләре дә бу гаиләгә кертелә.

***Нигер-кордофан гаиләсе*** халыклары (дөнья халкының якынча 6%-ы) күбрәк Көнбатыш, Үзәк, Көнчыгыш һәм Көньяк Африкада (Синегалдан КАРга кадәр) таралганнар. Әлеге гаиләне макрогаилә дип исәпләп, 10 тел гаиләсеннән тора дип уйлыйлар:

1) *кордофан* гаиләсе Судандагы 20ләп кечкенә телне берләштерә;

2) *манде* телләре Көнбатыш Суданның үзәгендә таралган;

3) *атлантик* гаилә үз эчендә 7 төркемне ала;

4) *иджоид* телләре (10лап тел) Нигер елгасы култыгында таралган;

5) *догон* гаиләсе – Нигер елгасының көньяк-көнчыгышында таралган берничә кардәш телдән гыйбарәт;

6) *кру* гаиләсе көнбатыш һәм көнчыгыш тармаклардан тора, 35-40 чамасы тел керә;

7) *сенуфо* теле элек гур гаиләсенә кертеп каралган, соңгы вакытларда аерым тел гаиләсе төзи дип фаразлана;

8) *саванна* телләре гаиләсе гур һәм адамава-убагин төркемнәреннән гыйбарәт, аңа 230лап тел керә;

9) *ква* гаиләсе Көнбатыш Суданның көньягында таралган 80ләп телне үз эченә ала;

10) *бенуэ-конголез* – Африкадагы күп санлы телләрдән гыйбарәт булган иң зур тел гаиләсе. Бениннан Сомалига һәм көньяктан КАРга кадәр булган бик зур территориягә таралган, 900ләп тел керә.

***Нил-сахара телләре гаиләсе*** (дөнья халкының якынча 0,6%-ы) – афразия һәм нигер-конго гаиләләренә кергән телләр арасында таралган, әмма аларның берсенә дә кермәгән Африка телләреннән гыйбарәт булган гипотетик макрогаилә. Бу телләр Малидан Эфиопиягә, Мисырдан Танзаниягә кадәр территориядә таралганнар. Нил-сахара телләрендә сөйләшүчеләр катнаш европалы-нигероид расага карый. Нил-сахара гипотезасы буенча, бу макрогаилә 9 тел гаиләсе һәм берничә изолят телдән тора:

1) *сонгай телләре* гаиләсе (Нигер һәм Мали) якынча 10 телне үз эченә ала;

2) *сахара телләре* гаиләсе (Чад күле буенда Сахараның бер чите) 10лап телдән гыйбарәт;

3) м*абан телләре* гаиләсе (Чадның Судан белән чиктәш көньяк-көнчыгыш өлеше) 5-10 телдән тора;

4) *фор телләре* гаиләсенә Чадның көнчыгышындагы һәм Суданның көнбатышындагы ике генә тел керә;

5) *үзәк Судан телләре* гаиләсе көнбатыш һәм көнчыгыш өлешләргә бүленгән 8 төркемнән тора, 60лап тел керә;

6) *көнчыгыш Судан телләре* гаиләсенә 80ләп тел керә; бу гаилә үзе шартлы рәвештә берләштерелгән 3 тел гаиләсеннән һәм бер изолят телдән тора;

*7) каду телләре* гаиләсе элек кордофан телләре гаиләсенә кертелгән, Судан республикасы үзәгендәге 7 телне үз эченә ала;

8) *кульяк телләре* гаиләсе Угадандагы 3 кечкенә телдән гыйбарәт;

9) *коман телләре* гаиләсендә Эфиопиядәге һәм Судан чикләрендәге 5 тел бар.

*Берта* һәм *гумуз* телләре – Эфиопиядәге изолятлар; *кунама* теле – Эритрейдагы изолят.

***Койсан телләре гаиләсе.*** “Койсан” термины 1928 елда этнограф Л.Шульце тарафыннан кертелә (khoi – кеше, san – бушмен), ул аны бу халыкларның гомуми физик-раса тибын билгеләү өчен куллана. Хәзерге вакытта мәгълүм булган койсан телләре ике гаиләгә һәм 3 изолят телгә бүленә:

1) *үзәк койсан тел гаиләсе* ике төркемне үз эченә ала: кхой-кхой телләре (Намибия һәм КАР) һәм чу-кхве (калахари) телләре (Намибия, Бостванa, Калахари чүленең төньяк-көнчыгышы);

2) *жу-къви телләре гаиләсе*ндә ике төркем: Төньяк койсан төркеме (Намибия, Ангола һ.б.) һәм көньяк койсан телләре.

Изолятлар: *квади* теле (XX гасырда үлгән); *сандаве* һәм *хадза* телләре (Танзания).

***Кытай-тибет телләре гаиләсе*** телләре Көнчыгыш, Үзәк, Көньяк-Көнчыгыш Азиядә һәм Көньяк Азиянең төньяк чигендә таралган. Бу гаиләгә кергән телләр сан ягыннан күп булмаса да, аларда сөйләшүче кешеләр саны ягыннан бу гаилә, һинд-европа телләре гаиләсеннән генә калышып, икенче урында тора. Бу гаиләдә күп кенә лингвистлар ике төркем бар дип исәпли (ә кайбер классификацияләрдә төркемнәр саны 13 җитә):

1) *кытай* төркеменә кытай һәм кытай теленең бер диалекты дип саналган дунган теле керә. Кытай теленең диалектлары гына

да 7 төп төркем барлыкка китерә. Дунган теле Кытайда һәм Урта Азиядә таралган;

2) *тибет-бирма* төркеменә тибет һәм бирма теле карый. Күпчелек классификацияләрдә бу төркем үз эчендә бик катлаулы итеп бүленә.

***Тай (тай-кадай) телләре гаиләсе***нә берничә дистә тел керә, алар Көньяк Кытайда, Һинд-Кытай ярымутравында һәм Һиндстанның көнчыгышында таралган. Бу гаилә *тай төркеме* (бер төркем диалектлары белән тай, лаос, шан телләре) һәм *кадай төркеме*нә (Кытай провинциясендә яшәүче 750 меңләп кеше сөйләшә торган ли теле һәм диалектлары, лати, лакуа, гэлао телләре) бүленә. Барлык тай телләре дә типологик яктан үзара якын һәм кытай теленә охшаган. Күп кенә тай телләренең язулары бик борынгы.

***Австро-азиат телләре гаиләсе***нә Көньяк-Көнчыгыш һәм Көньяк Азиядә, Һинд океанындагы кайбер утрауларда яшәүче халыкларның телләре керә. Бу телләрнең әлеге гаиләгә кертелүләре ышанычлы рәвештә дәлилләнгән дип санала, шулай да эчке классификациядә ачык булмаган моментлар шактый, чөнки күп кенә тау кабиләләренең телләре әлегәчә өйрәнелеп җитмәгән. Австро-азиат телләрендә сөйләшүчеләрнең 70%-ы – вьетнамлылар. Әлеге тел гаиләсендә дүрт төркем аерыла:

1) *мон-кхмер телләре* (вьетнам, кхмер телләре – икесе дә Вьетнам һәм Камбоджаның дәүләт телләре санала);

*2) мунда телләре* (сантали, мунда һ.б.);

3) *никобар телләре;*

4) *нахали телләре.*

***Австронезия телләре гаиләсе***нә 150 дән артык тел керә. Аны кайчак икегә (индонезия һәм океания яисә индонизия һәм полинезия телләренә), ә кайвакыт дүрт төркемгә (индонезия, полинезия, меланезия һәм микронезия телләренә) бүләләр. Бу гаилә телләрендә Көньяк-Көнчыгыш Азия утрауларында һәм ярымутрауларында яшәүче күпсанлы халыклар сөйләшә. Телләр саны ягыннан бу гаилә иң эреләрдән санала, бу телләрдә

сөйләшүчеләрнең саны да шактый (300 млн. чамасы). Әлеге тел гаиләсенә *яван* (1000 елдан артык язу тарихына ия), *бали, малайя, тагаль, малагаси* кебек зур телләр дә керә. Болардан тыш *маори, гавай, самоан* кебек полинезия телләре дә мәгълүм.

***Эскимос-алеут телләре гаиләсе***нә кергән аз санлы халыклар Гренландиядә, Төньяк Америка белән чиктәш төньяк районнарда, Россиянең ерак төньяк-көнчыгышында яшиләр. Аңа күп диалектлардан торган эскимос һәм алеут телләре керә. Икесендә дә аффиксация киң кулланыла. Эскимос телләрендә агглютинация таралган, алеут телләрендә флексияләр очрый. Эскимос телендә сөйләшүчеләр Гренландиядә, Канадада, Аляскада һәм Себердә яши. Алеут телендә аралашучылар Прибылов утравында (Россия), Алеут утрауларында (АКШ) яши. Типологик яктан фин-угор телләренә якын. Шуңа күрә Россия тикшеренүчеләре бу телләрне еш кына Урал телләре гаиләсенә кертәләр. Кайбер хезмәтләрдә америка индеецлары телләре белән охшашлыкларны да күрсәтәләр.

Телләрне тел гаиләләренә аера торган генеалогик классификация еш кына тел берәмлекләренең матди гомумилегенә түгел, бәлки географик тәртипкә дә таяна. Шуңа күрә генеологик классификация, нигездә, тел гаиләләрен һәм макрогаиләләрне санап чыгуга кайтып кала дисәң дә була. Алар белән шулай ук дөнья лингвистик картасы буенча сәяхәт иткәндә дә танышып була.

**5. Телләрнең типологик классификациясе.**

Типологик каршы кую, гомуми һәм аермалы структур сыйфатларны табу өчен дөньяның барлык телләре дә кулланырга мөмкин. Лингвистик типология чагыштырыла торган телләрдәге фонетик, синтаксик һ.б. билгеләрне дә исәпкә ала. Әмма сүзнең морфологик төзелешен анализлауга нигезләнгән классификация аеруча нык эшләнгән.

***Морфологик классификация*** телнең структурасы, төзелеше турында мәгълүмат бирә. Бу классификация дөньядагы телләрне үзләренең структурасындагы кайбер уртак билгеләре, сүзнең морфологик төзелеше буенча билгеле бер типларга берләштерә.

Дөньядагы телләрне дүрт морфологик типка аерган типологик классификация күпчелек галимнәр тарафыннан кабул ителә.

1. *Флектив телләр*. Бу телләрдә сүзнең морфологик төзелешендә флексия ныклы һәм төпле күрсәткеч санала. Флектив телләрдә флексияләр бик киң кулланыла, алар күп төрле грамматик мәгънәләр белдерәләр. Бу очракта флексия күпмәгънәле, ягъни бер үк вакытта берничә грамматик мәгънә аңлата. Флектив телләрдә аффикслар тамырга карата төрле позицияләрдә торырга мөмкин: суффикс, префикс, инфикс һ.б. Мондый телләрдә тамыр фонетик яктан үзгәрә ала (бегать – бежать), аларда төрләнеш типлары күп (спряжение, склонение). Флектив телләргә һинд-европа телләре керә. Алар аналитик һәм синтетик төзелешле телләргә бүленәләр.

2. *Агглютинатив телләр*. Бу тип телләрдә морфемаларның чиге аермачык күренеп тора. Морфемалар бары бер генә мәгънә белдерә. Агглютинатив аффикслар сүзнең грамматик формасы үзгәрүгә карап үзгәрмиләр. Аларда төрләнеш бер генә төрле. Болар – төрки телләр һәм фин-угор телләре. Әмма бу телләрнең барысында да агглютинация дәрәҗәсе бердәй түгел.

3. *Изоляцияләнгән* яки *аморф телләр*. Бу телләр сүзләрнең төрләнмәве белән характерлана. Аларда грамматик мәгънә ярдәмлек сүзләр, сүз тәртибе, музыкаль басым, интонация белән белдерелә. Сүзтезмә яки җөмләдәге сүзләр арасында бәйләнешне күрсәтә торган формаль күрсәткечләр булмау бу телләргә изоляцияләнгән дигән атама бирүгә сәбәп булган. Икенче атама (аморф) бу телләрдә морфологик форманың булмавыннан килеп чыккан. Бу телләрне шулай ук *тамыр* телләр дип тә атыйлар, чөнки аларда сүз тамырга яки нигезгә туры килә. Мондый телләргә кытай, вьетнам һ.б телләр керә.

4. *Полисинтетик (инкорпорацияләнгән) телләр.* Бу телләрнең төзелешендә төп үзенчәлек: аларда җөмлә бер кушма сүз буларак төзелә, ягъни җөмләдәге сүзләр барысы бербөтен булып оеша. Нәтиҗәдә формаль морфологик күрсәткечләре булмаган комплекслар барлыкка килә, ул синтаксик бөтен тәшкил итә: бу комплексның башы – ия, ахыры хәбәр, ә уртада аергычлар, тәмамлык һәм хәлләр урнаша. Мәсәлән, чукот телендәге *тыатакаанмыркын* сүзе рус телендәге “я жирных

оленей убиваю” җөмләсенә туры килә. *Ты – я, ата – жир, каа – олень, нмы – убивать, ркын – делать*. Полисинтетиклык Америка индеецлары теленә һәм Төньяк-Көнчыгыш Азия халыклары (чукот, коряк, камчадаль һ.б.) телләргә хас.

XX гасырда типология вәкилләрен тел системасының башка баскычлары да кызыксындыра башлады. Мәсәлән, ***фонологик классификация*** (Н.С.Трубецкой, Р.О.Якобсон) телләрнең фонемалар системасы төзелешендә, системада һәм текстта сузык һәм тартыкларның күләм мөнәсәбәтендә, иҗек структурасында, суперсегмент (просодик) берәмлекләрдә охшашлык һәм аермалыкларны эзләү белән шөгыльләнә.

Фонологик типология өчен иң әһәмиятле билге – телдәге төп фонетик берәмлекнең характеры. Андый төп берәмлек фонема булса “фонема төзелешле” телләр турында фикер йөртелә. Бу – күпчелек телләр, ягъни күпчелек телләрдә төп фонетик берәмлек – фонема. Ә инде төп фонетик берәмлек иҗек (силлабема) икән, “иҗек төзелешле” телләр барлыкка килә (кытай, бирма, вьетнам).

Фонологик типологиядә икенче әһәмиятле билге – сүз һәм иҗекнең просодик характеристикасы. Бу билгегә карап тональ яки политоник телләр (кытай, бирма, вьетнам) монотоник телләргә (калган телләр) каршы куела; ирекле сүз басымына ия телләр басымы даими яки ярымдаими телләргә (һинд-европа, фин-угор) һәм басымсыз (тунгус-манчьжур) телләргә оппозициядә тора.

Фонетик һәм фонологик типология әлегә барлык телләр материалында да, барлык фонетик күренешләрне дә исәпкә алып эшләнеп бетмәгән. Бу өлкәдә тикшеренүләр дәвам итә.

***Синтаксик классификация*** өчен сүз тәртибен чагыштыруга нисбәтле тикшеренүләр кызыклы. Мәсәлән, субъектның (S), фигыль-предикатның (V) һәм объектның (O) урнашу тәртибе тәкъдим ителгән 6 формуланың берсе белән күрсәтелергә мөмкин: SVO, SOV, VSO, VOS, OSV, OVS. Рус телендә һәр алты форманың да кулланылырга мөмкин, ләкин SVO формасы нейтраль, стилистик яктан тамгаланмаган дип санала.

Килеш төрләнеше хас булган телләрдә, фигыль-предикатның күчемле яки күчемсез, фигыльнең актив яки пассив формада булуына карамастан, S һәрвакыт (яки бик еш) исем килеше белән белдерелә. Мондый төр телләр – *номинатив телләр* дип атала. Номинатив телләрдә туры тәмамлык гадәттә төшем килеше белән белдерелә (шуңар күрә аларның икенче исеме – аккузатив телләр). Һинд-вропа телләре җөмләләренең номинатив төзелеше белән характерлана. Моннан тыш, номинатив телләргә һинд-европа телләреннән башка абсолют күплек керә. Мәсәлән, афразия телләре, төрки телләр, монгол, тунгус-маньчжур телләре, күпчелек тибет-бирма, Австриядәге телләрнең бер өлеше һ.б. керә.

Әгәр субъектның килеш категориясе фигыльнең күчемле яки күчемсез булуына карап билгеләнә икән, димәк бу очракта *эргатив телләр* турында сүз алып барыла. Эргатив конструкцияләр һинд-иран, кавказ, эскимос-алеут, баск һ.б. телләргә хас. Эргатив телләргә, шулай ук, күп кенә телләр керә: кавказ телләре (грузин, убых), австронезия телләре (тонга), австралия телләре (дьирбал), папуас, чукот-камчат, эскимос-алеут һәм майя (тцелтал) телләре. Эргатив үзенчәлекләр, шулай ук, хинди һәм урду телләрендә дә чагыла.

*Актив төзелешле* телләрдә субъект һәм объект түгел, ә бәлки актив һәм пассив башлангыч бер-берсенә каршы куела. Актив (җанлы) исемнәр, нигездә, хәрәкәт фигыльләре белән, ә инактив исемнәр хәл (торыш) фигыльләр белән яраша. Актив телләргә кайбер америнд телләре (дакота), лхаса-тибет, гуарани телләре керә.

Синтаксик типологиядә сүз тәртибе һәм бәйлекләр арасында бәйләнеш тә күзәтелә. Ике класс аерыла: *уңга тармакланган* телләр (иярүче сүз ияртүче сүз артыннан килә – һинд-европа, семит, австронезий телләренең күбесе) һәм *сулга тармакланган* телләр (ияртүче сүз ияртүче сүз артыннан килә – алтай һәм кавказ телләре).

Типологик тикшеренүләр даирәсенә хәзерге көндә Африка, Австралия, Себер, Көньяк-Көнчыгыш Азия, Океания, Америка индеецларының телләре дә кертелә башлады.

**6. Телләрнең ареаль классификациясе.**

Ареаль классификация телләрне тышкы, урнашу ягыннан гына төркемли кебек. Мәсәлән, географик критерий нигезендә Кавказ һәм Африка телләре аерыла, төркем һәм төркемчә атамаларында төньяк, көнбатыш һ.б. шундый сүзләр очрый. Зур территорияләрдә һәм чиктәш булмаган урыннарда таралыш алган тел гаиләләре, хәтта аерым телләр була. Шулай ук дөньяда кардәш булмаган телләрдә сөйләшүче халыкларның кечкенә генә территорияләрдә янәшә яшәп ятулары мәгълүм. Мәсәлән, Кавказда һинд-европа, Алтай телләре гаиләләренең төрле төркемнәренә караган телләр таралыш алган. Һиндстанның көньягында, Африканың күпчелек районнарында, Яңа Гвинея утрауларында шул ук хәл күзәтелә.

Әмма ареаль классификациядә болар гына түгел, бәлки лингвистик фактлар да исәпкә алына:

1) янәшә яши торган халыклар һәм аларның телләре күпчелек очракта килеп чыгышлары ягыннан да бәйле була. Мәсәлән, тарихи география һәм тарихи этнология фәннәре мәгълүматлары буенча, Америка җирле халкының (аборигеннарның) телләре кардәш дип фараз ителә;

2) кардәш булмаган телләрдә дә, озак вакытлар бергә аралашып яшәү сәбәпле, охшаш сыйфатлар барлыкка килә. Мәсәлән, күрше телләрнең фонологик системаларында (басым, тартык һәм сузык авазлар, тон), синтаксисларында охшашлыклар табыла. Генетик яктан кардәш булмаган, әмма янәшә яши торган телләрдәге мондый охшашлыкларны *ареаль охшашлыклар* дип йөртәләр. Телләрне шундый тел фактлары охшашлыгына нигезләп төркемләү ареаль классификациянең нигезен тәшкил итә.

Ареалларның зурлары һәм кечкенәләре була. Кайчак бөтен дөньяны өч гиперареалга бүләләр: *Иске дөнья (Старый свет), Яңа дөнья (Новый свет)* һәм *Океания.* Икенче төрле, җентеклерәк бүленешләр дә булырга мөмкин (мәсәлән бер телнең, диалектның таралыш ареаллары һ.б.).

Кайбер хезмәтләрдә *сузынкы* һәм *йомык ареал*лар билгеләнә. Сузылган зоналар гадәттә тигезлекләрдә була һәм анда телләр генетик яктан бертөрле була. Йомык зоналар исә географик (тау,

океан, диңгез һ.б. белән) чикләнгән ареалларда барлыкка килә һәм генетик төрлелек белән аерылып тора. Мәсәлән, Евразия даласы – сузынкы зона, Кавказ – йомык зона.

Дөнья телләренең барысын да кертеп ясалган ареаль классификацияләр күп түгел. Бу уңайдан үрнәк итеп А.Кибрик классификациясен[10] китерергә мөмкин. Ул үзенең “Дөнья телләре һәм тел ареаллары” хезмәтендә 10 макроареал аерып чыгара.

1. Африканың Сахарадан көньяктарак булган өлеше (нигер-кордофан, Нил-сахара, койсан телләре керә).
2. Төньяк Африка һәм Якын Көнчыгыш (афроазиат телләре таралган территория).
3. Үзәк һәм Көньяк Азия (һинд европа телләре гаиләсенең һинд һәм иран төркеме, дравид телләре гаиләсе керә).
4. Кытай һәм Көньяк-Көнчыгыш Азия (кытай-тибет, тай, австроазиат телләре таралган).
5. Океания (австронезия һәм папуасс телләре).
6. Австралия.
7. Европа һәм Кавказ (һинд-европа телләренең калган төркемнәре һәм Кавказ телләре).
8. Төньяк Азия (Урал, Алтай, палеоазиат телләре).
9. Төньяк Америка.
10. Көньяк Америка.

Хәзерге көндә фәндә бу классификациядән дә камилрәк бүленеш күренми, шунлыктан телләрне ареаль яктан төркемләүне шуңа нигезләп күз алдына китерергә була.

### 7. Телләрнең функциональ классификациясе.

Хәзерге фәндә телләрне яңача төркемләү буенча эзләнүләр дәвам итә. Алда санап үтелгән генеалогик, типологик һәм ареаль классификацияләрдән тыш, кайвакыт социолингвистик һәм социомәдәни классификацияләрне дә күрсәтәләр. Дөрес, аларның үзенчәлекле классификацияләр буларак яшәүләре турында тел белемендә сүз алып бару әлегә кабул ителмәгән. Әмма шулай да мондый классификацияләрнең булу ихтималы, аларда каршы куелырга тиешле билгеләр (язусыз, борынгы

[10] Кибрик А. Языки мира и языковые ареалы http://www.myshared.ru/slide/203434/

язулы, иске язулы телләр; дәүләт телләре / рәсми телләр һәм рәсми булмаган телләр, гомуммилли, җирле һәм кабилә телләре һ.б) ачык күренеп тора.

Хәзерге дөньяның лингвистик картасы аның административ-сәяси картасы белән тыгыз бәйләнгән: дөнья телләре бу телләрдә сөйләшүче халыкларның саны, таралыш ареалы, иҗтимагый функцияләре, үз дәүләтендәге һәм аннан читтә абруе белән дә бер-берсеннән аерылып торалар. Телләрнең ***функциональ*** (иҗтимагый-функциональ, яки социологик) ***классификациясе***, кагыйдә буларак, күп планлы, чөнки анда тел һәм җәмгыятькә мөнәсәбәтле күп кенә даими һәм үзгәрүчән факторларны исәпкә алырга кирәк. Кайбер билгеләре буенча, телләрнең функциональ классификациясен түбәндәгечә күзалларга мөмкин.

1. Этник гомумилек белән бәйләнешләренә карап, өч тел тибы аерып була: *халык теле, кабилә теле* һәм *милли телләр*. Телнең иҗтимагый тибын халыкның иҗтимагый бергәлеге билгели.

2. Этник территориядән читтә таралуы һәм телнең хәзерге дөньяда тоткан урыны *җирле телләрне*, аерым төбәкләрдә яшәүче халык кына куллана торган *төбәк телләрен*, *халыкара аралашу телләрен* һәм *дөнья телләрен* (БМО телләре – инглиз, француз, кытай, испан, гарәп, рус) билгеләргә нигез бирә.

3. Җәмгыятьтә үтәгән функцияләре һәм яшәү формалары буенча, *әдәби телләр* һәм *диалектлар, дәүләт телләре, культ* яки *ритуал телләр* һ.б. аерыла.

Илдә сәяси ситуация үзгәрү, икътисади үзгәртеп корулар, иҗтимагый һәм милли сәясәттә яңа ориентирлар пәйда булу һ.б. – барысы да иҗтимагый-коммуникатив системага да тәэсир итә, аның составына һәм функцияләренә йогынты ясый. Телләрнең функциональ классификациясе дөньяда тел ситуацияләренең үзенчәлекләрен күзалларга ярдәм итә, телнең җәмгыятьтәге функцияләрен характерлый.

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар**

1. Дөньядагы телләрнең санын билгеләү проблемасының асылын аңлатыгыз.

2. Дөньядагы телләрне нинди принциплар буенча төркемлиләр?

3. Генеалогик принцип нидән гыйбарәт?

4. Тел гаиләсе, телләр төркеме, кардәш телләр, баба тел төшенчәләрен аңлатыгыз.

5. Иң зур тел гаиләләрен атагыз.

6. Лингвистик классификациянең нинди төрләре бар? Морфологик, фонетик, синтаксик классификацияләрнең асылын аңлатыгыз.

7. Ареаль классификациядә телләр ничек төркемләнә?

8. Ареаль классификациянең асылы нидән гыйбарәт?

9. Телләрнең функциональ классификациясендә нинди критерийлар исәпкә алына?

## Тема: ТЕЛ СИСТЕМАСЫ ҺӘМ АНЫҢ СТРУКТУРАСЫ

1. Система һәм структура төшенчәләре.
2. Тел системасы һәм структурасы.
3. Телнең структур берәмлекләре.
4. Телнең структур яруслары.

### 1. Система һәм структура төшенчәләре.

Чынбарлык күренешләрен система итеп өйрәнү хәзерге фәннең төп методологик принципларыннан санала. Үзара бәйләнештәге элементлардан гыйбарәт булган бөтен бер объектны ***система*** дип атыйлар.

Системалар төрле була: матди һәм идеаль, гади һәм катлаулы, ачык һәм ябык һ.б. *Матди система*ларның элементлары – матди (материаль) объектлар. *Идеаль системалар* кешенең аң, фикерләү эшчәнлеге продуктын тәшкил итә. Аңа фәлсәфи категорияләр системасын, математикадагы формаль тамга системаларын, фәнни теорияләрне һ.б. кертергә була. Болар үз эчендә *гади* һәм *катлаулы* системаларга бүленә. Гади системалар чагыштырмача гади элементлардан тора (мәсәлән, гади биологик системалар, химик элементлар системасы), катлаулы системалар системалар системасыннан гыйбарәт була, ягъни аның үз эчендә подсистемалар аерыла (мәсәлән, катлаулы система буларак, җәмгыять икътисади, социаль, сәяси һәм рухи подсистемаларга бүленә).

Система *ачык* булганда, аңа өстәмәләр, төзәтүләр кертелә ала, ягъни бу система чикләнмәгән. *Ябык* системалар, киресенчә, чикләнгән, аларга яңа элементлар өстәп булмый.

***Структура*** система элементлары арасындагы бәйләнешләр һәм мөнәсәбәтләр җыелмасын аңлата. Теге яки бу системага кергән матди элементлар билгеле бер тәртиптә оешкан булалар.

Һәр системаның эчке оешуы – структурасы була. Система элементларының оешуы, тәртипкә килүе шушы системаның структурасын тәшкил итә. Димәк, структура элементларның бәйләнешенә, мөнәсәбәтенә нигезләнә. Структура системадан тыш яши алмый, системадан аерыла алмый.

**2. Тел системасы һәм структурасы.**

Телнең дөньяда иң уникаль система булуы турында сөйләгәндә, күпчелек тел белгечләре *структура* төшенчәсен дә кулланалар, бу термин белән тел берәмлекләре һәм аларның төрләре арасындагы системалы мөнәсәбәтләрнең гаять әһәмиятле ягын ассызыклыйлар.

Структура тел системасындагы абстракт булган компонентларны аерып чыгара, алар телнең теге яки бу ярусы (дәрәҗәсе, катламы) эчендәге элементларның мөнәсәбәтен түгел, бәлки тел элементларының яруслары арасындагы мөнәсәбәтләрне характерлый. Мәсәлән, фонемаларның үзара мөнәсәбәте аларның бер ярус эчендә системалы оешуын аңлата; ә шушы ук берәмлекләрнең сүз һәм морфемаларны билгеләүдә катнашуы һәм шул вакытта үтәгән функцияләре структур багланышларны белдерә.

Гадәттә телне системалар системасы буларак билгелиләр, шуның белән аның гаять катлаулы, анда күп төркемнәр һәм бүлекләр, ягъни подсистемалар, телне бербөтен итеп оештыра торган төрле элементлар булуын ассызыклыйлар. Шул ук вакытта телнең, бер яктан, катгый оешкан, төзелешенә читтән субъектив тәэсирләрне чикли торган, аерым өлешләренә үтеп кермәслек система булуына игътибар итәләр. Икенче яктан, тел – ачык, хәрәкәтчән система, ул үзгәрүчән чынбарлыкны, кеше тәҗрибәсе нәтиҗәсендә туган предмет һәм күренешләрне, аларның бәйләнешләрен һәм мөнәсәбәтләрен чагылдыра. Телнең менә шундый каршылыклы характеры анда система оештыра торган, төрле функцияләргә һәм мөмкинлекләргә ия берәмлекләрнең булуын күздә тота.

**3. Телнең структур берәмлекләре.**

Тел берәмлекләрен аеруда фәндә уртак фикер әлегә юк. *Тел берәмлекләре* дип кабатлана торган, тел системасында чагыштырмача даими билгеләре белән аерылган, яисә турыдан-туры сөйләм актларында телдә кабул ителгән кагыйдә һәм модельләр буенча ясала торган элементларга әйтәләр.

Тел системасын һәм структурасын оештырудагы урыныннарына һәм рольләренә карап тел берәмлекләрен ике класска аерып карыйлар: *конститутив берәмлекләр* (КБ) һәм *конститутив булмаган берәмлекләр* (КББ) (термин *конституция – төзелеш, структура* дигән төшенчәдән алынган).

***Конститутив берәмлекләр*** (КБ) – тел системасындагы төп берәмлекләр, аларны кабатлап, санап була, аларга формаль (матди-идеаль) күрсәткечләр хас, тел системасында даими статуска ия. Болар – фонема, морфема, сүз формалары, сүз, сүзтезмә, җөмләләр.

Әмма телнең аерым дәрәҗәләре (ярuслары) шушы төзелеш, нигез берәмлекләреннән генә тормый. Һәр аерым ярuста алда саналган сыйфатларга ия булмаган берәмлекләр дә очрый, алар ярус эчендә яки ярусара функцияләр үтиләр. Бу берәмлекләрнең кайберләре кабул ителгән кагыйдә һәм модельләр буенча сөйләм барышында ясала (фонетик сүз, синтагма, җөмлә кисәкләре һ.б.), ә икенчеләре теге яки бу КБнең элементы була (иҗек, интонация, басым һ.б.); өченчеләре КБ базасында ясала, алар теркәләләр, саналалар, КБгә хас булган аерым функцияләрне башкаралар һәм шуның белән КБгә якын киләләр (фразеологизмнар, аббревиатуралар һ.б.). Мондый берәмлекләр телнең подъярусларын төзи ала дияргә нигез бар. Аларны ***конститутив булмаган берәмлекләр*** (КББ) дип атыйлар.

**4. Телнең структур ярuслары (дәрәҗәләре, катламнары, баскычлары)** аның төп структур оешу компонентларын тәшкил итәләр. Телнең система булып оешуы аның төрле ярусларында төрлечә. КБ – тел ярусларын төзи торган базис элементлар, әмма телнең аерым ярусын төзүдә билгеле бер дәрәҗәдә КББ дә катнаша. Ярус элементлары буларак, КБ белән КББ үзләренең

матди һәм формаль табигатьләре, мәгънә тибы, үзара мөнәсәбәтләренең характеры, үтәгән функцияләре белән ярусның үзенчәлеген барлыкка китерәләр. Әлеге нигездә телнең *фонетик-фонологик, морфемик-морфологик, лексик-семантик* һәм *синтаксик яруслары* аерыла.

Телнең структурасында фонетик төзелеш әһәмиятле урын тота. Ул телнең матди яшәешен тәэмин итә. ***Фонетик-фонологик ярус***та төп КБ – фонема. Фонема – телнең башка кечкенә кисәкләргә бүленми торган аваз берәмлеге, ул сүз һәм аның формаларын аера. Фонема һәм телнең әлеге ярусына кергән КББ (иҗек, басым һ.б.) телнең матди яки объектив ягын һәм, табигый, телдән (вербаль) фикерләүне барлыкка китерәләр. Телдәге фонемалар система тәшкил итә. Һәр фонема мөстәкыйль, ягъни ул фонемалар системасына кергән башка фонемалардан аерыла.

***Морфемик-морфологик ярус***ны аерып чыгару турында тел белгечләренең фикере бердәй түгел. Кайбер галимнәр морфемик дәрәҗәне генә аерып чыгаралар һәм иң кечкенә мәгънәви кисәкләрне – морфемаларны, шулар белән беррәттән төрле аффиксларны өйрәнү белән шөгыльләнәләр. Икенче төркем галимнәр морфемик-морфологик яруска, морфологиянең берәмлеге буларак, сүз формалары һәм аларның парадигмаларын да кертеп карыйлар. Морфемалар һәм аларның бәйләнешләре үтәгән функцияләре белән берлектә өйрәнелергә тиешлекне күздә тотып, бу ярусның берәмлекләр составына морфемаларны һәм сүз формаларын кертеп карау максатка ярашлы дип уйлыйлар.

Телнең тагын бер структур элементы – аның лексик төзелеше. Телнең ***лексик-семантик ярусы***нда төп КБ – сүз; аннан тыш бу яруска үзләренең мәгънәләре һәм үтәгән функцияләре ягыннан сүзгә тиңләштерелә торган берәмлекләр – фразеологизмнар, лексикалаштырылган номинатив (тезмә терминнар, тотрыклы аналитик атамалар) һәм предикатив сүзтезмәләр (фигыльле исем сүзтезмә), шулай ук аббревиатуралар керә.

***Синтаксик ярус***та төп КБ – сүзтезмә һәм җөмлә. Грамматиканың бер бүлеге буларак, синтаксис әлеге

берәмлекләрне тасвирлау һәм конкрет мәгънәләрен анализлау белән шөгыльләнми, бу берәмлекләрне төзү модельләре һәм аларның тел системасында теркәлгән типик мәгънәләре синтаксисның төп тикшеренү объектын тәшкил итә.

Шулай итеп, тел системасында дүрт төп структур компонент бар. Тел – гади система гына түгел, ягъни тел системасына кергән шушы компонентлар үзләре дә система (подсистема) тәшкил итәләр. Телнең бер подсистемасындагы үзгәрешләр икенчесенә дә тәэсир итә. Җыеп әйткәндә, телнең фонетик-фонологик, морфемик-морфологик, лексик-семантик, синтаксик ярусллары арасында тыгыз бәйләнеш яши һәм тел шул структур элементлар бердәмлегеннән гыйбарәт. Тел үзенең төп функциясен – аралашу функциясен үтәү өчен тотрыклы система булырга тиеш.

Телнең системалы-структур төзелеше тел турындагы фәннең традицион бүлекләре белән туры килеп бетми. Тел берәмлекләрен системалы-структур һәм традицион мөнәсәбәтләрдә өйрәнү бер-берсен алыштырмый да, чикләми дә, киресенчә, тулыландыра гына. Тел берәмлекләрен структур яктан өйрәнү КБнең тел төзелешендәге әһәмиятен ачыкларга ярдәм итә.

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар**

1. Система һәм структура төшенчәләрен аңлатып бирегез.
2. Телнең структур берәмлекләрен тасвирлагыз.
3. Телнең структур ярусллары (дәрәҗә, баскычлары) турында сөйләгез.

## Тема: ТЕЛНЕҢ ФОНЕТИК ТӨЗЕЛЕШЕ

1. Фонетика һәм фонология турында төшенчә.
2. Сөйләм авазларын өйрәнү аспектлары.
3. Сөйләмдә аваз үзгәрешләре.
4. Сөйләмнең фонетик кисәкләре.
5. Басым һәм интонация.

### 1. Фонетика һәм фонология турында төшенчә.

Табигый кеше телендә аваз чаралары булу вербаль хәбәрләрне тапшырырга һәм кабул итәргә мөмкинлек бирә. Әлеге аваз чаралары җыелмасы телнең ***фонетик-фонологик***

***компонент***ын барлыкка китерә. Тел системасының бу компонентын һәм аның аралашу процессында яшәү-кулланылу үзенчәлекләрен *фонетика* фәне өйрәнә. Хәзерге вакытта еш кына телнең аваз ягын төрлечә өйрәнүне күздә тоткан фәннәр җыелмасы мәгънәсендә, *фонетик фәннәр* турында сүз йөртәләр.

Фонетика термины киң һәм тар мәгънәләрдә кулланыла. Тар мәгънәсендәге *фонетика*ның төп предметы – телнең аерым авазлары, ягъни фонетика аваз чараларын физик (акустик) һәм биологик (артикуляцион + перцептив) аспектларда тикшерә. Кайвакыт тар мәгънәсендәге фонетиканы өчкә бүләләр:

1) авазның әйтелешен өйрәнә торган *артикулятор фонетика*;

2) аваз әйтелешенең нәтиҗәсен өйрәнә торган *акустик фонетика*;

3) авазны кабул итү белән бәйле *аудитив (перцептив) фонетика*.

*Фонология* фәненең төп берәмлеге – фонема. Ул иң беренче чиратта телнең фонемаларын билгеләү, аларны система итеп оештыру принципларын, сөйләм агышында аларның үзара мөнәсәбәтләрен ачыклау белән шөгыльләнә. Фонология фәне сегмент һәм суперсегмент фонологияләрне үз эченә ала. *Сегмент фонология* сөйләмдә бер-бер артлы килә торган берәмлекләрне (фонема, иҗек) өйрәнә. *Суперсегмент* (супрасегмент) *фонология* просодик чараларны (тон, иҗек акценты, басым, интонация) тикшерә. Тагын да җентекләбрәк караганда, сегмент фонология фонема турында өйрәтмә *(фонемика)* һәм иҗек турында өйрәтмә *(силлабемика)* дигән тармакларга бүленә. Суперсегмент фонологиядә тон, сүз басымы, интонацияне өйрәнүгә бәйле рәвештә *тонология, акцентология, интонология* фәннәре аерыла.

Фонетиканың тикшерү-өйрәнү максатына карап, гомуми һәм хосусый, синхроник һәм диахроник (тарихи), тасвирлама һәм норматив, теоретик һәм гамәли дигән төрләргә дә бүләләр.

### 2. Сөйләм авазларын өйрәнү аспектлары.

Фонетиканың төп берәмлеге булган ***аваз*** – сөйләмнең таркалмый торган иң гади берәмлеге булса да, катлаулы

күренеш. Шуңа күрә аны төрле яктан өйрәнәләр. Беренчедән, сөйләм авазлары, табигатьтәге теләсә нинди аваз кебек, физик, матди күренеш. Димәк, аларны ишетелеш, яңгыраш ягыннан өйрәнергә мөмкин. Моның белән физика фәненең *акустика* бүлеге шөгыльләнә. Икенчедән, сөйләм авазлары ясауда билгеле бер органнар катнаша. Авазларны бу яктан да өйрәнүне *биологик аспект* дип атыйлар. Бу ике аспект бергә *фонетик аспект* дип тә йөртелә. Өченчедән, сөйләм авазының иҗтимагый ягы да зур әһәмияткә ия, авазлар мәгънә аеруда катнаша. Авазны шул яктан өйрәнү *иҗтимагый* (социаль, фонологик, лингвистик) аспектның эчтәлеген тәшкил итә[11]. Бу аспектлар үзара тыгыз бәйләнгән.

### *Сөйләм авазларын акустик яктан өйрәнү*

Физик күренеш буларак ***аваз*** – тыгыз матдәнең билгеле бер мохиттә тирбәнүеннән барлыкка килгән һава дулкыннарының тирбәнеш нәтиҗәсе. Ә ***сөйләм авазы*** – тавыш ярыларының тирбәнеш нәтиҗәсе. Һаваның кысылуы һәм таралып китүе дулкынсыман рәвештә кешегә аваз формасында ишетелә. Бу тирбәнеш дулкыннарын төрле аппаратлар (кимографлар, оцилографлар, электр спектографы һ.б) ярдәмендә яздырып алалар, һәм бу язмалар авазның акустик составын, физик төзелешен билгеләргә мөмкинлек бирә.

Физик яктан һәрбер сөйләм авазы *югарылыгы, көче, тембры* һәм *озынлыгы* белән аерылып тора. Тавыш ярыларының тирбәнеше нәтиҗәсендә туган һава дулкыннарының тирбәнеше ритмик, тәртипле һәм, киресенчә, оешмаган, тәртипсез булырга мөмкин. Тигез тирбәнешләр нәтиҗәсе буларак *тавыш (тон),* ә тирбәнешләр тигезсез, таркау булса, *шау (шум)* барлыкка килә. Авазларда тон һәм шау төрле дәрәҗәдә катнаша. Сузыклар тоннан гына ясала; сонор тартыкларны *(м, н, ң, р, л, м, й, w)* әйткәндә дә тон өстенлек итә; ә яңгырау тартыкларны әйткәндә шау да, тон да катнаша; саңгырау тартыклар шаудан гына тора.

Авазның *югарылыгы* тавыш ярыларының билгеле бер вакыт аралыгында тирбәнеш ешлыгына бәйле. Тирбәнешләр никадәр еш булса, аваз шулкадәр югары була.

---

[11] Авазларның әлеге сыйфаты фонология фәнендә өйрәнелә.

Авазның *көче* (интенсивлык) тирбәнешнең амплитудасына бәйле. Төрле авазларның көче төрлечә. Авазның көче йоткылык резонаторларының күләменә бәйле. Аның күләме кимрәк булган саен, авазның көче арта бара.

Һава тирбәнешләрен барлыкка китергән матдә үзенең бөтен массасы белән генә түгел, аерым өлешләре белән дә тирбәнә. Матдәнең аерым кисәкләре тирбәнешеннән барлыкка килгән тоннарны – *обертоннар* яисә *гармоника* дип атыйлар. Обертоннар авазга *тембр* (французча: кыңгырау) дип аталган үзенчәлекле бизәк бирә.

Сөйләм авазының микъдари *озынлыгы* аның яңгырау вакыты белән билгеләнә.

### *Сөйләм авазларын биологик яктан өйрәнү*

Кешенең сөйләм өчен генә хезмәт итә торган махсус органнары юк. Сөйләгәндә кеше төрле органнардан файдалана. Сөйләм барлыкка китерүдә катнаша торган органнар җыелмасы *сөйләм аппараты* дип атала. Сөйләм аппараты түбәндәге өлешләрдән тора:

1) сулыш аппараты (диафрагма, үпкәләр, бронхлар, трахея);
2) бугаз (тавыш ярылары һәм кимерчәкләр);
3) бугаздан өске өлеш (йоткылык, авыз һәм борын куышлыгы).

Сөйләм органнарының авазларны әйткәндәге эшчәнлеге *артикуляция* дип атала. Аваз артикуляциясендә өч этап була: *экскурсия* (сөйләм органнарының теге яки бу авазны әйтү өчен әзерлеге); *экспозиция* (сөйләм органнарының шушы авазны әйткәндә бер мизгелгә туктап калуы); *рекурсия* (сөйләм органнарының кире үз хәлләренә кайтуы).

Сөйләм органнарының, теге яки бу авазларны әйтү өчен, типик торышлары җыелмасы *артикуляцион база* дип йөртелә. Ул тумыштан бирелми, бәлки теге яки бу телне өйрәнгәндә формалаша. Артикуляцион базаның тотрыклылыгы чит телләрне өйрәнгәндә үзен шактый сиздерә. Туган телгә хас артикуляцион база үзенчәлекләренең икенче бер телдә сөйләгәндә чагылуы аркасында *акцент* барлыкка килә.

### *Сөйләм авазларын иҗтимагый яктан өйрәнү*

Авазларны мәгънәгә мөнәсәбәттә өйрәнү лингвистик аспектның асылын тәшкил итә.

Кешенең сөйләмендә авазлар саны бик күп. Бер генә аваз да шул ук төгәллек белән икенче тапкыр кабатлана алмый. Мәсәлән, *балалар* сүзендә өч [а] авазы өч төрле әйтелә: беренче иҗектә – о-лашкан, икенчесендә – бераз о-лашкан, өченчесендә чиста [а] ишетелә. Ләкин татар кешесе аның аерым билгеләренә игътибар итми, аларның барысын да бер [а] авазы дип кабул итә. Башка авазлар белән дә шул ук хәл. Сөйләмдә авазлар гаять күп булса да, аларны охшаш билгеләре нигезендә сан ягыннан кимрәк булган аваз типларына берләштереп була. Шул аваз типларын фәндә ***фонема*** дип атыйлар. Сөйләмнең теләсә кайсы авазы фонема түгел, бары теге яки бу телгә хас булган, сүз һәм морфемаларның аваз тышчаларын, ягъни мәгънә аерырга сәләтлеләре генә фонема дип аталырга хаклы. Тик шунысына да игътибар итәргә кирәк: фонема үзе мәгънә белдерми, ул сүз мәгънәсе белән бәйләнештә тора.

Сөйләм авазы белән фонема бер яктан тыгыз бәйләнсәләр дә, аларны тиңләштереп карарга ярамый. *Сөйләм авазы*н – фонетика, *фонема*ны фонология өйрәнә. Фонетикада аваз акустик-артикуляцион яктан өйрәнелә, фонологиядә фонема аралашудагы әһәмияте, иҗтимагый функцияләре күзлегеннән тикшерелә.

Тел берәмлекләрен оештыру һәм мәгънәләрен аеру өчен фонемалар тел системасында бер-берсенә каршы куелырга тиеш. Фонемаларның шул рәвешчә каршы куелышы *оппозиция* дип атала. Беренче чиратта һәр фонема нуль фонемага, ягъни әлеге фонеманың юклыгына каршы куела: *сата – ата, тай – ай, сарык – арык, өстәл – өстәле, кил – килә* һ.б. Беренче өч сүзнең мәгънәсе сүз алдында билгеле бер тартыкларның булу-булмавы белән аерыла; ә соңгы ике сүздә фонеманың булу-булмавы сүз формаларын аера һ.б.

***Фонема*** – телнең минималь берәмлеге, ул тагын да кечерәк кисәкләргә таркала алмый. Шулай булуга карамастан, ул шактый катлаулы күренеш, чөнки һәр фонема мөстәкыйль яши алмый торган билге-сыйфатлардан гыйбарәт. Татар телендәге *д*

фонемасында түбәндәге билгеләрне күрсәтергә була: яңгырау (саңгырау *т* дан аермалы буларак: *дары – тары*); шартлаулы (өрелмәле *з* дан аермалы буларак: *дар – зар*); тел алдында ясала (*ķ* дан аермалы буларак, *дар – ķар*); аны ясауда иреннәр катнашмый (*б* дан аермалы буларак: *дала – бала*); борын авазы түгел (*Дилә* - *Нилә*) һ.б.

Һәр фонеманың даими фонологик билгеләре була, алар *конститутив билгеләр* дип атала. Әмма фонеманың составында барлык билгеләр дә бердәй әһәмияткә ия түгел. Аларның кайберләре фонеманы башкалардан аерып тора. Болар – *дифференциаль билгеләр.* Бериш билгеләр фонеманы башкалардан аеру өчен хезмәт итми, фонема составын тулыландыра гына, чөнки бу билге ярдәмендә аңа каршы куела торган икенче бер фонема булмый, болары – *интеграль билгеләр*. Бу акустик-артикуляцион билгеләр сөйләшүчеләр тарафыннан кабул ителә һәм фонемаларны бер-берсеннән аера, шулай ук сүз һәм морфемаларны танырга да ярдәм итә. Мәсәлән, *дар* һәм *тар* сүзләрендәге беренче авазлар яңгыраулыкта-саңгыраулыкта аерыла, бу аларның дифференциаль билгеләре. *Бара* һәм *бәрә* сүзләрен сузыкларның калынлыгы-нечкәлеге аера.

Фонемалар телдә иҗекләр, тактлар, фразалар составында яшиләр һәм шул сәбәпле төрле әйтелеш шартларына эләгәләр. Фонемаларның билгеле бер әйтелеш шартларына билгеләнүе, чолганышы *дистрибуция* дип атала. Мәсәлән, татар телендәге [ң] авазы сүз башында килә алмый, сүз уртасы һәм ахырында иркен кулланыла; [о] һәм [ө] фонемалары абсолют сүз ахырында очрамый; рус телендәге [ы] фонемасы сүз башында килми.

Фонемаларның әйтелеш шартлары *позиция* дип атала. Бу позицияләр *көчле* һәм *көчсез* булырга мөмкин. Фонеманың *көчле позициясе* аның дифференциаль билгеләре аеруча ачык чагылыш тапканда күзәтелә. Фонемалар, дифференциаль билгеләрен югалтып, тоныграк күренгән позиция *көчсез позиция* дип атала.

Бер генә билгеләре белән аерылып торган фонемалар *коррелятлар* дип атала: *а – ә, у – ү, б – п, з – с* һ.б.

Шулай итеп, ***фонема*** – реаль яшәеше булган һәм төрле билгеләргә ия булган тел берәмлеге ул. Фәндә фонеманың түбәндәге билгеләрен күрсәтәләр:

1) фонема матди бердәмлеккә ия;
2) фонема мәгънә ясый: *бак – бас – баш*;
3) фонема мәгънә аера: *тор –тоз – тол*;
4) фонема фонетик позициягә бәйле түгел;
5) фонеманың төп билгесе аерым әйтелә ала, башка билгеләрен аерып әйтү кыен;
6) фонема, телдә бер аерылып чыккач, шул телдә сөйләшүчеләр тарафыннан һәрвакыт аерым фонема буларак кабул ителә.

**3. Сөйләмдә аваз үзгәрешләре.**

Сөйләмдә авазлар, берсе янында икенчесе килеп, төрле үзгәрешләргә дучар булалар. Бу үзгәрешләр авазның сүздәге урынына, басымга бәйле булырга (*позицион үзгәрешләр)* яки авазларның бер-берсенә тәэсир итешүе нәтиҗәсендә барлыкка килергә (*комбинатор аваз үзгәрешләре*) мөмкин. Комбинатор һәм позицион аваз үзгәрешләрен билгеләүдә фәндә төрлелек яшәп килә.

***Авазларның позицион үзгәрешләре***

Авазларның позицион үзгәрешләре күп очракта аларның сүз башында яки азагында килүгә бәйле. Төрле сәбәпләр аркасында сүзнең башындагы яисә ахырындагы авазлар төшеп калырга мөмкин, бу күренеш ***апакопия*** дип атала: *фатир, секунд, гәҗит* һ.б. Бу күренеш татар теленең сөйләшләрендә дә күзәтелә: *тәрәз, берләр (бөреләр)* һ.б. Сүз ахырында тартыклар төшеп тә калырга мөмкин, мәсәлән, рус телендә: *лист (лис), мост (мос).*

Сүз ахырында килгән яңгырау тартыкларның саңгыраулашуын да позицион үзгәрешләргә кертеп була. Бу татар, рус, белорус, болгар телләрендә күзәтелә: *флаг – флак, клуб – клуп, завод – завот* һ.б.

Сузыкларның позицион үзгәрешләре басымга да бәйле була. Шундый үзгәрешләрнең иң киң таралганы – ***редукция***. Аваз басымнан еракта торып кыскарырга һәм аерым очракларда төшеп калырга мөмкин.

Авазларның сүздәге урынына бәйле үзгәрешләрдән тагын протеза, эпентеза һәм эпитеза күренешләрен атап үтү урынлы

булыр. Татар телендә алар чит телләрдән, аерым алганда рус теленнән сүзләр кабул иткәндә күзәтеләләр.

***Протеза*** – сүз башындагы янәшә тартыклар алдына сузык аваз өстәлү: *эшләпә* (шляпа), *эскәмия* (скамья), *эскерт* (скирда), (ы)шкаф һ.б.

***Эпентеза*** – сүз башындагы янәшә тартыклар арасына сузык аваз өстәлү: *сумала* (смола), *каравать* (кровать), *келәт* (клеть), *бүрәнә* (бревно) һ.б.

***Эпитеза*** – сүз ахырына сузык аваз өстәлү, бу күренеш сүз ахырында ике тартык янәшә килгәндә күзәтелә: *отпускы* (отпуск), *пропускы* (пропуск), *Сарански* (Саранск), *Омски* (Омск) һ.б.

***Авазларның комбинатор үзгәрешләре***

***Аккомодация*** (җайлашу) – сузык һәм тартыклар әйтелешенең бер-берсенә җайлашуы. Сузыклар аккомодациясе – тартыклар тәэсирендә сузыкларның үзгәрүе, тартыклар аккомодациясе – сузыклар тәэсирендә тартыкларның үзгәрүе: нечкә сузыклар янында тартыклар нечкәрәк әйтелә – палатальләшә, калын сузыклар янында калынрак әйтелә – велярлаша.

***Ассимиляция*** (охшашлану) – ике охшаш булмаган тартык авазның бер-берсенә тәэсир итүе нәтиҗәсендә бер төрле яки якын артикуляцияле охшаш авазлар барлыкка килү: *сделать* – ***з****делать* (яңгыраулыкта охшашлану); *унбиш* – *у****м****биш* (ясалу урыны буенча охшашлану), *күренми* – *күре****мм****и* (ясалу урыны буенча охшашлану) һ.б.

***Диссимиляция*** (охшашсызлану) – артикуляциясе буенча охшаш ике аваздан төрле авазлар барлыкка килү. Мәсәлән: *шешә – чешә, шашкан – чашкан, прорубь – пролубь, ярмарка – ярминкә* һ.б. Диссимиляция сөйләм телендә бик актив.

***Сингармонизм***. Башкача әйткәндә, бу күренеш сузыклар ярашуы дип атала: сүзнең беренче иҗегендә (тамырда) нинди сузык аваз килсә, калган иҗекләрдәге, кушымчалардагы сузыклар да шул сузыкка ярашалар. Төрки телләрнең барысында да диярлек (үзбәк һәм чуваш теленнән кала) күзәтелгән бу үзенчәлек закончалыклы рәвештә барлык сүзләрдә дә сакланганлыктан, аны *сингармонизм законы* дип йөртәләр. Аның ике төрен аерып карыйлар: *рәт гармониясе* (сузыклар беренче

иҗектәге сузыкка рәте буенча – калынлыкта-нечкәлектә ярашалар: *киләләр, авылдаш*) һәм *ирен гармониясе* (беренче иҗектәге иренләшкән авазларга ярашып, калган иҗекләрдәге сузыклар да иренләшәләр: *болын [болын], көлке [көлкө]*).

Татар теленең диалектларында һәм гади сөйләмдә комбинатор үзгәрешләрнең тагын түбәндәге төрләре дә очрый, алар, башлыча, ассимилятив, яки диссимилятив тенденцияләргә нигезләнәләр:

– ***диэреза*** вакытында аерым тартыклар әйтелмичә төшеп кала: *солнце – сонце, поздно – позно, белән – белә, кайчы – качы* һ.б.;

– ***геминация*** – тартыкның көчәйтелеп, ике тапкыр әйтелүе: *оллы, икке* һ.б.;

– ***гаплология*** – сүздәге бертөсле аваз яки иҗекнең берсе төшеп калу: *близозоркий – близорукий, курноносый – курносый, минералология – минералогия* һ.б. Ләкин мәгънәгә зыян килерлек булса, иҗек төшеп калмый: *филология, орденоносец* һ.б.;

– ***метатеза*** – сүздәге авазларның урыннары алышыну: *мәрмәр – мрамор, ведмедь – медведь, абзар – азбар, күләгә – күгәлә* һ.б.;

– ***аваз таркалу***. Кайвакыт аваз әйтелешендәге төп хәрәкәтләрнең аерылып көчәюе нәтиҗәсендә яңа аваз барлыкка килә. Мәсәлән, *что – што, конечно – конешно* һ.б.;

– ***элизия*** – ике сүз чигендә сузыклар очрашып, бу сүзләр бер басым астында әйтелгәндә (сандхи шартларында) барлыкка килә торган үзгәреш: *бара+иде – барайде, кара+урман – карурман* һ.б. Нәтиҗәдә бер аваз төшеп кала, я дифтонг, я бөтенләй яңа аваз барлыкка килә. Элизия күп очракта язуда чагылыш тапмый;

– ***авазлар чиратлашу***. Авазларның сөйләм агышында һаман үзгәреп торуы сәбәпле, бер үк морфема төрле аваз вариантларында йөрергә мөмкин. Мәсәлән, *тап – табу, ак – агу, нога – ножной* сүзләрендә *п-б, г-к, г-ж* авазлары чиратлаша. Авазлар чиратлашу хәзерге тел нормалары яисә аның элеккеге кагыйдәләре нигезендә бара.

### 4. Сөйләмнең фонетик кисәкләре.

Фонетик яктан караганда сөйләм авазлар агымыннан яки авазлар чылбырыннан тора. Бу чылбыр үзара буйсынган,

үзенчәлекле, чиста фонетик берәмлекләрдән гыйбарәт булган, берсе артыннан икенчесе килә торган буыннарга таркала. Сөйләмнең фонетик кисәкләре – текст, фраза, синтагма (такт), сүз, иҗек һәм авазлар.

1. Сөйләмнең иң зур кисәге – ***текст***. Сөйләмнең мәгънәви, логик, коммуникатив, структур-грамматик, интонацион яктан оешкан иң зур берәмлеге ***текст*** дип атала. Фонетик яктан караганда ул паузалар белән чикләнә һәм аның үз яңгыраш рәвеше була. Текстның озынлыгы турындагы мәсьәлә әлегә кадәр бәхәсле булып кала бирә.

2. ***Фраза*** – тексттан кала икенче зур фонетик берәмлек, мәгънәсе буенча төгәлләнгән әйтелмә. Фразалар аерым интонация ярдәмендә формалаша; сөйләм чылбырында фразалар үзара паузалар, ягъни яңгырашның тукталуы белән аерыла. Пауза вакытында сөйләүче икенче фразаны әйтү өчен сулыш ала. Грамматик берәмлек (җөмләне) белән фонетик берәмлекне (фраза) тәңгәлләштерергә ярамый, чөнки бер фраза берничә җөмләне үз эченә алырга, яки киресенчә, бер фраза берничә җөмләгә таркалырга мөмкин. Фразаны интонация оештыра; һәр әйтелгән фразаның үз интонацион схемасы була.

3. Фраза синтагмаларга (сөйләм тактларына) таркала. ***Синтагма*** (такт) – сөйләмнең интонацион-мәгънәви кисәге, фразаның паузалар белән аерылып торган һәм тәмамланмаганлык интонациясе белән әйтелә торган өлеше. Сөйләмнең синтагмаларга бүленеше турыдан-туры мәгънә белән бәйләнгән: сөйләмне синтагмаларга (тактларга) теләсә ничек бүлү фикерне үзгәртүгә, яисә бөтенләй бозуга китерә *(Атарга ярамый калдырырга. Яхшы утыр.)*.

4. Синтагма (такт) фонетик сүзләргә таркала. ***Фонетик сүз*** – сөйләм тактының бер басым белән әйтелгән кисәге. Фонетик сүз һәрвакытта да лексик яки грамматик сүз белән тәңгәл килми. Күпчелек телләрдә барлык мөстәкыйль сүзләрнең фраза яки такт эчендә үз басымнары була. Ярдәмче сүзләр исә, басымнары булмаганлыктан, мөстәкыйль сүзләрнең йә алдыннан, йә артыннан килеп, алар белән *фонетик сүз* барлыкка китерәләр. Басымсыз сүзнең басымлы сүз алдыннан килүе *проклиза* күренеше дип атала, басымсыз сүз үзе *проклитика* була (без

шл**я**пы, ты ход**и**л). Басымсыз сүзнең басымлы сүз артыннан килүе *энклиза* була, басымсыз сүз *энклитика* дип йөртелә (ход**и**л бы, кт**о** это). Кайвакыт мөстәкыйль мәгънәле сүзләр дә проклитика яки энклитикага әйләнергә мөмкин, бу бигрәк тә шигъри сөйләмдә күзәтелә.

5. Фонетик сүзләр иҗекләргә таркала. ***Иҗек*** – әйтелешнең иң кечкенә берәмлеге. Ул тактның бер яки берничә авазадн торган кисәге. Иҗек составында бер, ике, биш аваз да булырга мөмкин. Һәркем иҗекләргә бүлеп әйтә белүгә карамастан, иҗеккә билгеләмә бирү һәм аның чикләрен билгеләү фонетиканың катлаулы мәсьәләреннән санала.

Төзелешләре буенча иҗекләр *ачык* (сузык авазга тәмамлана) һәм *ябык* (тартык авазга бетә) була. Сонор авазларга беткән иҗекләрне *ярымачык* иҗекләр дип йөртәләр.

6. Иҗекләр ***аваз***лардан тора. Бу күзлектән караганда, *сөйләм авазы* – иҗекнең бер артикуляция эчендә әйтелгән (ягъни бер экскурсия, бер рекурсиядән торган) кисәге.

**5. Басым һәм интонация.**

Басым һәм интонация просодик күренешләргә карый, алар сөйләмнән аерылып чыга алмыйлар, сегмент элементларның бөтенлеген тәшкил итәләр.

***Басым***

Басым сөйләмнең бер кисәген башкаларыннан аерып кую өчен хезмәт итә торган суперсегмент элемент. Аның берничә төре бар.

***Сүз (иҗек) басымы*** сүздәге бер иҗекне башкаларыннан аерып куя. Сүз басымы – сүзнең җаны. Басым – сүзнең төп билгесе. Басымын югалткан сүз мөстәкыйльлеген югалта һәм кушымчага әйләнә, соңыннан бөтенләй юкка чыгарга мөмкин. Сүз басымы дүрт төрле була: көч басымы, микъдари басым, тойгы басымы, музыкаль басым. *Көч* басымы үзенең көче белән аерылып тора, *микъдари* басым озынлыгы белән аерыла, *музыкаль* басым төшкән иҗек башкаларыннан тонының югарырак булуы белән характерлана. *Тойгы* басымы (эмоциональ) булганда иҗек көчен, озынлыгын, мелодикасын үзгәртә: *Сау бул! Ой!* (төрлечә әйтергә мөмкин).

Һәрбер телдә басымның теге яки бу төре өстенлек итә. Рус, инглиз, төрки телләрдә көч басымы таралган, рус телендә микъдари басымы да катнаша, музыкаль басым кытай, корея телләре өчен хас. Кайбер телләрдә сүз басымы сизелмәскә дә мөмкин (француз, тунгус-маньчжур һ.б.).

***Логик басым*** – сөйләмдәге бер сүзнең башкаларыннан аерылып торуы. Логик басым сөйләмдә аралашу өчен әһәмиятле булган сүзгә төшә. Ул – сөйләмнең коммуникатив үзәге. Гадәттә, логик басым татар телендә хәбәр алдындагы сүзгә, рус телендә соңгы сүзгә төшә. Ләкин инверсия булганда бу кагыйдәдән тайпылышлар да булырга мөмкин.

***Синтагма басымы*** сөйләмнең интонацион-мәгънәви берәмлекләренә төшә, ул сүз яки логик басым белән дә туры килергә мөмкин.

### ***Интонация***

**Интонация**не сөйләмнең җаны диләр. Ул бик катлаулы күренеш. Аның түбәндәге билгеләре бар:

а) интонация тавышның күтәрелүеннән һәм төшүеннән тора: бу сөйләмнең мелодикасы. Сөйләм мелодикасы һәр телдә үзенчә. *Мелодика* әйтү максаты буенча җөмлә төрләрен (хикәя, сорау, боеру, өндәү) аера. Аның ярдәмендә кешенең эмоциональ халәте дә белдерелә;

ә) көчле һәм көчсез, озын һәм кыска иҗекләр чиратлашуыннан гыйбарәт – фраза эчендә ул фразага ритм өсти;

б) сөйләмнең билгеле бер вакыт аралыгында акрын яки тиз агышы белән, ягъни сөйләмнең тизләнеше һәм акрынаюы белән характерлана – болар сөйләмнең темпын барлыкка китерә. *Темп* – аерым сүзләрнең һәм сүзтезмәләрнең билгеле бер вакыт аралыгында тиз һәм әкрен әйтелешләренең чиратлашуы;

в) әйтелешнең көчле яки көчсез булуыннан тора – бу сөйләмнең интенсивлыгын тудыра. *Интенсивлык* сөйләм органнарының киеренкелеге, сулап чыгаруның көче белән бәйле, ул сөйләмдәге иң әһәмиятле сүзләрне аерып чыгарырга ярдәм итә;

г) фраза эчендәге паузаларның булу-булмавыннан тора. *Пауза* – фразалар, синтагмалар арасындагы тукталыш. Ул сулыш алу өчен кирәк. Паузалар фразаның аерым кисәкләренә басым ясыйлар, фразаны ярымфразаларга бүләләр;

д) интонация шулай ук әйтелмәнең гомуми тембрыннан гыйбарәт. *Тембр* – өстәмә төсмерләр исәбенә тавышның үзгәрүе. Безне кем тыңлауга карап, тембр үзгәрә. Максатка бәйле рәвештә тембр “шат”, “күңелсез”, “уенчак”, “куркынган” һ.б төрләрдә булырга мөмкин.

Интонация язуда тыныш билгеләре белән белдерелә. Әмма сөйләм интонациясен тыныш билгеләре белән генә биреп бетерү мөмкин түгел.

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар**

1. Фонетика һәм фонология фәннәренең өйрәнү объектлары нәрсәләрдән гыйбарәт?
2. Сөйләм авазларын нинди аспектлардан чыгып өйрәнәләр?
3. Нәрсә ул артикуляцион база?
4. Акцент ничек барлыкка килә?
5. Сөйләмдә нинди аваз үзгәрешләре була?
6. Сөйләм нинди фонетик кисәкләргә бүленә?
7. Басым нәрсә ул? Аның нинди төрләре була?
8. Интонациянең нинди акустик компонентлары бар?

## Тема: ТЕЛНЕҢ СҮЗЛЕК СОСТАВЫ

1. Лексикология фәне һәм аның тармаклары.
2. Сүз турында төшенчә.
3. Лексик мәгънәләрнең типлары.
4. Телнең сүзлек составы турында мәгълүмат.
5. Әдәби телнең сүзлек байлыгын тулыландыру юллары.

### 1. Лексикология фәне һәм аның тармаклары.

Телдәге барлык сүзләр җыелмасы *лексика* дип атала. Лексика сүзләрдән һәм сөйләмдә әзер килеш кулланыла торган тотрыклы сүзтезмәләрдән тора.

Лексиканы, аның үсешен һәм кулланылышын өйрәнә торган фән ***лексикология*** була, ягъни лексикология – сүз турында сүз, яки сүз турында фән.

Лексикология алдында торган иң катлаулы һәм мөһим бурыч – телдәге һәр аерым лексик берәмлекне җыю, теркәү, аларның мәгънәләрен ачыклау һәм тасвирлау. Бу эш белән ***лексикография*** (сүзлекләр төзү теориясе һәм практикасы турындагы фән) шөгыльләнә. Дөньядагы барлык төр

сүзлекләрне икегә бүлеп карыйлар: энциклопедик һәм филологик сүзлекләр.

*Энциклопедик сүзлекләр*дә төшенчәгә аңлатма бирелә, алар турындагы карашлар, гипотезалар, фикер каршылыклары чагылдырыла, шушы төшенчәләр белдергән күренешләр, әйберләр, вакыйгалар, затлар турында мәгълүматлар да бирелә. Энциклопедияләрнең *универсаль* һәм *махсус* дигән төрләре була. Универсаль энциклопедияләрдә җәмгыять тормышы һәм фәннең төрле тармакларыннан системага салынган мәгълүматлар бирелә. Мәсәлән, Зур Совет энциклопедиясе, Татар энциклопедик сүзлеге һ.б. Махсус энциклопедияләр медицина, авыл хуҗалыгы, физика, техника, педагогика, музыка, әдәбият белеме һ.б. буенча төзелергә мөмкин.

*Филологик сүзлекләр*дә сүзләр, аларның мәгънә үзенчәлекләре, лексик-грамматик сыйфатлары аңлатыла. Максаты, эчтәлеге, сүзлек мәкаләләренең нинди телдә язылуы һ.б. карап, филологик сүзлекләрнең ике төре була: *бертелле* һәм *тәрҗемәле* сүзлекләр. Бертелле сүзлекләрдә тел материалы бары тик бер телдә генә тасвирлана. Боларга телләрнең күпчелегендә булган аңлатмалы сүзлекләрне, синонимнар, антонимнар, омонимнар сүзлекләрен, фразеологик сүзлекләрне һ.б. кертеп карыйлар. Тәрҗемәле сүзлекләрне ничә тел материалы кулланылуга карап *икетелле* һәм *берничә тел* сүзлекләренә бүләләр. Икетелле сүзлекләр иң күп таралган сүзлекләрдән санала: русча-татарча, татарча-русча, русча-инглизчә, русча-төрекчә һ.б. Берничә тел сүзлекләрендә өч-дүрт һәм хәтта аннан да күбрәк телләр янәшә куелырга мөмкин. Мәсәлән, татарча-русча-гарәпчә сүзлек, русча-татарча-инглизчә сүзлек һ.б.

Лексикологиянең сүз мәгънәләре һәм сүз мәгънәләренең үзгәрү сәбәпләрен өйрәнә торган махсус бүлеге ***семасиология*** дип йөртелә. Лексикология һәм семасиология үзара тыгыз бәйләнгәннәр, чөнки сүзнең җаны – аның мәгънәсе. Сүз форма һәм мәгънә бердәмлегеннән гыйбарәт булганга, аны лексиологик һәм семасиологик аспектлардан тасвирларга кирәк.

Сүзнең атау функциясе, предметларга, күренешләргә атама бирү закончалыклары лексиканың ***ономасиология*** тармагында

карала. Сүзнең тарихын, килеп чыгышын өйрәнә торган тармакны ***этимология*** диләр. Телдә бер төшенчә белдерү өчен катып калган тотрыклы сүзтезмәләрне ***фразеология*** тикшерә.

Лексикология составында гамәли әһәмиятләре белән аерылып торган ***ономастика*** һәм ***топонимика*** тармаклары бар. *Ономастика* ялгызлык исемнәр – кеше исемнәре, кушаматлар, отчестволар һ.б. тарихын тикшерә. *Топонимика* – ялгызлык характерындагы географик атамаларны өйрәнә (авыл, шәһәр, елга, күл һ.б.). Бу ике тармакны бергә ***топономастика*** дип тә йөртәләр. Үз эчендә ул *зоонимика* (хайван кушаматлары), *космонимика* (күк җисемнәре исемнәре), *гидронимика* (сулык исемнәре) һ.б. тармакларга аерыла.

**2. Сүз турында төшенчә.**

Лексикологиянең төп берәмлеге – сүз. Һәрбер сүзнең аваз ягы, төзелеше, мәгънәсе, грамматик билгеләре бар. Алар сүздә һәрвакыт бергә яшиләр. Ләкин сүзне өйрәнгәндә бу якларның һәрберсен аерым-аерым карыйлар.

Сүзгә, дистәләрчә билгеләмәләр бирелеп, аның төп үзлекләре ачыкланса да, тел белемендә кабул ителгән уртак билгеләмә хәзерге көнгә хәтле юк әле. Сүзгә бердәнбер билгеләмә булмауга карамастан, аның төп (фонетик, лексик, грамматик) билгеләрен күрсәтергә мөмкин.

1. Сүз фонетик яктан формалашып җиткән була. Аваз тышчасыннан башка сүз була алмый. Ул сүзнең яңгыраш ягын тәшкил итә: сүз башы, сүз азагы закончалыгы, фонемаларның үзенчәлекле тезмәләре, бер басымга ия булу, бөтенлек (сүз эченә авазлар өстәү мөмкин түгел) – бу сыйфатлар һәр сүзгә хас.

2. Лексик яктан һәр сүзнең мәгънәсе була. Телдә мәгънәгә ия булмаган сүз юк.

3. Грамматик яктан сүз теге яки бу сүз төркеменә карый.

4. Сүз нәрсәне дә булса атый, ягъни аңа атау (номинатив) функциясе хас. Әмма ярдәмлек сүзләр искәрмә булып тора, чөнки аларның атау функциясе юк.

5. Сүз телдә һәрвакыт яши, сөйләм вакытында ул тел хәтереннән алына.

Сүз – телнең төп берәмлеге. Атау берәмлеге булган сүздә бер үк вакытта телнең грамматик үзлекләре дә чагылыш таба, шунлыктан ул грамматик берәмлек тә. Номинатив берәмлек буларак сүзне *лексема*, ә грамматик берәмлек буларак *сүз формасы* дип йөртәләр. Сүз һәм лексема терминнары күп очракта телнең бер үк күренешен атыйлар. Мәсәлән, *югарыга* дигән берәмлек бер үк вакытта сүз дә, лексема да. Ә менә *белән, һәм* – сүзләр, әмма лексема була алмыйлар, чөнки алар номинатив берәмлекләр түгел. “Кеше кешегә иптәш һәм дус” җөмләсендә биш сүз, әмма өч лексема. Лексема гади дә (бер сүздән гыйбарәт) һәм тезмә дә булырга мөмкин (тимер юл, Кара диңгез, югары уку йорты).

**3. Лексик мәгънәләрнең типлары.**

Лексикологиядә сүзнең лексик мәгънәләре өйрәнелә. Һәр лексик мәгънә бер сүзгә карый: *йорт, бала, бүген, кичә, озын, яшел, бер, ике, бару, кайту* һ.б. Ләкин һәрбер сүз гомумиләштерә. Алда әйтелгән сүзләр белән теләсә нинди йорт, бала һ.б төшенчәләр белдерелә. Сүз белдергән лексик мәгънәләр гаять күп. Бу лексик мәгънәләренең типларын сүзнең а) кешене чолгап алган чынбарлыкка мөнәсәбәтенә; ә) кешенең фикеренә, хисләренә, теләкләренә мөнәсәбәттә; б) телдәге башка сүзләргә мөнәсәбәткә карап төркемлиләр.

I. Сүзнең чынбарлыктагы предметларга һәм күренешләргә мөнәсәбәтеннән чыгып, номинатив һәм сигнал, туры һәм күчерелмә, конкрет һәм абстракт мәгънәләр аерыла.

*Номинатив мәгънәләр* предметны, күренешне, билгене атарга мөмкинлек бирәләр һәм аларны бер-берсеннән аералар: төн, ашау, йомшак, тиз һ.б. *Сигнал* мәгънәләр предметны индивидуаль исем бирмичә генә күрсәтәләр, аңа ишарә ясыйлар: *теге, шулай, уф, чөнки* һ.б.

*Туры* мәгънәсендәге сүз предметны, күренешне, билгене турыдан-туры, башка мәгънәләрне күз алдында тотмыйча чагылдырыла: якты, чабу, тирән һ.б. *Күчерелмә* мәгънәләрдә предмет, күренеш, билге шул ук сүзнең башка мәгънәләре аша чагыла: *матур кыз – матур теләк, су ага – гомер ага, көмеш йөзек – көмеш туй* һ.б. Күчерелмә мәгънәләрнең метафора,

метонимия, синекдоха, функция буенча күчеш дип аталган төрләре бар.

*Конкрет* мәгънәләр конкрет бер предметка, күренешкә, билгегә карыйлар: *өй, тырма, яшел* һ.б. *Абстракт* мәгънәләр исә нинди дә булса конкрет бер предметны, күренешне, билгене белдермиләр: *аклык, фикерләү* һ.б.

II. Лексик мәгънәләрнең аңга (фикерләүгә) мөнәсәбәтенә бәйле рәвештә, сүздә терминологик һәм гомуми, образлы һәм образсыз, эмоциональ һәм эмоциональ булмаган мәгънәләр табыла.

*Терминологик* мәгънәләр төшенчәгә тәңгәл килергә омтыла. *Гомуми* мәгънәләрдә төшенчә өстәмә төсмерләр исәбенә баетыла.

*Образсыз* мәгънәләрнең күләмендә күзаллаулар юк. *Образлы* мәгънәләрдә исә күзаллаулар яши.

*Эмоциональ* һәм *эмоциональ* булмаган мәгънәләр кешенең хис-тойгыларын белдерү, белдермәүләре белән аерылалар.

III. Тел структурасындагы лексик мәгънәләрнең үзара бәйләнешендәге аермаларга карап, синонимик, антонимик, монолексик, ононимик, мотвлашкан һәм мотивлашмаган, нигез һәм ясалма, ирекле һәм бәйле мәгънәләр аерыла.

*Синонимик* (охшаш яки якын) мәгънәләр: *салкын, суык; җылы, эссе, кайнар* һ.б.

*Антонимик* (капма-каршы) мәгънәләр: *көн – төн, ак – кара, кайта – китә, югары – түбән* һ.б.

*Монолексик* мәгънәләр бер сүзгә карыйлар һәм үзара бәйләнгән булалар: *агач башы, кеше башы, өч баш суган, баш кеше* һ.б.

*Омонимик* мәгънәләр – бер яңгырашка ия булган сүзләрдә очрый торган төрле мәгънәләр, алар арасында бәйләнеш булмый: *яз* – исем (ел фасылы), *яз* – фигыль (кәгазьгә язу) һ.б.

*Мотивлашмаган мәгънә* башка мәгънәләргә бәйле түгел: өстәл, сары, май һ.б. *Мотивлашкан мәгънә*не туры мәгънәдән чыгып аңларга мөмкин: *бай өстәл, сәгать йөри, ялкынлы сөю* һ.б.

*Нигез* һәм *ясалма мәгънәләр* бер сүздән икенче сүз барлыкка килү нәтиҗәсендә туалар: *сердәш – сер* сүзеннән, *язучы – яз, эшче – эш, җитәкчелек – җитәкләү* һ.б. Яңа ясалган сүз ясалма

сүз була, ә аның мәгънәсен *ясалма мәгънә* диләр. Яңа сүзгә нигез булган сүз *нигез сүз* була, ә яңа сүз ясау өчен файдаланылган мәгънә *нигез мәгънә* дип атала. Һәр ясалма мәгънә нигез мәгънәгә нигезләнә.

Телдә тагын *ирекле* һәм *бәйле мәгънәләр* була. Һәр ирекле мәгънә аерым сүз белән белдерелә: *авыз, ак, тимер, тию, селтәү, сибү* һ.б. Бәйле мәгънә кимендә ике сүз белән белдерелә: *ак шигырь, тимер юл, түбәсе күккә тию, кул селтәү, борчак* һ.б.

**4. Телнең сүзлек составы турында мәгълүмат.**

Телдәге барлык сүзләр аның озын тарихи үсеше нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Телнең *лексикон*ында (грекча сүзлек, сүзләр запасы) бер төркем сүзләр башка сүзләрдән ачыктан-ачык аерылып тора. Аны *төп лексик фонд* дип атыйлар.

Сүзләрне актив һәм пассив катламнарга аерып карыйлар, ул сүзләрнең кулланылу ешлыгына нигезләнә. Төрле сәбәпләр аркасында аерым чорларда бер төркем сүзләр башкаларына караганда ешрак кулланыла. Билгеле бер чорда кулланылышта булган сүзләр телнең *актив лексика*сын тәшкил итә. Сирәк кулланыла торган сүзләр *пассив лексика*га карый.

Актив һәм пассив сүзләргә бүленеш лексиканың хронологик яктан *искергән* һәм *яңа сүзләр* катламына аерылуы белән тыгыз бәйләнештә. Кагыйдә буларак, искергән сүзләр пассив була, шулай ук һәр яңа сүзне дә актив дип әйтү мөмкин түгел.

*Искергән сүзләр* – актив кулланылыштан чыккан, әмма пассив сүзлек составында сакланган сүзләр. Искерү сәбәпләренә бәйле рәвештә искергән сүзләрне тарихи сүзләр һәм архаизмнар дигән төрләргә бүлеп карыйлар.

*Архаизмнар* – актив сүзлек составыннан синонимнары кысрыклаган сүзләр. Алар предмет һәм күренешләрнең искергән атамалары, әмма бу очракта күренешләр үзләре искермиләр, хәзерге вакытта да яши бирәләр, тик билгеле бер чорда аларга яңа атамалар бирелә һәм искеләре сирәк кулланыла башлый (мәсәлән, чор колоритын тудыру максаты белән, тантаналы стильдә, көлкеле халәт тудыру өчен һ.б.).

Еш кына сүзләр атаган предметлары һәм күренешләре тормыштан китү сәбәпле пассив лексикага күчәләр. Аларны

тарихи сүзләр дип атыйлар. *Тарихи сүзләр* – хәзерге вакытта кулланылыштан, халыкның тормыш-көнкүрешеннән төшеп калган элеккеге чор әйбер-күренешләрен һәм төшенчәләрен аңлаткан сүзләр. Тарихи сүзләрнең хәзерге телдә синонимнары булмый. Искергән сүзләр, аеруча тарихи сүзләр яңа күренеш һәм төшенчә атамалары буларак актив кулланылышка кире кайтырга мөмкин.

Искергән сүзләргә телдә неологизмнар каршы куела. *Неологизмнар* – кулланучы буын хәтерендә туган яңа сүзләр һәм мәгънәләр. Кайвакыт неологизм билгеләмәсенә башка билгеләр дә өстәлә: яңа күренеш һәм төшенчәләрне аңлату, иске атамаларны алмаштыру, яңалыкны белдергән стилистик эффект, сүзлекләрдә теркәлмәү һ.б. Һәр чор һәм һәр буын яңа сүзләр барлыкка китерә. Кагыйдә буларак, яңа сүзләр зарурлыгы фән һәм мәдәният үсеше, техниканың алга китеше, иҗтимагый тормыш үзенчәлекләре белән бәйле була.

**5. Әдәби телнең сүзлек байлыгын тулыландыру юллары.**

Телнең сүзлек составы баюда ике чыганак бар: 1) *телнең эчке ресурслары*: телнең үз мөмкинлекләреннән чыгып сүзләр ясалу; телдә яшәп килгән сүзләрнең мәгънәләре киңәю; диалектлардан сүзләр алу; калькалаштыру[12] – чит тел сүзен кисәккә-кисәк тәрҗемә итү юлы белән яңа сүз ясау; 2) *тышкы ресурслар*: чит телләрдән сүзләр алу.

Алынма сүзләрне төркемләүдә гомум кабул ителгән классификация юк. Чит тел сүзләрен *әйбер* яки *төшенчәгә бәйле* һәм *бәйле булмаган*нарын аерудан тыш, *туры* һәм *кыек алынма*ларга бүләләр. Туры алынмалар бер телдән икенчесенә турыдан-туры күчә, ә кыек алынмалар икенче бер арадашчы тел аша керә.

Чит тел сүзләре үзләренә ят бер телгә килеп кергәннән соң, телнең законнарына яраклаша башлыйлар: алган тел сүзләренең аваз һәм грамматик сыйфатларын кабул итәләр. Ассимиляция дәрәҗәсенә карап, *үзләштерелгән* һәм *үзләштерелмәгән алынмалар* була. Үзләштерелгән алынмалар үзләре өчен яңа булган тел системасына шул дәрәҗәдә яраклашалар ки, аларның

[12] Бу ысул кайбер хезмәтләрдә тышкы ресурс буларак карала.

алынма булулары хәтта сизелми дә, бары этимологик анализ гына бу сүзләрнең чыганагын билгели ала (мәсәлән, рус телендә *доска, сахар, капуста, тарелка, диван, суп, кофта* һ.б. сүзләр). Үзләштерелмәгән алынмаларны икенче төрле *варваризмнар* дип йөртәләр, аларның чит телнеке булулары аваз, график, грамматик һәм семантик үзенчәлекләрендә чагыла.

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар**

1. Лексикология фәне нәрсәне өйрәнә һәм аның нинди тармаклары бар?
2. Телнең төп берәмлеге буларак сүзнең нинди билгеләрен беләсез?
3. Сүзнең лексик мәгънәсе һәм аның типлары турында сөйләгез.
4. Телләрнең сүзлек байлыгы нинди юллар белән үсә?
5. Сүзлекләрнең нинди төрләре була?

## Тема: ТЕЛНЕҢ ГРАММАТИК ТӨЗЕЛЕШЕ

1. Морфемика. Морфема һәм аларны төркемләү.
2. Сүз ясалышы һәм аның төп берәмлекләре.
3. Морфология, аның өйрәнү объекты.
4. Грамматик категория. Грамматик мәгънә. Грамматик форма.
5. Синтаксис. Төп синтаксик берәмлекләр.
6. Җөмлә кисәкләре турында мәгълүмат.

### 1. Морфемика. Морфема һәм аларны төркемләү.

Телнең фонемадан зуррак берәмлеге – морфема, ул фонема һәм сүз арасында тора. Морфемага карашлар төрле булса да, барлык галимнәр аның сүздән зур булмаска тиешлеге белән килешә, шул ук вакытта сүз составында ким дигәндә бер морфема булуы мәҗбүри.

***Морфемика*** – тел белеменең морфемалар системасын һәм аларның сүз составында яшәү кагыйдәләрен өйрәнә торган бүлеге. Морфемика шулай ук сүзләрне морфемик төзелешләре ягыннан системага сала, сүзләргә морфемик анализ ясау принципларын эшкәртә. Бу термин белән телнең морфемик төзелешен, аның морфемалары җыелмасын һәм морфема типларын атыйлар.

Морфема төшенчәсен һәм терминын фәнгә И.А.Бодуэн де Куртенэ кертеп җибәрә. Соңрак ул башка тел галимнәренең хезмәтләрендә үстерелә.

***Морфема*** – телнең ике яклы берәмлеге, аның билгеле фонетик яки график формасына (белдерелү планы) аерым бер

мәгънә теркәлгән була (эчтәлек планы). Мәсәлән *җырчы* сүзендәге *–чы* морфемасы “җырлау белән шөгыльләнә торган кеше” мәгънәсен бирә. Кайвакыт нуль морфема турында да фикер йөртәләр. Мәсәлән, *өй, өстәл, урам* кебек сүзләрдә кушымча юклыгы аларның баш килештә, берлек санда булуына ишарә итә.

Морфеманың төп билгеләре:

1) морфема ике яклы була: ул аваз ягыннан формалашкан һәм мәгънәгә ия;

2) морфема тагын ваграк кисәкләргә бүленә алмый;

3) морфемалар яңадан ясалмыйлар, бәлки телдә яшиләр;

4) алар мөстәкыйль түгел: сүз составына кереп, төрле мәгънә белдерәләр. Бу билге абсолют булмаска да мөмкин, чөнки: а) сүз белән тәңгәл килгән морфемалар да була (кофе, пальто); ә) аерым телләрдә, бигрәк тә аморф (тамыр) телләрдә (кытай, вьетнам телләрендә) сүз белән морфеманың каршы куелышы юк.

Морфемалар, мәгънәнең характерына, сүздәге урынына һәм сүздәге рольләренә карап, төрле төркемчәләргә аерылалар.

1. Морфемалар төп, деривацион һәм реляцион мәгънәләрне белдерәләр. *Төп* мәгънә сүзнең тамырында белдерә. *Деривацион* морфемалар тамырны ачыклап, конкретлаштырып килә, мөстәкыйль кулланылмый. Төрки, татар тел белемендә аларны *сүз ясагыч кушымчалар* диләр: авыл-даш, көч-сез, җыр-ла һ.б. *Реляцион* морфема сүзнең башка сүзләргә мөнәсәбәтен белдерә. Бу морфемаларны *форма ясагычлар* дип атыйлар, алар эчендә *сүз төрләндергечләр*не (килеш, сан-зат, тартым һ.б.) аерып чыгаралар: *эш-кә, укый-сың, әни-ем; деревням, новый, пишу.*

2. Сүз төзелешендәге урыны ягыннан, тамырга бәйле рәвештә, морфемалар *префик*слар (алкушымча – тамыр алдында йөриләр), *суффикс*ларга (тамырдан соң киләләр) һәм *постфикс*ларга (флексиядән соң урнашалар) бүленәләр: *до-работ-ать, плен-ниц-а, учу-сь.* Төрки телләрдә барлык кушымчалар – постфикслар гына: *яз-у, тор-мыш-ка, күл-ләр-не, эш-ләр-е(н)-дәге-се-н* һ.б. Болардан кала да аффикслар була: *конфикслар* (циркумфлекслар) тамырны чолгап алалар; *инфикслар* аффикслар эченә кереп урнашалар, мондый

кушымчалар Филиппин утрауларындагы бонток телендә һәм өлешчә латин телендә очрый; *интерфикслар* кушма сүзләрне берләштерәләр, рус телендәге *о, е* бәйләүче сузыклары шундыйлардан: *земл-е-коп, пар-о-ход, прибор-о-строение, пол-е-вод* һ.б.; *трансфикслар* тартыктан торган тамырларны аерым сузыклар белән аералар. Мондый кушымчалар гарәп телендә күзәтелә. Тартыклардан торган тамырлар янында сузык трансфикслар килә. Мәсәлән, -*а,* -*и* трансфикслары сыйфат фигыль ясый: *к-ә-т-и-б-ун* – язучы (тамыр к-т-б); *д-ә-р-с-үн* – укучы, белем алучы (тамыр д-р-с).

3. Морфеманың сүздә мәҗбүри булуы яисә мәҗбүри булмавы ягыннан *тамыр* һәм *аффиксаль* морфемаларга бүленәләр. Тамыр мофема һәр сүздә була, ә аффикслар факультатив булалар. *Тамыр* – сүзнең реаль мәгънәгә ия булган иң кечкенә кисәге, тамыр сүз төрләнеше белән бәйләнмәгән һәм шуңа күрә бер үк тамыр төрле сүз төркемнәрендә күзәтелә: *күз – күзлек, күзләү, күзлут, күзаллау, күзикмәк, күзле, күзсез* һ.б.; *читать – учитель, учить, вычитывать, прочитанный, читающий, прочитано* һ.б. Тамырларның кабатлануы һәрбер телдә күзәтелә. Мәсәлән, татар телендә *тиз* тамыры түбәндәге сүзләрдә очрый: *тизаткыч, тизлек, тизләнеш, тизләнешле, тизләнү, тизләткеч, тиз-тиз, тизәйткеч* һ.б. Бер тамыр тирәсенә оя төзеп тупланган сүзләр *тамырдаш* сүзләр дип аталалар.

4. Авазлар белән белдерелгән морфемалар белән беррәттән, телдә *нуль* морфема да булырга мөмкин: башка сүз формалары белән чагыштырганда, морфеманың булмавы мәгънә белдерә. Мәсәлән, весел-0 – весел-а – весел-о – весел-ы; умен-0 – умн-а – умн-о, умн-ы.

5. Морфемалар *иректе* һәм *бәйле* булырга мөмкин. Аерым сүз булып та кулланыла ала торган морфемалар ирекле була, алар шул ук рәвештә башка сүзләрдә дә кабатланып киләләр, болар – тамыр морфемалар. Бәйле морфемалар исә аерым гына кулланыла алмый, аларга күбрәк аффикслар кирә.

6. Килеп чыгышлары ягыннан караганда морфемалар *телнең үзенеке* һәм *башка телдән алынган* булуы ихтимал. Рус телендә очрый торган -*изм,* -*ист,* -*ад,* -*аж,* -*ант* морфемалары, *а-, архи-*,

*контр-, де-, экстра-* префикслары алынма морфемалар дип күрсәтелә. Татар телендәге *-ханә, -намә* компонентларын алынма кушымчалар дип санargoйлар (әмма аларның чыганак телләрдә мөстәкыйль мәгънәле сүзләр икәнен истә тотарга кирәк): басмаханә, даруханә, васыятьнамә, шәһадәтнамә һ.б. Гадәттә грамматик элементлар бер телдән икенче телгә сирәк үтеп керә, мисалга китерелгән морфемалар чит тел сүзе белән бергә дә үтеп керергә мөмкин.

## 2. Сүз ясалышы һәм аның төп берәмлекләре.

### *Сүзьясалыш структурасы*

Сүзьясалышы термины ике мәгънәдә йөри: телнең сүзьясалыш төзелеше һәм тел белеменең бер бүлеге. Формаль чаралар ярдәмендә яңа сүзләр ясауны күздә тоткан хәлдә, сүзьясалышын икенче төрле ***деривация*** дип тә атыйлар. Ясалма сүзләр ***дериват****лар*, ә алар турындагы фән ***дериватология*** дип атала.

Сүзнең сүзьясалыш структурасын тикшергәндә ***сүз нигезе*** төшенчәсе мөһим роль уйный. Сүзнең лексик мәгънәсен белдерә торган тамырдан һәм ясагыч кушымчалардан гыйбарәт өлеше ***нигез*** дип атала (реляцион мөнәсәбәтләрне белдерә торган кушымчалар нигез составына кермиләр, чөнки алар лексик мәгънәне түгел, ә грамматик мәгънә белдерәләр). Төзелешләре ягыннан алар *тамыр* һәм *ясалма* дигән төрләргә бүленәләр. *Тамыр нигезләр* тагын да кечерәк мәгънәле кисәкләргә бүленмиләр, ә *ясалма нигезләр* морфемаларга бүленә.

### *Сүзьясалыш мәгънәсе*

Һәр ясалма сүзнең үзен ясаган сүзе була (ягъни мәгънәсе һәм төзелеше ягыннан гадирәк тамырдаш сүзе). Яңа сүз ясый торган чара *сүзьясагыч форманты* дип атала. Ясалма сүзләрнең сүзьясалыш мәгънәсе була. *Сүзьясалыш мәгънәсе* – ясалма сүзнең ясагыч сүзгә карата булган, сүз эчендә формаль белдерелгән семантик мөнәсәбәте. Сүзьясалыш мәгънәсе бер төркем мотивлашкан сүзләрдә бердәй була: *борма, бөгелмә, йөкләнмә, казылма, күргәзмә, оешма, ташлама* сүзләрендә "ясаучы нигездән аңлашылган эш-хәрәкәт нигезендә барлыкка

килгән әйбер исеме” сүзьясалыш мәгънәсе –ма/-мә кушымчасы аша белдерелә.

Сүзьясалыш мәгънәсе лексик һәм грамматик мәгънәләр арасында тора. Лексик мәгънәдән аермалы буларак, ул аерым бер сүзгә генә түгел, ә бердәй формаль белдерелү чарасына ия булган бер төркем сүзләргә хас була. Ул бер сүз төркеменә кергән барлык сүзләрдә дә табылмый, ә аерым сүзләрне генә характерлый.

### ***Сүзьясалыш тибы***

Гадәттә бер үк сүз төркемннән булган ясагыч нигездән, бер үк сүзьясагыч чара ярдәмендә ясалган, бердәй сүзьясалыш мәгънәсенә ия булган ясалма сүзләрнең төзелеш схемасы ***сүзьясалыш тибы*** буларак аңлашыла. Мәсәлән, рус телендә -*тель* суффиксы белән ясалган сүзләр арасында ике сүзьясалыш тибы аерырга мөмкин: 1) зат мәгънәсен белдерә торган сүзләр – *учитель, писатель, читатель, руководитель*; 2) предмет мәгънәсен белдерә торган сүзләр – *подогреватель, взрыватель, выключатель, усилитель* һ.б.

Сүзьясалыш типлары *продуктив* һәм *продуктив булмаган* төрләргә аерыла. Әгәр хәзерге көндә дә шул үрнәк буенча яңа сүзләр ясалса – продуктив сүзьясалыш тибы була, ә инде яңа сүзләр ясалмый яисә сирәк ясалса, ул продуктив булмаган сүзьясалыш тибын тәшкил итә.

### ***Сүзьясалыш ысуллары***

Сүз ясалыш ысуллары ике зур төркемгә бүленә: ***аффиксаль*** һәм ***кушымчасыз ысул***.

***Аффиксаль ысул*** белән сүз ясаганда, формант буларак бер кушымча яисә кушымчаларның комбинациясе катнаша. Аффиксаль ысул буенча сүз ясалышы түбәндәге төрләргә бүленә: *префиксаль* (про-читать, за-водить), *суффиксаль* (началь-ник, чит-а-тель, юл-чы, як-таш, чәчәк-ле, баш-ла), *префиксаль-суффиксаль* (при-морь-е, по-дорож-ник), *префиксаль-постфиксаль* (до-звон-ить-ся), *суффиксаль-постфиксаль* (горд-и-ть-ся), *префиксаль-суффиксаль-постфиксаль* (о-банкрот-и-ть-ся), *нуль аффиксация алымы* (синь, гниль). Бу ысулны икенче төрле ***морфологик ысул*** дип тә

йөртәләр. Төрки телләрдә, агглютинатив телләр булганга, бу алымның суффиксаль төре гаять киң кулланыла

Сүз ясалуда ***кушымчасыз алым*** түбәндәге ысулларда чагыла: сүзнең бер өлешен кисеп ташлау, конверсия, аерым сүзләрне билгеле бер эзлеклелектә берләштерү. Кушымчасыз сүз ясаганда, түбәндәге төрләр барлыкка килә: 1) сүзләрне ялгау (генерал-майор, ва-гон-ресторан); 2) кисеп ташлау (зав, зам); 3) аббревиация (вуз, МГУ, завуч); 4) кабатлау (тихо-тихо, красный-красный, еле-еле, матур-матур, вак-вак); 5) конверсия (мороженое, столовая, җәяүле, таныш, өлкәннәр). Аларны башкача ***синтаксик, морфологик-синтаксик*** юллар дип тә йөртәләр. Сүзләр шулай ук ***фонетик*** **(**кайбер авазлар төшеп кала, я чиратлаша, я басым үзгәрә һ.б.: *хәзер – әзер, тугры – туры, сылтау- селтәү*), ***лексик-семантик*** юл (сүзнең яңа мәгънәсе барлыкка килә: *йомгак – йомгак* (итог мәгънәсендә), *түгәрәк – түгәрәк* (кружок мәгънәсендә) һ.б.) белән дә ясала.

Сүзьясалаш ысуллары да телдә үзгәреш кичерәләр. Иң яңа алымнар дип ***аббревиация*** һәм ***кисеп ташлау*** санала. Алар XX гасырда интенсив рәвештә үсеп китәләр.

### 3. Морфология, аның өйрәнү объекты.

**Морфология** сүз формаларын һәм алар белдергән мәгънәләрне, грамматик сүз классларын (сүз төркемнәрен), аларга хас грамматик категорияләрне өйрәнә.

Сүз төркемнәрен аеру принциплары барлык телләр өчен дә бердәй. Сүзләрне төркемнәргә бүлгәндә иң элек аларның уртак *лексик-грамматик* мәгънәләренә игътибар итәләр: бер төркем сүзләр предметны, икенчеләре предметның билгесен, өченчеләре эш-гамәлләрне, предметларның санын һ.б. мәгънәләр белдерә.

Уртак лексик-грамматик мәгънәләре буенча бер төркемгә кергән сүзләрнең үзләренә генә хас булган билгеле бер грамматик категорияләре бар. Мәсәлән, предметлык мәгънәсен белдерүче сүзләр татар телендә – килеш, сан, тартым белән; рус телендә род, сан, килеш белән төрләнәләр һ.б. Сүзләрне бу билгеләренә нисбәттә төркемләү *морфологик принцип*ның нигезендә ята.

Билгеле бер төркемгә кергән сүзләрдә төп грамматик мәгънәнең уртаклыгы бердәй морфологик билгеләр табылуга гына түгел, охшаш синтаксик билгеләр булуга да китерә. Шунлыктан сүзләрне төркемнәргә аерганда *синтаксик принцип* та исәпкә алынырга тиеш. Бу принцип буенча сүзнең җөмләдәге типик синтаксик функциясенә, аның башка сүзләр белән бәйләнешкә керү үзенчәлекләренә игътибар ителә.

Әйтелгәннәргә нәтиҗә ясап, сүз төркемнәренә түбәндәгечә билгеләмә бирергә мөмкин: *сүз төркемнәре* – уртак грамматик мәгънәләре, бердәй морфологик билгеләре һәм типик синтаксик функцияләре нигезендә берләшкән сүз класслары.

Сүз төркемнәрен мөстәкыйль һәм ярдәмлек сүз төркемнәренә бүлү кабул ителгән. *Мөстәкыйль сүз төркемнәре*нә кергән сүзләр аерым торганда реаль мәгънә белдерәләр, нинди дә булса грамматик категория күрсәткечләрен алалар, җөмләдә синтаксик функция үтиләр һәм яңа сүзләр ясау өчен нигез булып торалар. *Ярдәмлек сүз төркемнәре*ндә бу сыйфатлар табылмый. Шушы нигездә татар телендә исем, сыйфат, сан, алмашлык, рәвеш, фигыль, аваз ияртемнәре мөстәкыйль сүз төркемнәре дип өйрәнеләләр. Ярдәмлекләрнең белдергән мәгънәләре һәм телдә үтәгән функцияләре гаять төрле, шунлыктан аларны үз эчендә *бәйләгеч* (бәйлек, теркәгеч) һәм *модаль сүз төркемнәре* (сөйләүченең сөйләмгә мөнәсәбәтен белдерә торган сүзләр – кисәкчә, ымлык, хәбәрлек сүзләр) дип тә аералар.

Һәрбер телдә сүзләрне төркемнәргә бүләләр, әмма аларның саны, билгеләре, үзара мөнәсәбәте төрле телдә төрлечә чагылыш таба.

## 4. Грамматик категория. Грамматик мәгънә. Грамматик форма

***Грамматик категория*** – тулы бер сүзләр классына яки сүз тезмәләре классына хас булган һәм телдә формаль яктан белдерелгән универсаль семантик билге. Грамматик категория телдә бер-берсенә мөнәсәбәттә торган, капма-каршы куелган грамматик мәгънәләр булганда гына формалаша ала. Мисал өчен, килеш категориясе ким дигәндә ике килеш формасы, сан категориясе – ике төрле сан, заман категориясе кимендә ике

заман формасы булганда гына оеша. Әгәр грамматик мәгънәләр каршы куелмаса, телдә грамматик категория формалаша алмый.

Телләрдәге охшаш категорияләрнең күләме дә, ягъни каршы куелган мәгънәләр саны да төрлечә була.

***Грамматик мәгънә***ләр лексик мәгънәләрнең гомумиләшүеннән барлыкка килә. Тел аралашу чарасы буларак үскән саен, төрле сүзләрдә яңа гомуми билгеләр һаман табыла бара. Мәсәлән, фигыль заманнары чынбарлыктагы һәртөрле эшгамәл үткәндә, хәзер һәм киләчәктә башкарылуын күрсәтә. Сан мәгънәсе реаль чынбарлыктагы предметның конкрет исәбен белдерә. Димәк, грамматик мәгънәләр формаль мәгънәләр генә түгел, предметлар һәм күренешләрнең төрле классларын һәм шулар арасындагы мөнәсәбәтләрне белдерә торган мәгънәләр. Ул бер төркем сүзләргә һәм синтаксик төзелмәләргә хас. Грамматик мәгънә түбәндәге билгеләргә ия:

1. Ул гомумиләштерә.

2. Ул мәҗбүри (әгәр исемнәргә сан мәгънәсе хас икән, һәр исем ничек кенә булса шул мәгънәне белдерә).

3. Бер төркемгә кергән сүзләрнең барысында да табыла (мәсәлән, татар телендә барлык исемнәр килеш, сан, тартым белән төрләнәләр).

4. Грамматик мәгънәләрнең саны конкрет билгеле (лексик система ачык булганлыктан, яңа сүзләр һәм мәгънәләр ясалып торалар, ә грамматик мәгънәләр күп түгел).

5. Грамматик мәгънәләр типиклашкан (телдәге билгеле бер регуляр чаралар белән белдереләләр һ.б.).

Теләсә кайсы грамматик мәгънәнең үз белдерелү формасы була. ***Грамматик форма*** – сүз, сүзтезмә яки җөмлә формасының грамматик мәгънә белдерә торган өлеше.

Телләрдәге күптөрле грамматик формаларда чагылыш тапкан грамматик мәгънәләрне белдерү ысуллары әллә ни күп түгел. Алар грамматик мәгънәләрне синтетик һәм аналитик юллар белән белдерәләр.

*Синтетик юл* (грекча – берләштерү) бер сүз эчендә берничә морфеманы (тамыр, сүзьясагыч, сүз төрләндергеч морфемаларны) берләштерә. Грамматик мәгънә бу очракта сүз эчендә белдерелә. Грамматик мәгънәнең синтетик юл белән белдерелүенә түбәндәге

чаралар кирә: аффиксация, басым, редупликация, эчке флексия, супплетивизм.

Грамматик мәгънәләрне *аналитик юл* белән белдерү өчен ярдәмлек сүзләр (теркәгечләр, бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр, ярдәмче фигыльләр, кисәкчәләр, артикльләр); интонация; сүз тәртибе кулланыла. Грамматик мәгънәләрне белдерүче грамматик чараларның таралышы төрле телләрдә төрлечә.

***Аффиксация.*** Аффиксация дөньядагы күп телләрдә шактый киң таралган. Аффиксациянең ике төре бар: *агглютинация* һәм *фузия*. Икенчесен *флексия* дип тә атыйлар.

*Агглютинация* – тамырга кушымчаларның бер-бер артлы ялганып килүләре. Бу очракта тамыр үзгәрми, морфемаларның чикләре ачык күренеп тора. Агглютинация күренеше төрки, фин-угор телләренең морфологик үзенчәлеген тәшкил итә, аларны *агглютинатив телләр* дип йөртәләр.

*Флексияләр* (окончание) яңа сүзләр ясамыйлар, сүз ахырында киләләр. Рус телендә флексиянең тамыр, нигез белән тыгыз берегүе, кушылуы, ягъни *фузия* күренеше күзәтелә. Флексияләр нигезгә берегеп, фузия барлыкка килгән телләрне *флектив телләр* телләр дип атыйлар. Һинд-европа, семит телләре – флектив телләр.

***Эчке флексия.*** Тамыр эчендә авазларның, законлы рәвештә үзгәреп, төрле грамматик мәгънәләр белдерү өчен кулланылышы эчке флексия дип атала. Тарихи чиратлашулардан аермалы буларак, мондагы аваз үзгәреше фонетик позициягә бәйле түгел, ягъни аларның нигезендә грамматик сәбәпләр ята. Мәсәлән, немец телендә фигыль формалары шулай аерыла.

***Супплетивизм.*** Бер үк лексик мәгънәгә ия булган сүзләрнең төрле грамматик формаларын төрле тамырдагы сүзләр белән белдерү. Мәсәлән, *хороший, плохой* сүзләренең чагыштыру дәрәҗәсе – *лучше, хуже*; *брать* фигыленең совершенный виды – *взять*; *человек* сүзенең күплеге – *люди; я* алмашлыгының родительный падеж формасы – *меня*; *бу* сүзенең төшем килеше – *монысын; ул* сүзенең чыгыш килеше – *аннан* һ.б.

***Редупликация*** – тамырның (нигезнең), тулысынча яисә өлешчә кабатланып, грамматик мәгънә белдерүе. Бу чара ярдәмендә:

1) билгенең интенсивлыгы арта: *озын-озын***;** *большой-большой*;

*2)* төрки телләрдә артыклык дәрәҗәсе ясала: *ап-ак, зуп-зур***,** *зәп-зәңгәр*, *ямь-яшел;*

3) грамматик күплек белдерелә, бу аеруча япон, малайа, полинезия телләре өчен хас: *куни* (япон. ил) – *куни-куни* (илләр); *оранг* (индонезия. кеше) – *оранг-оранг* (кешеләр);

4) процессның дәвамлылыгы белдерелә: *баралар-баралар, әйттем-әйттем, ашаган-ашаган* һ.б.

5) арта торган күплек (бәйлекләр белән) мәгънәсе бирелә: *өй өстенә өй, хат артыннан хат, нур өстенә нур, мәшәкать артыннан мәшәкать* һ.б.

6) процессның артуы белдерелә: *якынайганнан-якыная, үскәннән-үсә, артканнан-арта* һ.б.

***Басым*** һәм ***интонация.*** Басым – күп телләрдә грамматик мәгънәне белдерә торган грамматик чара. Мәсәлән, рус телендә: *рук**и*** (күплек, баш килеше) – ***р**уки* (берлек, иялек килеше), *город**а*** (күплек, баш килеш) – *г**о**рода* (берлек, иялек килеш) һ.б. Татар телендә басым сүзнең төрле сүз төркемнәренә керүен билгели: *басм**а*** (исем) – *б**а**сма* (боерык фигыль); *бүлм**ә*** (исем) – *б**ү**лмә* (боерык фигыль).

Интонация әйтү максаты буенча җөмлә төрләрен билгели: *Фестиваль башланган. Фестиваль башланган? Фестиваль башланган!*

Интонация компонентлары җөмләдә төрле грамматик мәгънәләрне белдерүдә катнашалар. Мәсәлән, сүзләр арасындагы пауза сүзтезмәне юкка чыгара ала: *яхшы утыр – яхшы, утыр; шофер абыем – шофер – абыем* һ.б.

Интонация сөйләүченең сөйләмгә мөнәсәбәтен – модальлекне белдерү өчен дә кулланыла.

***Сүз тәртибе.*** Аффиксация аз булган телләр өчен сүз тәртибенең әһәмияте аеруча зур, чөнки сүзнең грамматик мәгънәсе аның җөмләдәге урынына карап үзгәрә. Сүз тәртибе җөмлә кисәкләренең функцияләрен билгели. Моны рус, татар телләрендә дә күзәтергә мөмкин. Мәсәлән: *Мать любит дочь. День сменяет ночь. Кеше аю ашаган. Ана бала ярата***.** Бу

җөмләләрдә беренче исем – һәрвакыт ия, икенче исем һәрвакыт туры тәмамлык була.

Рус телендә сүз тәртибе төгәл һәм якынча саннарны аера: *пять рублей – рублей пять, человек десять – десять человек* һ.б.

Төрки телләрдә сүз тәртибе ачыклаулы һәм хәбәрлекле мөнәсәбәтне, ягъни сүзтезмә һәм җөмләне аера: *кызыл байрак – байрак кызыл, акыллы бала – бала акыллы, уңган килен – килен уңган* һ.б.

***Ярдәмлекләр.*** Бу төр грамматик чаралар шулай ук аффиксация аз булган телләрдә күбрәк күзәтелә. Ярдәмлекләргә теркәгечләр, бәйлекләр, кисәкчәләр, артикльләр керә.

*Бәйлекләр* урнашу үзенчәлеге ягыннан ике төрле була: сүз алдында килгәннәрен – *предлог* (рус, инглиз телләрендә), сүздән соң килгәннәрен *послелог* (төрки, фин-угор телләрендә) дип атыйлар. Алар урын-ара, вакыт, максат, шарт, сәбәп һ.б. мөнәсәбәтләрне белдерәләр, билгеле бер килеш формалары белән кулланылалар, җөмлә кисәкләре арасындагы ияртүле бәйләнешне белдерәләр.

*Теркәгечләр* тезүле һәм ияртүле бәйләнешне белдерәләр, алар кушма җөмләдә аеруча зур роль уйныйлар.

*Кисәкчәләр* сөйләүченең сөйләмгә, чынбарлыкка мөнәсәбәтен күрсәтәләр һәм төрле мәгънәләр белдерәләр.

*Артикль* мөстәкыйль сүзләр белән килеп, аларның грамматик үзенчәлекләрен ачыклый: билгелелек-билгесезлек категориясен формалаштыра (немец, инглиз, француз, гарәп телләрендә); грамматик родны белдерә; грамматик сан күрсәткече була (француз, немец телләрендә); исемнең килеш формаларын белдерә ала.

Ярдәмлек сүзләр функциясендә кайбер мөстәкыйль мәгънәле сүзләр – аерым исемнәр, фигыльләр, алмашлыклар, саннар кулланылырга мөмкин. Телләрдә ярдәмче фигыльләрнең дә роле зур. Татар телендә *ит, бул* фигыльләре заман формаларын ясауда, зат һәм модаль мәгънәләрне белдерүдә катнашалар.

***Аваз чиратлашулары.*** Грамматик мәгънәләр аваз чиратлашу юлы белән дә белдерелергә мөмкин. Мәсәлән, рус телендә вид мәгънәсе өлешчә шушы чара ярдәмендә белдерелә: *нала**д**ить – нала**ж**ивать, упр**о**сить – упр**а**шивать* һ.б.

***Инкорпорация***. Бу күренеш сүз белән җөмлә чигендә күзәтелә. Тәмамлык, аергыч, хәл һ.б. җөмлә кисәкләре фигыль составына килеп кереп, аның белән кушма сүз ясый. Чукот телендәге *тивалантоак* тезмәсендә *ти* – I зат берлек сан күрсәткече, *вала* – пычак сүзенең нигезе, *нто* – чыгару сүзенең нигезе, *ак* – үткән заман һәм I зат берлекне белдерүче күрсәткеч. Сүзгә-сүз тәрҗемә иткәндә, “Мин пычак чыгардым” фикере килеп чыга. Бу күренеш кайбер Америка индеецлары, чукот, коряк телләре өчен характерлы.

## 5. Синтаксис. Төп синтаксик берәмлекләр

***Синтаксис*** җөмлә һәм сүзтезмәләрдә сүзләрнең бәйләнеш закончалыкларын, җөмлә төзелешен, җөмләләрнең синтаксик бөтенгә һәм текстка оешу принципларын өйрәнә. Шуларга бәйле рәвештә синтаксис өч өлешкә бүленә: сүзтезмә синтаксисы, җөмлә синтаксисы, текст синтаксисы.

Төп синтаксик берәмлекләр буларак *сүзтезмә* һәм *җөмлә* карала. Соңгы елларда синтаксик берәмлекләр рәтенә *синтагма, синтаксик бөтен, текст* кебек күренешләрне дә кертеп карый башладылар.

Синтаксиста сөйләм төзелеше сүзләр бәйләнеше аша өйрәнелә. Сөйләмдә сүзләр ике төрле бәйләнештә була. ***Тезүле бәйләнеш*** (паратаксис) вакытында, сүзләр үзара тигез хокуклы була, берсе икенчесенә буйсынмый. Тезүле бәйләнеш тезүче теркәгечләр (җыючы, каршы куючы, бүлүче) һәм интонация (санау, каршы кую) аша белдерелә. Тезүле бәйләнеш вакытында тиңдәш кисәкләр формалаша; тезмә кушма җөмләнең аерым компонентлары арасында да тезүле бәйләнеш урнаша. Әмма тезүле бәйләнеш үзе генә сөйләм барлыкка китерә алмый.

***Иярүле бәйләнеш*** (гипотаксис) булганда, бер сүз икенчесенә ияреп, буйсынып килә, анда сүзләр тигез хокуклы түгел: ал чәчәк, малай йөгерә, түгәрәк өстәл һ.б. Иярүле мөнәсәбәттә торган сүзләр арасында хәбәрлекле, ачыклаулы, аныклаулы мөнәсәбәтләр урнаша. *Хәбәрлекле мөнәсәбәт* вакытында бер сүз икенчесе турында ни дә булса хәбәр итә һәм җөмлә формалаша. *Ачыклаулы мөнәсәбәт*тә бер сүз икенчесен ачыклый, конкретлаштыра, бу вакытта сүзтезмә оеша.

*Аныклаулы мөнәсәбәт*тә торган сүзләрнең берсе икенчесен аныклый, өстәмә төгәллек кертә һәм бу вакытта аныклагыч дигән җөмлә кисәге барлыкка килә.

### *Сүзтезмәләр һәм аларны төркемләү*

Ким дигәндә ике мөстәкыйль мәгънәле сүзнең үзара ачыклаулы мөнәсәбәттә торып, бер төшенчә белдерүе ***сүзтезмә*** дип атала. Сүзтезмәләр берничә принциптан чыгып төркемләнәләр.

1. Компонентлар арасындагы мөнәсәбәтләрнең ирекле яки тотрыклы булуы ягыннан сүзтезмәләр *фразеологик* (тотрыклы) һәм *синтаксик* (ирекле) дигән төрләргә бүленәләр. Фразеологик сүзтезмәләр тел белеменең лексикология бүлегендә карала, ә ирекле сүзтезмәләр исә синтаксиста өйрәнелә.

2. Төзелеше ягыннан *гади* (ике мөстәкыйль сүздән гыйбарәт – матур чәчәк, тиз йөгерү, авылда яшәү һ.б.) һәм *катлаулы* (икедән артык мөстәкыйль сүздән тора – бер сәгатьтән кайту, ике чиләк су, бер тәлинкә аш һ.б.) сүзтезмәләр була.

3. Ияртүче һәм ияртүче сүзләр кайсы сүз төркеменнән булуга карап, *исемле исем* (авыл малае), *исемле фигыль* (урманнан кайту), *сыйфатлы исем* (ак чәчәкләр), *санлы исем* (өч кыз) һ.б. төр сүзтезмәләр була.

### *Җөмләләр һәм аларны төркемләү мәсьәләсе*

Җөмләгә тел белемендә дистәләрчә билгеләмә бирелгән, әмма аларның берсе дә барлык галимнәр тарафыннан кабул ителмәгән.

Һәр телдә җөмләләрнең төп билгеләре дип галимнәр *предикативлык һәм модальлекне* атыйлар. Предикативлык – чынбарлыктагы күренешләрне, вакыйга, билге һәм хисләрне хәбәр итү, ул заман, зат категорияләрендә чагылыш таба. Модальлек – сөйләмнең (сөйләүченең) чынбарлыкка мөнәсәбәте. Ул фигыль наклоненияләре, кисәкчәләр, ымлыклар, интонация, кабатлау, инверсия һ.б. аша белдерелә.

Җөмләләрне төркемләгәндә алда аталган аспектлар исәпкә алына һәм алар түбәндәге принциплар нигезендә төркемләнәләр:

1. Грамматик таркала алу-алмау ягыннан, *грамматик таркала* һәм *грамматик таркалмый торган җөмләләр* була: беренче төр җөмләләрдә җөмлә кисәкләрен (ия, хәбәр һ.б.) билгеләп була, икенчеләрендә җөмлә кисәкләргә аерылмый.

*2.* Чынбарлыкка белдерелгән мөнәсәбәтнең характеры ягыннан, *инкар* һәм *раслау* җөмләләр була.

*3.* Әйтү максаты ягыннан *хикәя, сорау, боеру* һәм *тойгылы* җөмләләр аерып карала.

*4.* Баш кисәкләр янында иярчен кисәкләрнең булу-булмавына карап, *җыйнак һәм җәенке* җөмләләр аерыла.

*5.* Хәбәрлек санына карап, җөмләләр *гади* һәм *кушма* була. Гади җөмләләр бер генә хәбәрлектән, кушмалары ике яки аннан артыграк хәбәрлектән тора.

*6.* Оештыручы үзәкнең санына карап, *бер составлы* һәм *ике составлы* җөмләләрне аералар. Бер составлы җөмләләрдә баш кисәкнең берсе генә була, икенчесен өстәп тә булмый; ә ике составлы җөмләләрдә ике баш кисәк тә кулланыла, яки икенчесен өстәргә мөмкин.

7. Мәгънә тулылыгы өчен кирәк булган кисәкләрнең кулланылу-кулланылмавына карап, *тулы* һәм *ким* җөмләләр аерылып тора. Ким җөмләләр аеруча җанлы сөйләм телендә, диалогларда кулланыла, ә тулы җөмләләр, гадәттә, фикер, текст, абзац башында очрый.

### 6. Җөмлә кисәкләре турында мәгълүмат.

### *Җөмләнең грамматик кисәкләре*

Җөмләдә сүзләр төрле грамматик роль үти. Җөмләнең структур үзәген тәшкил итә торган кисәкләре ***баш кисәкләр*** дип йөртелә. Аларга ия һәм хәбәр керә.

*Ия* – баш килештәге сүз белән бирелеп, хәбәрне үзенә ияртә торган абсолют бәйсез кисәк. Ул күп очракта исемнәр һәм исем мәгънәсендәге сүзләр белән белдерелә.

*Хәбәр* – җөмләнең ия турында хәбәр итә һәм аңа грамматик яктан буйсына торган баш кисәге. Хәбәрләр, нигездә, фигыль белән белдерелә (фигыль хәбәрләр). Фигыльдән башка сүз төркеме белән белдерелгән хәбәрләр (исем хәбәрләр) иядән аңлашылган әйбернең, төшенчәнең материалын, нинди дә булса бер билгесен белдерәләр.

Җөмләнең ***иярчен кисәкләре*** баш кисәкләрне ачыклап, җөмләне җәенкеләндереп киләләр, аларга аергыч, тәмамлык, хәл һәм аныклагыч керә. *Аергыч* – җөмләнең предмет төшенчәсен

белдергән кисәгенә ияреп, шул предметның билгесен, санын һәм кемгә (нәрсәгә) каравын аңлаткан кисәге. *Тәмамлык* җөмләнең процесс белдерә торган теләсә кайсы кисәгенә ияреп, процессның объектын, үтәүчене яки нинди дә булса бер хәл кичерүче затны (әйберне) һ.б. мәгънәләрне белдерә. *Хәл* җөмләнең фигыль, сыйфат, рәвеш һ.б. сүзләр белән белдерелгән кисәгенә ияреп, процессның яки билгенең билгесен, яисә процессның үтәлү рәвешен, вакытын, урынын, юнәлешен, максатын, сәбәбен, шартын, күләм-дәрәҗәсен белдерә. *Аныклагыч* – ияртүче кисәктән соң килеп, аңа өстәмә аныклык кертә торган кисәк.

Сөйләүченең чынбарлыкка, тыңлаучыга, җөмлә эчтәлегенә, төзелешенә мөнәсәбәтен белдерә торган кисәкләре җөмләнең ***модаль кисәкләре*** дип атала. Боларга эндәш һәм кереш сүзләр керә. *Эндәш сүзләр* сөйләм төбәлгән затны, әйберне белдерә. *Кереш сүзләр* сөйләүченең сөйләм эчтәлегенә, төзелешенә һәм сөйләм обстановкасына мөнәсәбәтен күрсәтәләр.

### ***Җөмләнең актуаль кисәкләре***

Җөмләдәге кайсы да булса бер кисәкнең мәгънә ягыннан аерымлануы актуаль кисәкләргә бүленешнең нигезен тәшкил итә. Аерымланган кисәк *рема* (сөйләм яңалыгы) дип атала, ул тыңлаучыга яңалык хәбәр итә. Җөмләнең бер өлеше тыңлаучыга таныш була һәм ул *тема* (сөйләм предметы) дип йөртелә. Мәсәлән, *Узган җәй коры килде* җөмләсендә *узган җәй* – тема, *коры килде* рема була. Шул рәвешчә, җөмлә, ничә сүздән торуына карамастан, ике актуаль кисәккә (тема һәм рема/ сөйләм предметы һәм сөйләм яңалыгы) бүленә. Актуаль кисәкләрнең кайсына да булса тәңгәл килә торган грамматик кисәк юк, алар теләсә кайсы грамматик кисәк белән туры килергә мөмкин. Составында сүзләр саны бердән артык булган һәркайсы җөмлә актуаль кисәкләргә бүленә. Җөмләдә сүзләр саны күбрәк булган саен, аның синтаксик төзелеше дә катлаулана бара.

#### **Белемнәрне тикшерү өчен сораулар**

1. Нәрсә ул морфема? Аларны ничек төркемлиләр?
2. Сүзьясалыш ысуллары турында сөйләгез.
3. Грамматик категория нәрсә ул?
4. Грамматик мәгънәләрне белдерүнең нинди юлларын беләсез?
5. Сүзләрне төркемләүдә нинди принциплар кулланыла?
6. Сөйләмдә сүзләр нинди бәйләнешләргә керә?
7. Сүзтезмәләрне ничек төркемлиләр?

8. Җөмләләрне төркемләү принципларын аңлатыгыз.
9. Җөмлә нинди  грамматик һәм актуаль кисәкләргә таркала?

## Тема: ЯЗУ. ГРАФИКА ҺӘМ ОРФОГРАФИЯ

1. Язу барлыкка килүнең алшартлары.
*2*. Сызма язуның төп тарихи этаплары.
3. Алфавит, графика һәм орфография.
4. Махсус язу системалары.

### 1. Язу барлыкка килүнең алшартлары.

Язу – кешелекнең иң бөек казанышларыннан берсе. Ул кешеләргә аваз теле ярдәмендә аралашу мөмкин булмаганда яки кыен очракларда кулланыла. Аваз телендә аралашу мөмкинлеге өчен иң беренче кыенлык – урын һәм вакыт. Ара ерагайган саен сөйләүченең тавышы ишетелми башлый. Язуның барлыкка килүен дә кешеләрнеңерактарак урнашкан кабиләләр белән аралашу ихтыяҗы һәм нәрсәне дә булса мәңгеләштерү теләге туган чорларга бәйләп аңлатырга мөмкин.

Иң әүвәл хәзерге язуларга бөтенләй охшамаган “юлламалар” барлыкка килгән булырга тиеш. Төрле әйберләрне, предметларны нинди дә булса мәгълүмат тапшыру максатларында куллану кешелек тарихының борынгы чорында киң таралган булгандыр. Аваз теленнән аермалы булган бу аралашу чарасын шартлы рәвештә *әйбер язуы* дип йөртәләр.

Мондый символик сигнализациядән тыш, шартлы сигнализация дә бар, анда исә “әйберләр” бернәрсә дә аңлатмый, шартлы тамга буларак кына кулланыла. Перу язуы *кипу* нәкъ шундыйлардан: төрле төстәге, төенле баулар бәйләнгән таякчыкны хат рәвешендә тапшырганнар. Ирокезларда төрле төстәге һәм төрле зурлыктагы кабырчыклар беркетелгән билбау да (*вампум)* хат итеп җибәрелгән. Гадәттә мондый хатларны аерым каста жрецлар гына укый алган. Бу ысул белән бик гади хәбәрләрне генә тапшырырга мөмкин булган.

Ә менә график тамгалардан гыйбарәт булган *сызма язу*ның мөмкинлекләре зуррак. Ул һәртөрле формасында һәм һәрбер үсеш этабында тел белән турыдан-туры бәйле: ул я тел формаларын чагылдыра, яки телгә бәйле булмаган өстәмә аралашу чарасы буларак кулланыла.

**2. Сызма язуның төп тарихи этаплары.**

Иң борынгы сызма язу ысулы палеолит чорында ук пәйда булган. Ул ***пиктографик язу*** атамасын алган (латинча *pictus* – ясау һәм грекча *grapho* – язу). Башкача аны *рәсем язуы* дип тә йөртәләр. Әлеге язудан кайбер Америка индеецлары бүгенге көндә дә файдалана. Дөрес, бу язу бик үк камил түгел, чөнки ясалган рәсемне төрле кеше төрлечә кабул итәргә мөмкин. Шунлыктан пиктографияне барлык галимнәр дә язуның беренче этабы дип санамыйлар. Шунысы да бар: борынгы кешеләр барлык ясалган әйберләрне дә тере, җанлы итеп кабул иткәннәр. Димәк, "рәсемле хикәятләр", бер яктан, шул гореф-гадәтләрне дәвам итсә, икенче яктан, сурәттән читләшүне, абстрактлашуны таләп иткән.

*Пиктография* – мәгълүматны рәсемнәр ярдәмендә тапшыру. Төрле конкрет предметлар сурәтләнгән рәсемнәрне билгеле бер тәртиптә урнаштырып, хуҗалык, иҗтимагый, хәрби һ.б. хәлләр турында мәгълүмат җиткерелә. Пиктография өчен алфавит таләп ителми, аны уку өчен рәсемнәрне дөрес аңлау да җитә.

Безнең эрага кадәр IV-III гасырларда Борынгы Шумерда, Борынгы Мисырда, аннары II гасырда Борынгы Кытайда икенче төрле язу барлыкка килә: һәр сүз я конкрет, я шартлы рәсем белән белдерелә башлый. Мәсәлән, *кул* турында сүз барганда кул рәсеме, *су*ны сурәтләгәндә дулкынлы сызык кулланылган. Өй, шәһәр, көймәләрнең һ.б. аерым символлары булган. Һәр тамга бер сүзне белдергәнлектән, аны *сүз язуы* дип атарга да була. Мондый мисыр рәсемнәрен греклар *иероглифлар* дип йөрткәннәр (*иеро* – изге, *глифы* – ташка уелган). Иероглифлар ярдәмендә төзелгән текстлар рәсемнәр сериясен хәтерләткән. Бу язуны икенче төрле "төшенчә язам" яки "идея язам" дип аңлатырга мөмкин. Әлеге язуның фәнни атамасы – ***идеографик язу*** да шуннан килеп чыккан. Тик бик күп иероглифларны истә калдырырга кирәк булган. Идеографик язу график формалар системасы булган, чөнки тамгалар эзлеклелеге сөйләмдә сүзләр тәртибен биргән.

Безнең эрага кадәр III гасырда ук шумерлар сөйләм авазларын график тамгалар белән бирүгә омтылыш ясаганнар, шуның белән ***фонографик (фонетик)*** *язу*га нигез салганнар. Гәрчә шумер язуы сүз язуыннан иҗек язуына күчү баскычында

торса да, анда сөйләмне график сурәтләүгә беренче адымнар эшләнгән. Шумерлар уйлап табып, соңыннан семитлар тарафыннан үстерелгән *иҗек язуы* кешелек цивилизациясенең тагын бер казанышы була. Язуны иҗекләр ярдәмендә тәртипкә салу табигыйрәк тоелган. Иҗекләрнең саны сүзләргә караганда әзрәк. Әмма бу карарга килгәнче берничә йөз еллар үткән. Иҗек язуы безнең эрага кадәр III-II гасырларда Урта диңгез ареалының көнчыгышында кулланылган. Хәзерге көндә бу язудан Һиндстанда, Эфиопиядә файдаланалар.

Язуны гадиләштерүдә алдагы этап *аваз язуы* була, анда сөйләмнең һәр авазына аерым тамга туры килә. Тик шундый гади һәм табигый юл уйлап табу өчен тагын да күбрәк вакыт таләп ителгән.

Аваз язуы тарихи яктан караганда яшьрәк халыкларда уйлап табыла, алар үзләреннән элек яшәп киткән кешеләрнең тәҗрибәсеннән гыйбрәт ала алганнар.

### 3. Алфавит, графика һәм орфография.

**Алфавит** – нинди дә булса фонемографик язуда кулланыла торган хәрефләрнең тарихи нигезләнгән тәртиптәге җыелмасы. *Алфавит* сүзе грек алфавитының беренче ике хәрефе исеменнән килеп чыккан – *альфа* һәм *бета* (яңа грек телендә *вита*). *Азбука* сүзе дә шул ук тәртиптә рус алфавитының беренче ике хәрефе атамасыннан ясалган – *аз+буки*. *Әлифба* сүзе гарәп алфавитының беренче ике хәрефе атамасыннан төзелгән – *әлиф+ба*.

Камил алфавитта бер хәреф бер авазны белдерергә һәм алфавитта телдәге фонемалар (авазлар) санынча хәреф булырга тиеш. Әмма язу тарихи рәвештә һәм күп еллар формалашканлыктан, язуда инде урнашкан гореф-гадәтләр, традицияләр дә чагылыш тапкан, шунлыктан идеаль алфавитлар юк, бары тик күпмедер дәрәҗәдә рациональ булганнары гына бар.

**Графика** – тел белеменең хәрефләрне язу, хәреф һәм аваз мөнәсәбәтләрен өйрәнә торган бүлеге. Теге яки бу алфавитта хәрефләрнең язылу үзенчәлекләрен күздә тоткан хәлдә, графика төрле телләрнең алфавитларын да атый. Ул, фән буларак, график язылышлары, форма үзенчәлекләре һәм авазларга мөнәсәбәтләре

буенча хәреф типларын өйрәнә. Гадәттә графика төшенчәсе аваз-хәреф язуына карата кулланыла.

Хәрефләр телдәге авазларга бер тел эчендә дә төрле нисбәттә торалар. Бер хәрефнең бер аваз (фонема) белдерүе – идеаль вариант. Әмма бу хәл бер генә милли алфавитта да юк, аларның һәркайсында хәрефләр саны белән фонемалар саны аерыла. Мәсәлән, инглиз телендәге 46 фонемага 26 хәреф бар, рус телендәге 33 хәреф 41 фонеманы белдерү өчен йөри. Шунлыктан һәрбер алфавитта авазлар һәм хәрефләр арасында төрле катлаулы мөнәсәбәтләр урнаша. Берничә хәреф бер фонема, яки киресенчә, бер хәреф берничә фонема белдерүдән тыш, кайбер алфавитларда билгеле бер фонемалар өчен юлдан аска һәм хәрефләр өстенә куела торган диакретик билгеләр кулланыла (татар телендә – ң, җ; поляк телендә – ą, чех телендә – ę,č,ž хәрефләре һ.б.).

**Орфография** – тел белеменең сүзләрне дөрес язу кагыйдәләрен өйрәнә торган тармагы. Төрле телләрдә кулланылышта булган кагыйдәләр берничә орфографик принципка барып тоташа. Бу принципларны билгеләүдә бердәм караш юк: берәүләр өч принцип (фонетик, морфологик һәм тарихи) билгеләсә, икенче берәүләр биш принцип (фонетик, морфематик, грамматик, дифференцияцияләнгән, традицион) күрсәтә, ә кайберәүләр исә алты принцип (фонематик, фонетик, этимологик, тарихи-традицион, морфологик һәм символик) булуын таный. Башка төрле бүленешләр дә бар. Өч орфографик принциптан (фонетик, морфологик һәм тарихи) торган классификация дөньядагы күп телләрне үз эченә ала.

### 4. Махсус язу системалары.

Махсус язу системалары профессиональ ихтыяҗларны канәгатьләндерәләр, аларга транскрипция, транслитерация һәм стенография керә.

Сөйләмнең аваз составын тулы итеп чагылдыру өчен кулланыла торган махсус язу системасын ***транскрипция*** дип атыйлар. Аваз берәмлекләренең нинди сыйфатын чагылдыруына карап *фонетик* һәм *фонематик транскрипция*ләрне аералар. Аларның икесе өчен дә фонетик алфавит – махсус тамгалар,

хәрефләр җыелмасы кирәк. Аеруча киң таралган фонетик алфавит – Халыкара фонетик ассоциациянең (МФА) латин алфавитына нигезләнгән алфавиты. Анда һәр авазның аерым билгесе бар. Рус һәм татар телләрендә күбрәк кириллицага нигезләнгән транскрипция кулланыла.

*Фонетик транскрипция*нең төп принцибы – кулланылган тамга белән транскрипцияләнә торган авазның тулысынча туры килүе. Бу вакытта һәр яңгыраган аваз транскрипция язмасында аерым теркәлеп барырга тиеш. Моның өчен теләсә кайсы фонетик алфавитка өстәмә билгеләр кертелә, аларны *диакретик билгеләр* дип йөртәләр.

*Фонематик транскрипция* сүзнең фонема яки морфема составын күрсәтә. Әгәр фонетик транскрипциядә фонемаларның һәр варианты чагылыш тапса, фонематик транскрипциядә бары төп төре генә бирелә. Фонематик транскрипциянең төп принцибы – һәр фонеманы позициясенә бәйсез рәвештә бер генә тамга белән күрсәтү. Ул шуңа күрә ул фонетик транскрипциядән гадирәк тоела. Әмма гомумкабул ителгән фонема теориясе юклыгын истә тотканда, аның фонеманы аңлауга бәйле икәнлеге күренә.

Тагын *гамәли (практик) транскрипция*не дә аерып билгелиләр. Ул чит тел сүзләренең әйтелешен милли алфавит чаралары белән теркәп куюдан гыйбарәт.

Практик транскрипция белән ***транслитерация*** тыгыз бәйләнгән, алар арасындагы чик һәрчак ачык булып күренеп тә тормый. Рус лингвистикасында кайвакыт чит тел сүзләрен рус графикасы ярдәмендә практик транскрипцияләүне транслитерация дип әйтәләр. Гадәттә транслитерация термины бер тел сүзләрен икенче телнең график чаралары белән бирү очрагында кулланыла. Ул алынма һәм калькалаштырылган сүзләрне язганда, бер телдән икенче телгә төрле ялгызлык исемнәрен – фамилияләр, газета, елга, шәһәр, ил һ.б. күчергәндә кирәк. Транслитерация нинди дә булса алфавитка нигезләнә һәм хәрефләрнең шартлы кулланылышына, диакретик тамгалар өстәлүгә юл куя.

***Стенография*** – җанлы сөйләмне теркәп баруны тизләтү өчен кулланыла торган махсус язу системасы. Стенографик язу тамгалары хәрефләрнең яки аларның элементларының

берникадәр үзгәргән вариантларыннан гыйбарәт. Алар шул дәрәҗәдә үзгәртелгән ки, язу процессын хәтта 4-7 тапкыр тизләтергә мөмкинлек бирәләр. Бу тамгалар тулаем сүз яки сүзтезмә мәгънәсен бирә торган идеограммалар, яисә иҗек яки иҗекләр тезмәсен аңлата торган силлабограммалар кебек кулланылалар.

Бүгенге көндә сөйләм яңгырашын техник теркәп бару чаралары күп булуга карамастан, стенографик күнекмәләр югары бәяләнә. Стенография төрле халыкара конференцияләрдә, югары дәрәҗәдәге очрашулар вакытында, хөкүмәт утырышларында, пресс-конференцияләрдә һ.б. кулланыла.

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар**

1. Язу барлыкка килүнең алшартлары дип нәрсәләрне атыйлар?
2. Әйбер язуының асылы нидән гыйбарәт?
3. Сызма язуның нинди этаплары булган?
4. Пиктографик, идеографик, фонологик язуларның төп билгеләрен тасвирлагыз.
5. Махсус язу системалары ни өчен уйлап табыла?

# ТЕЛ БЕЛЕМЕ ТЕРМИННАРЫНЫҢ АҢЛАТМАЛЫ СҮЗЛЕГЕ[13]

**Аваз** – сөйләмнең таркалмый торган иң гади фонетик берәмлеге; кешенең сөйләм аппараты эшчәнлеге, аерым алганда, тавыш ярыларының тирбәнеш нәтиҗәсе.

**Аваз артикуляциясе** – авазның әйтелеше. Аваз артикуляциясендә өч этап бар:

- *экскурсия* – сөйләм органнарының теге яки бу авазны әйтү өчен әзерлеге;

- *экспозиция* – сөйләм органнарының шушы авазны әйткәндә бер мизгелгә туктап калуы;

- *рекурсия* – сөйләм органнарының кире үз хәлләренә кайтуы.

**Аваз үзгәрешләре –** авазларның сөйләм агышында бер-берсенә тәэсир итеп үзгәрүләре.

***Позицион аваз үзгәрешләре*** – авазның сүздәге урынына, басымга бәйле рәвештә барлыкка килгән аваз үзгәрешләре. Төрләре:

- *апокопия* – сүзнең башында яисә ахырында авазлар төшеп калу;

- *протеза* – сүз алдына өстәмә авазлар килеп кушылу;

- *редукция* – авазның басымнан еракта торып кыскаруы һәм аерым очракларда төшеп калуы;

- *эпентеза* – сүз уртасына аваз өстәлү;

- *эпитеза* – сүз ахырына сузык аваз өстәлү.

***Комбинатор аваз үзгәрешләре*** **–** авазларның бер-берсенә тәэсир итешүе нәтиҗәсендә туган үзгәрешләр. Төрләре:

- *аккомодация* (җайлашу) – сузык һәм тартыклар әйтелешенең бер-берсенә җайлашуы;

- *ассимиляция* (охшашлану) – ике охшаш булмаган тартык авазның бер-берсенә тәэсир итүе нәтиҗәсендә бер төрле яки якын артикуляцияле, охшаш авазлар барлыкка килү;

- *диссимиляция* (охшашсызлану) – артикуляциясе буенча охшаш ике аваздан төрле авазлар барлыкка килү;

- *сингармонизм* – сузыклар ярашуы: сүзнең беренче иҗегендә (тамырда) нинди сузык аваз килсә, калган иҗекләрдәге, кушымчалардагы сузыклар да шул сузыкка ярашалар. Аның ике төрен аерып карыйлар: *рәт гармониясе* (сузыклар беренче иҗектәге сузыкка рәте буенча – калынлыкта-нечкәлектә ярашалар) һәм *ирен гармониясе* (беренче иҗектәге иренләшкән авазларга ярашып, калган иҗекләрдәге сузыклар да иренләшәләр);

– *диэреза* – аерым тартыклар әйтелмичә төшеп калу;

[13] Терминнар “Тел белеменә кереш” курсы күләмендә бирелә.

– *геминация* – тартыкның көчәйтелеп, ике тапкыр әйтелүе;

– *гаплология* – сүздәге бертөсле аваз яки иҗекнең берсе төшеп калу;

– *метатеза* – сүздәге авазларның урыннары алышыну;

– *аваз таркалу* – аваз әйтелешендәге төп хәрәкәтләрнең аерылып көчәюе нәтиҗәсендә яңа аваз барлыкка килү;

– *элизия* – ике сүз чигендә сузыклар очрашып, бу сүзләр бер басым астында әйтелгәндә (сандхи шартларында) барлыкка килә торган үзгәреш;

– *субституция* – чит авазны кабул иткәндә, аны туган телдәге аваз белән алыштыру;

- *авазлар чиратлашу* – бер морфема составындагы төрле авазларның теге яки бу кагыйдә нигезендә тәңгәлләшүе.

**Агглютинатив телләр** – агглютинация (кушымчаларның тамырга бер-бер артлы ялганып килүләре) күзәтелгән телләр (төрки, фин-угор һәм кайбер башка телләр).

**Актив сүзләр** – кешеләрнең көндәлек тормышында еш кулланыла торган сүзләр.

**Акцент** – туган телгә хас артикуляцион база үзенчәлекләренең икенче бер телдә сөйләгәндә чагылуы.

**Алфавит** – нинди дә булса фонемографик язуда кулланыла торган хәрефләрнең тарихи нигезләнгән тәртиптәге җыелмасы.

**Ареаль тел белеме** (ареаль лингвистика) – бер телнең төрле диалектларының яки бер-берсе белән чиктәш булган телләрнең территориаль бүленешен өйрәнә торган фән.

**Артикуляцион база** – сөйләм органнарының, теге яки бу авазларны әйтү өчен, типик торышлары җыелмасы.

**Артикуляция** – сөйләм органнарының авазларны әйткәндәге эшчәнлеге.

**Баба тел** – кардәш телләр төркеменең нәсел башы, ул телләрнең үсеш тарихында төрле кардәш телләргә таркала.

**Басым** – сөйләмнең бер кисәген башкаларыннан аерып кую өчен хезмәт итә торган суперсегмент элемент. Төрләре:

- *сүз (иҗек) басымы* – сүздәге бер иҗекне башкаларыннан аерылып торуы;

- *логик басым* – сөйләмдәге бер сүзнең аерылып торуы;

- *синтагма басымы* – сөйләмнең интонацион-мәгънәви берәмлекләренә төшкән басым.

**Гамәли тел белеме** – тел кулланылышына бәйле булган гамәли мәсьәләләрне чишү белән шөгыльләнә торган фән.

**Гомуми тел белеме** – кеше теле үзенчәлекләрен, телнең нигезен һәм табигатен, килеп чыгышын һәм үсешен өйрәнә, телне өйрәнү теориясен һәм методларын булдыру белән шөгыльләнә торган фән.

**Грамматик категория** – тулы бер сүзләр классына яки сүз тезмәләре классына хас булган һәм телдә формаль яктан белдерелгән универсаль семантик билге. Грамматик категория грамматик мәгънә һәм грамматик форма бердәмлегеннән гыйбарәт.

**Грамматик мәгънә –** предметлар һәм күренешләрнең төрле классларын һәм шулар арасындагы мөнәсәбәтләрне белдерә торган мәгънәләр. Грамматик мәгънәнең билгеләре: ул гомумиләштерә; мәҗбүри; бер төркемгә кергән сүзләрнең барысына да хас; грамматик мәгънәләрнең саны конкрет билгеле; грамматик мәгънәләр типиклашкан була: алар телдәге билгеле регуляр чаралар белән белдереләләр.

**Грамматик мәгънәләрне белдерә торган аналитик чаралар** – грамматик мәгънәләрне сүздән читтә тору юлы белән белдерә торган чаралар:

- *ярдәмлек сүзләр*. Алар атау функциясенә ия түгел, аларның мөстәкыйль мәгънәләре юк, мөстәкыйль мәгънәле сүзләр белән генә кулланылалар, үзләре генә җөмлә кисәге була алмыйлар. Ярдәмлекләргә теркәгечләр, бәйлекләр, кисәкчәләр, артикльләр, ярдәмче фигыльләр керә;
- *интонация* әйтү максаты буенча җөмлә төрләрен билгели. Бер үк җөмлә, нинди максат белән әйтелүенә карап, интонация ягыннан да аерыла. Интонациянең компонентлары җөмләдә төрле грамматик мәгънәләрне белдерүдә катнашалар;
- *сүз тәртибе.* Аффиксация аз булган телләр өчен сүз тәртибенең әһәмияте бик зур, чөнки сүзнең грамматик мәгънәсе аның җөмләдәге урынына карап үзгәрә;
- *инкорпорация*. Бу күренеш сүз белән җөмлә чигендә күзәтелә. Тәмамлык, фигыль составына килеп кереп, аның белән кушма сүз ясый; аергыч булганда, ул да шушы сүз чигеннән чыкмый.

**Грамматик мәгънәләрне белдерә торган синтетик чаралар** – грамматик мәгънәләрне сүз эчендә белдерә торган чаралар:

- *аффиксация* – грамматик мәгънәләрне (сүзләр арасындагы мөнәсәбәтләрне) кушымчалар ярдәмендә белдерү. Аффиксациянең ике төре бар: *агглютинация* (кушымчаларның тамырга бер-бер артлы ялганып килүләре) һәм *фузия* (флексиянең тамыр, нигез белән тыгыз берегүе, кушылуы);
- *басым* – күп телләрдә грамматик мәгънәне белдерә торган грамматик чара. Аерым телләрдә ул аффиксация белән бергә

кулланыла, әмма үзе генә дә грамматик форманың күрсәткече була ала, музыкаль басымның роле тагын да зуррак;

- *редупликация* **–** тамырның (нигезнең), тулысынча яисә өлешчә кабатланып, грамматик мәгънә белдерүе;

- *эчке флексия* – тамыр эчендә авазларның, законлы рәвештә үзгәреп, төрле грамматик мәгънәләр белдерү өчен кулланылышы;

- *супплетивизм* – бер үк лексик мәгънәгә ия булган сүзләрнең төрле грамматик формаларын төрле тамырдагы сүзләр белән белдерү;

- *аваз чиратлашулары* – морфемада авазларның төрле очракларда үзара алышынулары.

**Грамматик форма** – грамматик мәгънәнең телдә регуляр белдерелү чарасы.

**Грамматика** – телнең төзелешен, аның морфологик категорияләрен һәм формаларын, синтаксик категорияләре һәм төзелмәләре системасын өйрәнә торган фән. Ул сүзләрнең җөмләдә ярашу кагыйдәләреннән, шулай ук моңа бәйле рәвештә сүз формаларының үзгәреш кагыйдәләреннән гыйбарәт, ягъни бу фән тел элементларының систематикасын күздә тота. Грамматика ике өлештән – морфология һәм синтаксистан тора.

**Грамматология** – хәрефләрнең санын һәм формаларын, аларның авазларны белдерү өчен мөмкин булган тезмәләрен билгеләү белән шөгыльләнә торган фән.

**Графика** – тел белеменең хәрефләрне язу һәм уку кагыйдәләрен, хәреф һәм аваз мөнәсәбәтләрен өйрәнә торган бүлеге.

**Диалектология** – диалектларны, ягъни җирле сөйләшләрне, аларга хас тел үзенчәлекләрен өйрәнә торган фән.

**Диахрония** – телнең билгеле бер вакыт аралыгындагы үсешен күзәтү.

**Дидактика –** өйрәтү тәҗрибәсенә нигезләнгән һәм аны камилләштерү юлларын күздә тоткан дәреслек, әсбап, хрестоматия һәм башка уку-укыту материаллары рәвешендә укыту предметын барлыкка китерү белән шөгыльләнә торган фән.

**Дифференциация (дивергенция) –** телләр бүленү күренеше, бу вакытта бер телдә сөйләшүчеләр территория һәм иҗтимагый яктан таралып урнашалар, нәтиҗәдә кардәш телләр һәм диалектлар барлыкка килә. Дифференциация телләрнең саны артуга китерә.

**Җөмлә** – сөйләмнең фикерне, кичерешне һәм ихтыярны хәбәр итә һәм сөйләмнең чынбарлыкка мөнәсәбәтен белдерә торган төп берәмлеге.

**Җөмләнең актуаль кисәкләре.** Җөмләнең *тема* һәм *рема*га аерылуы сөйләмнең актуаль кисәкләргә бүленешен тәшкил итә. Сөйләмгә ничек килеп керү ягыннан һәр җөмлә ике өлешкә бүленә:

тыңлаучыга таныш өлеш (тема, сөйләм предметы) һәм тыңлаучы өчен яңалык алып килә торган өлеш (рема, сөйләм яңалыгы).

**Җөмләнең грамматик кисәкләре** – җөмләдә төрле грамматик роль үти торган кисәкләр: баш һәм иярчен кисәкләр.

***Җөмләнең баш кисәкләре*** – җөмләнең структур үзәген тәшкил итә торган кисәкләре:

- *ия* – баш килештәге сүз белән бирелеп, хәбәрне үзенә ияртә торган абсолют бәйсез кисәк.
- *хәбәр* – җөмләнең ия турында хәбәр итә һәм аңа грамматик яктан буйсына торган баш кисәге.

***Җөмләнең иярчен кисәкләре*** – җөмләнең баш кисәкләрен ачыклап, җөмләне җәенкеләндереп килгән кисәкләр:

- *аергыч* – җөмләнең предмет төшенчәсен белдергән кисәгенә ияреп, шул предметның билгесен, санын һәм кемгә (нәрсәгә) каравын аңлаткан кисәге.
- *тәмамлык* – җөмләнең процесс белдерә торган теләсә кайсы кисәгенә ияреп, процессның объектын, үтәүчене яки нинди дә булса бер хәл кичерүче затны (әйберне) һ.б. мәгънәләрне белдерә торган кисәге.
- *хәл* – җөмләнең фигыль, сыйфат, рәвеш һәм процесс белдерә торган башка сүзләр белән белдерелгән кисәгенә ияреп, процессның яки билгенең билгесен, яисә процессның үтәлү рәвешен, вакытын, урынын, юнәлешен, максатын, сәбәбен, шартын, күләм-дәрәҗәсен белдерә торган кисәге.
- *аныклагыч* – ияртүче кисәктән соң килеп, аңа өстәмә аныклык кертә торган кисәк.

***Җөмләнең модаль кисәкләре*** – сөйләүченең чынбарлыкка, тыңлаучыга, җөмлә эчтәлегенә, төзелешенә мөнәсәбәтен белдерә торган кисәкләре:

- *эндәш сүзләр* – сөйләм төбәлгән зат, әйбер.
- *кереш сүзләр* – сөйләүченең сөйләм эчтәлегенә, төзелешенә һәм сөйләм обстановкасына мөнәсәбәтен белдерә торган сүзләр.

**Җөмләләрне төркемләү.** Җөмләләр төрле принциплар нигезендә төркемләнәләр:

- грамматик таркала алу-алмау ягыннан: *грамматик таркала* һәм *грамматик таркалмый торган җөмләләр*;
- чынбарлыкка белдерелгән мөнәсәбәтнең характеры ягыннан: *инкар* һәм *раслау* җөмләләр;
- әйтү максаты ягыннан: *хикәя, сорау, боеру* һәм *тойгылы* җөмләләр;
- баш кисәкләр янында иярчен кисәкләрнең булу-булмавына карап: *җыйнак һәм җәенке* җөмләләр;

- хәбәрлек санына карап: җөмләләр *гади* һәм *кушма;*

- оештыручы үзәкнең санына карап: *бер составлы* һәм *ике составлы* җөмләләр;

- мәгънә тулылыгы өчен кирәк булган кисәкләрнең кулланылу-кулланылмавына карап: *тулы* һәм *ким* җөмләләр.

**Иҗек** – әйтелешнең иң кечкенә берәмлеге, ул сегмент һәм суперсегмент элементларның реальләшү урыны булып хезмәт итә. Иҗеккә бирелгән билгеләмәләр:

- *иҗек* – бер һава этәреше белән әйтелә торган аваз яки авазлар тезмәсе (мәктәп дәреслекләрендәге билгеләмә);

- *иҗек* – иң сонор һәм сонорлыгы кимрәк булган авазлар тезмәсе, авазлар чылбырының бер сонорлык түбәсе булган кисәге. Сонорлык түбәсе ничә булса, иҗекләр саны да шулкадәр була (сонорлык теориясе);

- *иҗек* – сөйләм аппаратының бер импульстагы мускул киеренкелеге белән әйтелә торган авазлар тезмәсе (мускул киеренкелеге теориясе);

- *иҗек* – тонның өзелүе яки аның активлыгы кимү нәтиҗәсендә ясалган монолит сөйләм кисәге (тональ теория).

***Төзелешләре буенча иҗек төрләре:***

- *ачык* иҗек – сузык авазга тәмамланган иҗек;

- *ябык* иҗек – тартык авазга беткән иҗек;

- *ярымачык иҗек* – сонор авазга беткән иҗек.

**Интеграль семиотик системалар** – җәмгыятьнең барлык әгъзалары да бердәй файдалана торган тамга системалары (тел, гореф-гадәтләр, уеннар һәм санау чаралары).

**Интеграция** (конвергенция) **–** телләр кушылу процессы, бу очракта телләр һәм диалектлар берләшә, нәтиҗәдә, телләр саны кими.

**Интерференция** – туган тел нормалары һәм системасы эшчәнлеге нәтиҗәсендә икенче тел системасы һәм нормаларының арттa калуы.

**Интонация** – телдәге суперсегмет чаралар җыелмасы. Интонациянең акустик компонентлары:

- *интенсивлык* (сөйләм органнарының киеренкелеге, сулап чыгаруның көче белән бәйле, ул сөйләмдәге иң әһәмиятле сүзләрне аерып чыгарырга ярдәм итә);

- *мелодика* (әйтү максаты буенча җөмлә төрләрен билгели);

- *озынлык* (сөйләм темпы);

- *пауза* (фразалар, синтагмалар арасындагы тукталыш);

- *тембр* (өстәмә төсмерләр исәбенә тавышның үзгәрүе, сөйләмнең характерлы бизәге);

- *темп* (аерым сүзләрнең һәм сүзтезмәләрнең билгеле бер вакыт аралыгында тиз һәм әкрен әйтелешләренең чиратлашуы).

**Искергән сүзләр** – предметлар, күренешләр югалу сәбәпле, актив кулланылыштан төшеп калган яки сирәк кулланыла торган сүзләр. Төрләре:

- *архаизмнар* – актив сүзлек составыннан синонимнары кысрыклаган сүзләр.

- *тарихи сүзләр* – хәзерге вакытта кулланылыштан, халыкның тормыш-көнкүрешеннән төшеп калган элеккеге чор әйбер-күренешләрен һәм төшенчәләрен аңлаткан сүзләр.

**Ияртүле бәйләнеш** (гипотаксис) – сүзләрнең берсе икенчесенә ияреп килүе. Ияртүле бәйләнештә торган сүзләр үзара өч төрле мөнәсәбәттә булалар:

- *хәбәрлекле мөнәсәбәт* булганда бер сүз икенчесе турында нәрсә дә булса хәбәр итә;

- *ачыклаулы мөнәсәбәт*тәге сүзләр берсе икенчесен ачыклап, төгәлләп, конкретлаштырып, башка шуңа охшашлы төшенчәләрдән аерып киләләр;

- *аныклаулы мөнәсәбәт* вакытында бер сүз икенчесен аныклап, аңа өстәмә төгәллек биреп килә.

**Каллиграфия** – язу тамгаларын (хәрефләрне) ачык, төгәл һәм матур язу турындагы фән.

**Лексика –** телдәге барлык сүзләр җыелмасы.

**Лексик мәгънә** – сүзнең эчтәлеге. Лексик мәгънәләренең типларын сүзнең а) кешене чолгап алган чынбарлыкка мөнәсәбәтенә; ә) кешенең фикеренә, хисләренә, теләкләренә мөнәсәбәттә; б) телдәге башка сүзләргә мөнәсәбәткә карап төркемлиләр.

**Лексикография** – сүзлекләр төзү теориясе һәм практикасы турындагы фән.

**Лексикология** – сүз турында өйрәтмә; лексиканы, аның үсешен һәм кулланылышын өйрәнә торган фән.

**Махсус семиотик системалар** – белгечләр тарафыннан эшкәртелгән, барлык кешеләр дә бердәй файдаланмый торган тамга системалары:

- *гамәли булмаган сәнгать системалары* (музыка, бию, сурәтләү-нәкыш);

- *гамәли сәнгать системалары* (костюм, дизайн, архитектура);

- *идарә системалары* (ориентирлар, сигналлар, командалар һ.б.).

- *прогноз системалары* (сынамышлар, күрәзәчелек, багу);

**Методика** – педагогка ничек эшләргә, аңлату алымнарын һәм методларын ничек сайларга икәнлекне өйрәтә торган фән.

**Морфема –** сүзнең мәгънәгә ия булган иң кечкенә кисәге (тел берәмлеге). Морфеманың төп билгеләре: морфема ике яклы була: ул аваз ягыннан формалашкан һәм мәгънәгә ия; морфема тагын ваграк кисәкләргә бүленә алмый; морфемалар яңадан ясалмыйлар, бәлки тел хәтереннән алыналар; алар мөстәкыйль яши алмыйлар: сүз составына кереп, төрле мәгънә белдереп яшиләр. Төрләре:

- белдергән мәгънәләренә карап, *төп, деривацион* һәм *реляцион морфемалар* була. Төп мәгънә сүзнең тамырында белдерә. Деривацион морфемалар тамырны ачыклап, конкретлаштырып килә, мөстәкыйль кулланылмый. Реляцион морфемалар сүзнең башка сүзләргә мөнәсәбәтен белдерә;

- сүз төзелешендәге урыны ягыннан (тамырга бәйле рәвештә), *префикслар* (алкушымча – тамыр алдында йөриләр), *суффикслар* (тамырдан соң киләләр), *постфикслар* (флексиядән соң урнашалар), *конфикслар* (циркумфлексләр – тамырны чолгап алалар); *инфикслар* (аффикслар эченә кереп урнашалар), *интерфикслар* (кушма сүзләрне берләштерәләр), *трансфикслар* (тартыктан торган тамырларны аерым сузыклар белән аералар) аерып карала;

- морфеманың сүздә мәҗбүри булуы яисә мәҗбүри булмавы ягыннан, *тамыр* (һәр сүздә була) һәм *аффиксаль* (факультатив булалар) морфемалар була;

- килеп чыгышлары ягыннан караганда морфемалар *телнең үзенеке* һәм *башка телдән алынган* булуы ихтимал.

**Морфемика** – тел белеменең морфемалар системасын һәм аларның сүзләр составында яшәеш кагыйдәләрен өйрәнү белән шөгыльләнә торган тармагы.

**Морфология** сүз формаларын һәм алар белдергән мәгънәләрне, грамматик сүз классларын (сүз төркемнәрен), аларга хас грамматик категорияләрне өйрәнә.

**Неологизмнар** – кулланучы буын хәтерендә туган яңа сүзләр һәм мәгънәләр.

**Ономастика –** ялгызлык исемнәре — исемнәр, кушаматлар, отчестволар һ.б. тарихын тикшерә торган фән.

**Орфография** – дөрес язу нормалары һәм кагыйдәләре җыелмасы. Төп орфографик принциплар:

- *фонетик принцип* – сүзне ишетелгәнчә язу;
- *морфологик принцип* – язганда сүздәге морфемаларның бөтенлеген саклау;
- *тарихи-традицион принцип* – сүзнең элеккеге язылышын саклап язу;

- *график принцип* – алынма сүзләрне чыганак телдәгечә язу, бу язуы бер булган телләр өчен аеруча әһәмиятле.

**Орфоэпия** – дөрес әйтелеш кагыйдәләре нормаларының җыелмасы. Орфоэпия – дөрес һәм матур сөйләү турындагы фән.

**Пассив сүзләр** – кешеләрнең көндәлек тормышында сирәк кулланыла торган сүзләр.

**Праформалар** – телләрнең чагыштырмалы-тарихи метод ярдәмендә торгызылган охшаш сүзләре һәм сүз формалары, аларның беренчел рәвешләре.

**Проклиза** – алдагы басымсыз сүзнең үзеннән соң килгән басымлы сүз белән бергә әйтелүе.

**Семасиология** – сүзләрнең мәгънәсен, мәгънәләр үсешен, үзгәрешен өйрәнә торган тармак.

**Семиотика** – кеше тарафыннан кулланыла торган төрле тамга (знак) системаларын, аларның төрләрен, төзелешен, тамгаларның гомуми сыйфатларын, шулай ук киноның, рәсем сәнгате, әдәбият һәм кеше мәдәниятенең башка төрләренең тамга (знак) функцияләрен өйрәнә торган фән.

**Симптом** – әйберләрнең күзәтелә һәм теркәлә торган сыйфаты, асылы. Мәсәлән, үлчәм, авырлык һ.б. кебек. Симптомнар – нинди дә булса мәгълүматны тапшыру өчен максатчан рәвештә файдаланылмый торган билгеләр.

**Сингармоник параллельләр** – этимологик яктан бер тамырга кайтып кала торган калын һәм нечкә әйтелешле сүзләр.

**Синтагма** – сөйләмнең интонацион- мәгънәви берәмлеге.

**Синтаксис** – җөмлә һәм сүзтезмәләрдә сүзләрнең бәйләнеш закончалыкларын, җөмлә төзелешен, җөмләләрнең синтаксик бөтенгә һәм текстка оешу принципларын өйрәнә торган фән.

**Синхрония** – текстлардагы тел материалын билгеле бер тарихи халәтендә бирелгәнчә гомумиләштерү.

**Система** – үзара бәйләнештәге элементлардан гыйбарәт булган бөтен бер объект.

**Сөйләм** – аралашу ысулы, телнең хәрәкәттәге формасы, телнең кулланылышы. Аралашу чарасы булган тел нәрсәдән торса, сөйләмдә шул (телнең төрле берәмлекләре һәм аларның бәйләнеш кагыйдәләре) чагыла. Аның төрләре: телдән сөйләм, әйтмә сөйләм, әйтмә-язма сөйләм.

***Телдән сөйләм*** – ишетеп кабул итүгә нигезләнгән сөйләм. Формалары:

- *фольклор* (бу текстларында мәңгелек хакыйкать, алар яттан күп тапкырлар кабатлауны күздә тота: экиятләр, мәкальләр, халык җырлары, мәсәлләр, тизәйткечләр һ.б.);

- *имеш-мимешләр* (текст чылбыр буенча кешедән-кешегә тапшырыла);

- *диалог* (ике яки берничә кешенең үзара аралашуы, аларда алдагы эш-гамәлләр турында фикерләр салына. Бу текстлар кабатланмый, алар диалогта катнашучыларга гына мәгълүм була);

- *ораторика* (билгеле бер аудиториягә юнәлгән сөйләм, ул аерым темага багышланмый, бер генә тапкыр сөйләнә. Ул өч төрле була: *судтагы сөйләм* – анда һәрвакыт үткәндәге хәлләр тикшерелә; *күрсәтмә чыгыш* – киресенчә, үткән киләчәк белән бәйләп бирелгән сөйләм; *фикер алышу* – күпчелек очракта киләчәккә юнәлтелә);

- *гомилетика* (оратор күп тапкырлар бер үк аудитория каршында бер зур тема буенча чыгыш ясагандагы сөйләм. Шулай ук өч төре бар: *нәсыйхәт* (вәгазь) – булган белемнәрне искә төшерү, яңарту һәм ныгытуга юнәлтелә; *уку-укыту сөйләме* – тыңлаучыларга яңа белемнәр алып килә; *пропаганда* – агымдагы конкрет вакыйгаларга багышлана).

***Язма сөйләм*** – күреп кабул итүгә нигезләнгән сөйләм. Формалары:

- *эпиграфика* (бу текстларда язу текстлары язу материалы булмаган әйберләргә (таш плитәләр, металл әйберләр, балчык эшләнмәләр һ.б.) төшерелә);

- *сфрагистика* (шәхси ышанмаклык тамгаларының – документларга куела торган мөһерләрнең һәм штампларның бер өлеше);

- *нумизматика* (язма текстлар бәһа тамгалары һәм регалияләрнең бер компоненты. Болар – акча тамгаларындагы, медаль, жетоннардагы һ.б. язулар);

- *палеография* (язу кораллары белән язу материалларында башкарылган һәртөрле язулар. Язу ысулларына бәйләп, аларны *хатлар* (эпистоллар), *документ* һәм *әдәби иҗат әсәрләре*нә бүлеп карыйлар);

- *неография* (басылган һәм тиражланган текстларга әйтәләр. Боларга шул ук документлар, хатлар һәм әдәби иҗат әсәрләре керә).

***Әйтмә-язма сөйләм (массакүләм коммуникация)*** – яңа көчле техник чаралар (күбәйтү аппаратлары, аваз яздыру җайланмалары, телевидение, радио, кино, компьютер) ярдәмендә ясала һәм таратыла торган сөйләм. Формалары:

- *массакүләм мәгълүмат* (зур күләмдәге кулланучыны, ягъни киң җәмәгатьчелекне күздә тоткан һәм агымдагы яңалыкларны хәбәр итә торган сөйләм. Мондый сөйләмне кино, телевидение, радио, газета-журналлар һ.б. иҗат итә);

- *реклама* (массакүләм мәгълүматның үзенчәлекле бер төре. Анда кулланучыга төрле товарлар, хезмәт төрләре һ.б. турында информация бирелә һәм бу әйберләргә карата сорау, ихтыяҗ тудыру максаты белән эшләнә);

- *информатика* (электрон чаралар ярдәмендә фактларны, белемнәрне гомумиләштерү формаларын һәм ысулларын җәелдерүне күздә тоткан сөйләм төре).

**Сөйләм авазларын өйрәнү аспектлары -** сөйләм авазларын төрле яклап өйрәнүне күздә тоткан юнәлешләр:

- *акустик аспект* – авазның физик табигатен, яңгыраш ягын өйрәнү. Физик яктан һәрбер сөйләм авазы югарылыгы, көче, тембры һәм озынлыгы белән аерылып тора;

- *биологик аспект* **–** сөйләм авазларын ишетелеш ягыннан, билгеле бер органнарның катнашуына мөнәсәбәттә өйрәнү;

- *иҗтимагый (иҗтимагый, социаль, фонологик, лингвистик) аспект* – сөйләм авазын мәгънәгә бәйле рәвештә өйрәнү;

- *фонетик аспект* **–** акустик һәм биологик аспектны берләштереп, шулай атыйлар.

**Сөйләм аппараты** – кешенең сөйләм барлыкка китерә торган органнар җыелмасы. Сөйләм аппаратының өлешләре: сулыш аппараты (диафрагма, үпкәләр, бронхлар, сулыш юлы (трахея); бугаз (тавыш ярылары һәм кимерчәкләр); бугаздан өске өлеш (йоткылык, авыз һәм борын куышлыгы).

**Сөйләм әдәбе** – сөйләмдә тел элементларын урынлы куллану, телнең сүзлек байлыгыннан һәм грамматикадан дөрес файдалану турындагы фән.

**Стенография** – җанлы сөйләмне теркәп баруны тизләтү өчен кулланыла торган махсус язу системасы.

**Сүз** – телнең лексик мәгънәләр һәм төрле мөнәсәбәтләр белдерә торган төп берәмлеге. Сүзнең төп билгеләре:

- сүз фонетик яктан формалашкан була: сүз башы, сүз азагы закончалыгы, фонемаларның үзенчәлекле тезмәләре, бер басымга ия булу, бөтенлек;

- грамматик яктан сүз чагыштырмача бөтен һәм бер формага ия (сүз тегe яки бу сүз төркеменә карый);

- лексик яктан һәр сүз билгеле бер мәгънәгә ия;

- сүзгә атау (номинатив) функциясе хас;

- сүз телдә яңадан туып тормый, ул телдә һәрвакыт яшәп, сөйләм вакытында калкып чыга.

**Сүзләрне төркемләү принциплары:**

- *лексик-грамматик принцип* – сүзләрне төркемнәргә аерганда гомумиләштерелгән уртак төп грамматик мәгънәгә игътибар итүне күздә тота;

- *морфологик принцип* – уртак морфологик билгеләргә карап төркемләү;

- *синтаксик принцип* – сүзләрнең җөмләдәге типик синтаксик функциясенә, аларның башка сүзләр белән бәйләнешкә керү үзенчәлекләренә игътибар итеп төркемләү.

**Сүзтезмә** – кимендә ике мөстәкыйль мәгънәле сүзнең ачыклаулы мөнәсәбәткә кереп, бер төшенчә белдерүе. Сүзтезмәдәге сүзләр арасында берничә төрле мөнәсәбәт урнаша:

- *атрибутив мөнәсәбәтләр* вакытында ияргүче сүз ияртүче сүзнең берәр билгесен, сыйфатын ачыклый;

- *релятив сүзтезмәләрдә* ияргүче сүз фигыль белән белдерелгән ияртүче сүзнең билгесен белдерә;

- *объект мөнәсәбәте* булганда, ияргүче сүз ияртүче сүзнең объектын белдерә.

**Сүз төркемнәре** – уртак грамматик мәгънәләре, бердәй морфологик билгеләре һәм типик синтаксик функцияләре нигезендә берләшкән сүз класслары.

***Мөстәкыйль сүз төркемнәре*** – атау функциясен башкара торган, мөстәкыйль лексик мәгънәләре булган һәм җөмлә кисәге булып килә ала торган сүзләр.

***Ярдәмлек сүз төркемнәре*** – атау функциясен башкармыйча, бары мөстәкыйль сүзләргә өстәмә мәгънәләр бирү, аларны бер-берсенә бәйләү яки модаль мәгънәләр белдерү өчен хезмәт итә торган сүзләр.

***Модаль сүз төркемнәре*** – сөйләүченең сөйләмгә булган мөнәсәбәтен белдерә торган сүзләр, аларның бер төрлесе җөмләдә кереш сүз булып йөри, икенчеләре хәбәр функциясендә килә яисә хәбәрлекнең үзәген тәшкил итә.

**Сүзьясалышы –** тел белеменең ясалма сүзләрне, аларның ясалу ысулларын һәм төзелешен өйрәнә торган тармагы.

**Тамга** – икенче бер күренешләрне, предметларны белдерә, алыштыра ала торган матди предметлар.

**Тезүле бәйләнеш** (паратаксис) – үзара тигез хокуклы сүзләрнең берсе икенчесенә буйсынмыйча бәйләнүләре.

**Текст** – сөйләмнең мәгънәви, логик, коммуникатив, структур-грамматик, интонацион яктан оешкан иң зур берәмлеге. Төрләре:

- *макротекст* – тәгалләнгән, тәмамланган, кыскарак бер әсәр, мәкалә, хикәя, әсәрләрнең аерым бүлекләре һәм бүлекчәләре, параграфлары, гариза, беркетмә, белешмә, мәзәк, шигырь һ.б.;

- *микротекст* – бер теманы үз эченә алган берничә мөстәкыйль җөмлә, абзац, берничә абзац һ.б.

**Тел –** фикерләр, хисләр, теләкләр белдерә торган фонетик, лексик, грамматик чаралар җыелмасы; кешеләрнең иң мөһим аралашу чарасы; иҗтимагый күренеш. Тел билгеле бер коллективның иҗат җимеше һәм

тарихи күренеш. Ул билгеле бер вакыт аралыгындагы барлык сөйләш һәм диалектларны, телдән һәм язма сөйләм формаларын берләштерә.

**Тел белеме** – телләрне (шул исәптән аерым кеше телен дә, һәм, гомумән, кайчандыр яшәгән, хәзерге һәм кайчан да булса барлыкка килергә мөмкин булган телләрне дә) өйрәнә торган фән.

**Тел берәмлекләре** – кабатлана ала торган, тел системасында чагыштырмача даими билгеләре белән аерыла алган, яисә турыдан-туры сөйләм актларында телдә кабул ителгән кагыйдә һәм модельләр буенча ясала торган элементлар. Тел системасын һәм структурасын оештырудагы урынына һәм роленә карап тел берәмлекләрен ике класска аерып карыйлар:

- *конститутив берәмлекләр* (КБ) – тел системасындагы төп берәмлекләр, аларны кабатлап, санап була, аларга формаль (матди-идеаль) күрсәткечләр хас, тел системасында даими статуска ия. Болар – фонема, морфема, сүз формалары, сүз, сүзтезмә, җөмләләр;

- *конститутив булмаган берәмлекләр* (КББ) – кайберләре телдә кабул ителгән кагыйдә һәм модельләр буенча сөйләм барышында ясала (фонетик сүз, синтагма, җөмлә кисәкләре һ.б.), икенчеләре теге яки бу КБнең элементы була (иҗек, интонация, басым төрләре һ.б.); өченчеләре КБ базасында ясала, теркәлә, санала, КБгә хас булган аерым функцияләрне башкара һәм шуның белән КБгә якын килә торган берәмлекләр (фразеологизмнар, аббревиатуралар һ.б.).

**Тел гаиләсе** – бөтен кардәш телләрне үзенә җыйган телләр берләшмәсе.

**Телләрне төркемләү** – дөнья телләрен билгеле бер уртак сыйфатлары буенча бүлү. Телләрне төркемләгәндә кулланыла торган принциплар:

- *генеалогик принцип* телләрне кардәшлегенә, бер уртак телдән килеп чыгуларына нигезләп төркемләүне күздә тота;

- *типологик* яки *структур-типологик принцип* нигезендә телләрнең эчке төзелешләрендәге охшашлыклар ята;

- *ареаль принцип* дөньяда телләрнең һәм тел күренешләренең таралыш ареалларын өйрәнүне күздә тота;

- *функциональ принцип* телләрнең үтәгән мәдәни һәм иҗтимагый функцияләрен барлаудан гыйбарәт.

**Телләрнең ареаль классификациясе** – дөнья телләре картасын, аерым телләрнең һәм телләр төркеменең таралыш ареалларын төзүне күздә тоткан классификация. Бу классификация мөстәкыйль булса да, генеалогик һәм типологик классификацияләр арасында тора. Ул генеалогик классификация эчендә дә, төрле генетик чыганаклы телләр өчен дә эшләнә ала. Ареаль классификациядә контактлы күренешләр

белән бәйле билгеләр әһәмияткә ия. Бер тел эчендә ареаль классификация телнең диалектларына бәйләп башкарыла.

**Телләрнең генеалогик классификациясе –** телләрнең тарихи кардәшлегенә нигезләнгән классификация. Дөнья телләрен кардәшлек буенча төркемләү теге яки бу телләрнең бер телдән килеп чыгуын өйрәнә. Генеалогик классификацияләр күпсанлы, аларның күпчелегендә искә алынган тел гаиләләре: ***һинд-европа, семит-хәмит (афразия), кавказ, дравид, урал, алтай, чукот-камчатка, нигер-кордофан, нил-сахара, койсан, кытай-тибет, тай, австро-азиат, австронезия, эскимос-алеут телләре гаиләләре.***

**Телләрнең лингвистик классификациясе** – телләрнең структур һәм функциональ үзлекләрен үзара генетик мөнәсәбәтләренең характерына бәйсез рәвештә чагыштырып өйрәнү. Типологик чагыштырулар тел системаларының морфологик, синтаксик, фонологик дәрәҗәләрендә уздырыла.

- *телләрнең морфологик (типологик) классификациясе* – телләрне грамматик формаларны белдерүче чараларга нисбәтле төркемләү. Бу яктан телләр түбәндәге типларга бүленә: флектив телләр, агглютинатив телләр, изоляцияләнгән яки аморф телләр, инкорпорпорацияләнгән яки полисинтетик телләр.

- *синтаксик классификация* – телләрдәге сүз тәртибе, бәйлекләр арасында бәйләнешләрне һ.б синтаксик күренешләрне чагыштыруга нисбәтле тикшеренүләрдән гыйбарәт.

- *фонологик (фонетик) классификация* телләрнең фонемалар системасы төзелешендә, системада һәм текстта сузык һәм тартыкларның күләм мөнәсәбәтендә, иҗек структурасында, суперсегмент (просодик) берәмлекләрдә охшашлык һәм аермалыкларны эзләү белән шөгыльләнә.

**Телләрнең функциональ классификациясе** (иҗтимагый-функциональ, социологик) **–** дөнья телләрен тел һәм җәмгыятькә мөнәсәбәтле күп кенә даими һәм үзгәрүчән факторларны (бу телләрдә сөйләшүче халыкларның саны, таралыш ареаллары, иҗтимагый функцияләре, үз дәүләтендәге һәм аннан читтә абруе һ.б.) исәпкә алып төркемләү.

**Телнең структур яруслары** (дәрәҗәләре, катламнары, баскычлары) – телнең төп структур оешу компонентлары. Телнең *фонетик-фонологик, морфемик-морфологик, лексик-семантик* һәм *синтаксик яруслары* аерып карала.

**Тел семиотикасы** – телдән һәм язма сөйләмдә тел мәгънәсен чагылдыру ысулларын, яңа тамгаларының барлыкка килү тенденцияләрен өйрәнә торган фән.

**Телнең килеп чыгышы турында теорияләр** – беренче кеше теленең барлыкка килүен аңлата торган гипотезалар.

***Биологик теорияләр*** – телнең килеп чыгышын кеше организмының (ис сизү, тәм тою органнарының, сөйләм аппаратының) эволюциясе белән аңлата торган теорияләр:

- *аваз ияртемнәре теориясе (ономато-поэтик теория*). Бу теориягә фәлсәфәдә стоиклар нигез сала. Аның асылы: борынгы кеше, табигатьтәге авазларга охшатып, төрле авазлар чыгарган. Шул рәвешле аваз ияртемнәре барлыкка килгән;

- *ымлыклар теориясе.* Бу теория борынгы Грециядә стоикларга каршы лагерь – эпикурчылардан ук килә. Асылы: борынгы кешеләрнең иң беренче авазлары ымлыклар, рефлекслар булган. Беренче сүзләр шатлыкны, куркуны, ачлыкны һ.б. хисләрне белдергәннәр. Шулар тора бара табигый авазларга әйләнеп, җәмгыятьтәге һәр кеше өчен уртак символик мәгънәләрдә йөри башлаганнар;

- *балалар теле теориясе.* Бу теория XIX йөздә тарала. Аның тарафдарлары телнең барлыкка килүен балалар теленә бәйләп карыйлар. Төрле халык балаларының телләре бер үк авазларны әйтеп ачыла (*мама, папа, баба, няня, деда* һ.б.). Соңга таба гына балаларның аңсыз әйткән бу сүзләре, теге яки бу тел мохите тәэсире белән, билгеле бер мәгънәле авазлар комплексына әверелә башлый.

***Иҗтимагый теорияләр*** – телнең барлыкка килүен кешенең аң үсеше һәм хезмәттә туган иҗтимагый ихтыяҗлар белән бәйләп карый торган теорияләр:

- *иҗтимагый договор (килешү) теориясе.* Асылы: тел кешеләр тарафыннан аңлы рәвештә иҗат ителгән, булдырылган;

- *хезмәт тавышлары (кычкырыклары) теориясе.* Бу теория буенча фикерләү һәм эш бер-берсеннән аерылгысыз булган; кешеләр, хезмәт кораллары ясый башлаганчы, табигый предметларның башка объектларга тәэсирен сынап караганннар. Бергә эшләгәндә чыккан тавышлар хезмәтне җиңеләйткәннәр һәм оештырганнар. Башта ирексездән әйтелгән бу тавышлар әкренләп хезмәт процессының символына әйләнеп киткәннәр. Беренче тел фигыль тамырларыннан гыйбарәт булган;

- *ымнар теле (кинетик) теориясе*. Бу теория тарафдарлары телне ымнардан барлыкка килгән дип исәплиләр: кеше ымнар белән аралашканда ук, кинетик сөйләм булган, аннан соң инде аваз теле барлыкка килгән.

**Телнең үз сүзләре** – сүзлек составында бик борынгыдан, нигез телдән килә торган һәм телнең үз материалы җирлегендә ясалган сүзләр.

**Телнең функцияләре** – тел чараларының потенциаль үзенчәлекләрен сөйләмдә төрле максатларда куллану.

***Телнең иҗтимагый функцияләре:***

- *коммуникатив функция* – телнең кешеләр аралашуына, фикер алышуларына хезмәт итүен белдерә торган функциясе;
- *аккумулятив функция* – телнең иҗтимагый тәҗрибә һәм белемнәр туплау чарасы, матди һәм рухи мәдәният формалаштыру һәм үстерү коралы булуын күрсәтә торган функциясе;
- *когнитив функция* – телнең эчтәлекне белдерү, тапшыру һәм саклау функциясе. Ул әйләнә-тирәдәге предмет һәм күренешләрне атауда, аларга бәя бирү мөмкинлегендә чагылыш таба.

***Телнең эчке төзелеш функцияләре*** – телнең асылын һәм табигатен чагылдыра торган функцияләре, ягъни билгеле бер эчтәлекне, мәгънәне тел формалары белән белдерү.

- *фикер формалаштыру функциясе* – телнең фикерләрне формалаштыру һәм белдерү чарасы булып хезмәт итүе;
- *номинатив функция* – телнең чынбарлыктагы күренешләрне атау функциясе;
- *метател функциясе* – телнең үзен тасвирлау өчен хезмәт итүе.

***Телнең өстәмә*** (икенчел) ***функцияләре*** – сөйләмдә төрлечә чагыла һәм күбрәк телгә түгел, ә сөйләмгә карый торган функцияләр, алар телнең төп функцияләренә бәйле булалар һәм бер-берсенә тәэсир итәләр. Болар:

- *апеллятив функция* – нинди дә булса эш-гамәлләргә чакыру, өндәү функциясе һ.б.;
- *биологик функция;*
- *волюнтив функция* – ихтыярны тапшыру функциясе;
- *индикатор (күрсәткеч) функциясе* – билгеле бер төркем кешеләргә караганлыкны белдерү функциясе;
- *интеррогатив* – сорау функциясе;
- *корпоратив функция* – телнең кешеләрне төркемнәргә, сыйныфларга берләштерү функциясе;
- *магик функция* (боларга ырымнар, каргыгышлар, ант, ялвару, өшкерү һ.б. керә);
- *раслау (констатацияләү) функциясе* – нинди дә булса факт турында “битараф” хәбәр итү функциясе;
- *регулятив функция* – кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне тәртипкә салу функциясе;
- *фатик функция – контакт урнаштыру* функциясе;
- *экспрессив (эмотив) функция* – сөйләүченең кәефен һәм хисләрен чагылдыру функциясе;

- *эстетик функция* – тел ярдәмендә шәхескә эстетик тәэсир итү функциясе (әдәбият, театр, кино һ.б.);

- *эстетик функция* – телнең үз формасы белән тәэсир итү функциясе;

- *этник функция* – телнең халыкны берләштерә, милли үзаң формалаштырырга ярдәм итү функциясе;

**Терминология** – һәр фәннең терминнар җыелмасы, шул терминнарны өйрәнә торган фән.

**Типологик тел белеме** (телләр типологиясе) – дөньяда билгеле булган барлык тел системаларын өйрәнә торган фән.

**Топонимика** – ялгызлык характердагы географик атамаларны (авыл, шәһәр, елга, күл һ.б.) өйрәнә торган фән;

**Топономастика –** лексикологиянең ономастика һәм топонимиканы берләштергән тармагы. Үз эчендә *зоонимика* (хайван атамалары), *космонимика* (күк җисемнәре исемнәре), *гидронимика* (сулык исемнәре) һ.б. тармакларга аерыла.

**Транскрипция** – телнең аваз составын төгәл бирү өчен фәнни максатларда кулланыла торган махсус язу. Төрләре:

- *фонетик транскрипция* авазларны, аларның төп вариантларын чагылдыра; аның төп принцибы – кулланылган тамга белән транскрипцияләнә торган авазның тулысынча туры килүе;

- *фонематик транскрипция* фонемаларны чагылдыра, аның төп принцибы – һәр фонеманы позициясенә бәйсез рәвештә бер генә тамга белән күрсәтү.

**Транслитерация** – бер алфавиттагы сүзне икенче алфавитка күчергәндә кулланыла торган язу төре.

**Тышкы лингвистика** – тел һәм җәмгыять бәйләнеше проблемалары, телнең җәмгыятьтәге функцияләре, телләрнең территориаль таралышы, халыкның теле һәм мәдәнияте мөнәсәбәтләре һ.б. бик күп проблемалар белән шөгыльләнә. Бу атама астына бик күп фәннәр берләшә: социолингвистика, лингвогеография, этнолингвистика, психолингвистика һ.б.

**Фикерләү** – уйлау һәм фикер йөртү сәләте. Төрләре:

**-** *вербаль фикерләү* – телдә ныгыган формаларда бирелә, тышкы һәм эчке сөйләм процессында тормышка ашырыла торган фикерләү формасы; ул сүзләрдә теркәлгән төшенчәләр, хөкем, фикри нәтиҗәләргә таяна, анализлый һәм гомумиләштерә, гипотезалар һәм теорияләр кора;

- *вербаль булмаган фикерләү* – чынбарлык тәэсирләрен кабул итү нәтиҗәсендә туган, хәтердә саклау һәм күзаллау ярдәмендә яңадан барлыкка китерелгән хисси-күрсәтмә образлар ярдәмендә тормышка ашырыла торган фикерләү формасы.

**Филологик сүзлекләр (лексиконнар)** – сүз, аның мәгънә үзенчәлекләрен, лексик-грамматик һ.б. сыйфатларын ачыклауны күздә тоткан сүзлекләр. Төрләре:

- *бер тел сүзлекләре* – сүз турында шушы телдә аңлатма бирелә;

- *ике тел (тәрҗемәле) сүзлекләре* – сүзнең мәгънәсе икенче телдәге сүз белән бирелә;

- *берничә тел (күптелле) сүзлекләре* – сүз берничә тел сүзләре белән янәшә куела.

**Филологик фәннәр** – телнең кулланылышын һәм үсешен тулаем тикшерү, аның үсеш-яшәешенә шартлар тудыру белән шөгыльләнә торган фәннәр. Аларны гамәли, норматив, фундаменталь (нигез) фәннәргә аерып йөртәләр:

- *гамәли филологик фәннәр* турыдан-туры кеше эшчәнлеге белән бәйле, аларның һәркайсы аерым бер төр текст булуны таләп итәләр. Болар: каллиграфия, орфоэпия, эш кәгазьләре башкару, архив эше, китапчылык белеме, телләргә өйрәтү методикасы һәм дидактикасы, тел семиотикасы, мәгълүмат хезмәте күрсәтү һ.б.

- *норматив филологик фәннәр* телдән һәм язма сөйләмнең дөрес нормаларын билгелиләр, алар җәмгыятьтә кулланылышта йөргән барлык төр текстларны күздә тоталар. Болар: фонетика, грамматология, орфография, грамматика, лексикология, лексикография, риторика, поэтика, сөйләм әдәбе һ.б.

- *фундаменталь филологик фәннәр* турыдан-туры практикага барып тоташмыйлар, әмма аңа булышалар: фундаменталь тикшеренүләр норматив кагыйдәләрнең эшләнеше өчен база барлыкка китерәләр. Болар: чагыштырма тел белеме, чагыштырма-тарихи тел белеме, телләр типологиясе, әдәбият теориясе, диалектология, әдәбият тарихы, тел тарихы, әдәби тел тарихы, матур әдәбият теле тарихы һ.б.

**Флектив телләр** – фузия күренеше (тамыр белән флексиянең бик нык берегүе) күзәтелгән телләр (һинд-европа, семит телләре).

**Фонема** – телнең морфемаларын, сүзләрен һәм сүз формаларын аера торган, сөйләм агышында дифференциаль билгеләрен җуймаслык итеп үзгәрә ала торган иң кечкенә аваз берәмлеге.

**Фонетика** – телнең аваз ягын, авазлар составын һәм аваз тезмәләрен, аларның үзгәрешен өйрәнә торган тармагы.

**Фонетик сүз** – сөйләм тактының бер басым белән әйтелгән кисәге.

**Фонология** – телнең фонемаларын билгеләү, аларны система итеп оештыру принципларын, сөйләм агышында аларның үзара мөнәсәбәтләрен ачыклау белән шөгыльләнә торган фән. Төрләре:

- *сегмент фонология* сөйләмдә бер-бер артлы килә торган берәмлекләрне (фонема, иҗек) өйрәнә.

- *суперсегмент* (супрасегмент) *фонология* просодик чараларны (тон, иҗек акценты, басым, интонация) тикшерә.

**Фраза** – яңгырашы ягыннан тәмамланган бер хәбәр. Алар бер-берсеннән тавышның төшүе, пауза белән аерылып торалар.

**Фразеология** – тел белеменең телдә бер төшенчә белдерү өчен катып калган тотрыклы сүзтезмәләрне өйрәнә торган тармагы.

**Хосусый тел белеме** – аерым (мәсәлән, рус, инглиз, немец, татар теле һ.б.), яисә кардәш телләрне (славян, төрки телләр һ.б.) өйрәнү белән шөгыльләнә торган фән. Хосусый тел белеме *тасвири (синхроник)* булырга, ягъни тел фактларын теге яки бу тел тарихындагы конкрет бер чорга бәйле рәвештә тасвирларга мөмкин (күп очракта – бүгенге телләр), яисә *тарихи (диахроник)* була ала. Диахроник тел белемен еш кына чагыштырма-тарихи тел белеме белән тәңгәлләштереп карыйлар.

**Чагыштырма тел белеме** – грамматик тасвирламаларда һәм текстларда бирелгән ике (һәм күбрәк) телне чагыштырып өйрәнә торган фән.

**Чагыштырма-тарихи тел белеме** (компаративистика) – телләр арасындагы матди охшашлык билгеләрен ачыклау һәм тел үсеше проблемалары белән шөгыльләнә торган фән. Ул, тугандаш телләрне үзара чагыштырып, аларның тарихи үткәнен өйрәнә.

**Энклиза** – басымлы сүзнең үзеннән соң килгән басымсыз сүз белән бергә әйтелүе.

**Энциклопедик сүзлекләр** – төшенчәләргә аңлатма бирүә, алар турындагы карашлар, гипотезалар, фикер каршылыкларын чагылдыра торган сүзлекләр. Төрләре: *универсаль* (җәмгыять тормышы һәм фәннең төрле тармакларыннан системага салынган мәгълүматлар бирелә) һәм *махсус* (аерым өлкәләр буенча мәгълүмат туплана) энциклопедияләр.

**Этимология** – сүзләрнең тарихын, килеп чыгышын өйрәнә торган фән.

**Эчке лингвистика** – тел системасын һәм төзелешен мөстәкыйль күренеш буларак өйрәнә торган фән. Аның үз эчендә мөстәкыйль фәннәрне аерып чыгарырга мөмкин: фонетика һәм фонология, лексикология һәм семасиология, морфология һәм синтаксис, сүзьясалышы.

**Эчке сөйләм** – кешенең сүзләрне үзалдына уйлаганда да куллануы. Эчке сөйләм вакытында сөйләм органнары эшләп тора, ләкин кычкырып сөйләгәндәге кебек киеренке хәлдә булмыйлар.

## ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

Алефиренко Н.Ф. Теория языка. Вводный курс: учебное пособие для студ. филол. спец. высш. учеб. заведений. – 4-е изд., стер. – М.: Издательский центр «Академия», 2010 (2). – 384 с.

Арутюнова Н.Д. Язык и мир человека. – М.: Языки рус. культуры, 1999. – 896 с.

Белая Г.В., Симонов К.И. Введение в языкознание: учебное пособие. – М.: ТЕЗАУРУС, 2010. – 304 с.

Будагов Р.А. Введение в науку о языке. – М.: Добросвет-2000, 2002. – 544 с.

Гируцкий А.А. Введение в языкознание. – Минск: ТетраСистемс, 2005. – 288 с.

Гречко В.А. Теория языкознания. – М.: «Высшая школа», 2003. – 375 с.

Җамалетдинов Р.Р., Нурмөхәммәтова Р.С. Тел белеме нигезләре. – Казан: Ихлас, 2014. – 240 б.

Замалетдинов Р.Р. Теоретические и прикладные аспекты татарской лингвокультурологии. – Казань: Магариф, 2009. – 351 с.

Кодухов В.И. Ведение в языкознание. – М.: Просвещение, 1987. – 288 с.

Куликова И.С., Салмина Д.В. Введение в языкознание: учебник для бакалавров. – М.: Юрайт, 2013. – 699 с.

Леонтьев А.А. Путешествие по карте языков мира. – М.: Изд. Дом Мещерякова, 2008. – 344 с.

Лингвистический энциклопедический словарь / Гл. ред. В.Н.Ярцева. – 2-е изд., дополненное. – М.: Большая Российская энциклопедия, 2002. – 709 с.

Маслов Ю.С. Введение в языкознание. – М.: ACADEMIA, 2005. – 304 с.

Мечковская Н.Б. Общее языкознание: Структурная и социальная типология языков: Учеб. пособ. – М.: Флинта; Наука, 2001. – 312 с.

Немченко В.Н. Введение в языкознание: учебник для вузов. – 2-е изд., перераб. И доп. – М.: Юрайт, 2013. – 679 с.

Нурмөхәммәтова Р.С. Тел белеменә кереш (теоретик материаллар, тел турында кызыклы мәгълүматлар). – Казан: Ихлас, 2010. – 160 б.

Реформатский А.А. Введение в языкознание. – М.: Аспект Пресс, 2004. – 536 с.

Рождественский Ю.В., Блинов А.В. Введение в языкознание. – М.: ACADEMIA, 2005. – 943 с.

Сафиуллина Ф.С. Тел гыйлеменә кереш. – Казан: Хәтер, 2001. – 383 б.

Сафиуллина Ф.С., Сәлимов Х.Х., Сәлимова Д.Ә. Тел гыйлеменә кереш. – Казан: 2000. – 126 б.

Сусов И. П. Введение в языкознание. – М.: Восток-Запад, 2006. – 382 с.

***Интернет-ресурслар***

www.gramota.ru – Грамота.ру

www.gumer.info – Библиотека Гумер – гуманитарные науки

www.ksu.ru – Электронная библиотека и материалы сайта КПФУ

www.slovari.ru – Электронные словари

www.wikipedia.ru – Универсальная энциклопедия «Википедия»

www.myshared.ru/slide/203434/ Языки мира и языковые ареалы

## ЭЧТӘЛЕК


**Кереш** ........................................................................................................ 3

**Тел турындагы фән буларак тел белеме, аның башка фәннәр белән бәйләнеше**

Филологик фәннәр системасында тел белеменең урыны............... 4

Тел белемен тәшкил итүче фәннәр турында мәгълүмат.................. 5

Тел белеменең аспектлары............................................................. 7

Тел белеменең башка фәннәр белән бәйләнеше............................. 9

**Телнең табигате, асылы һәм функцияләре**

Тел һәм җәмгыять.......................................................................... 14

Тел – тамгалар (знаклар) системасы.............................................. 16

Телнең функцияләре...................................................................... 20

Тел һәм фикерләү.......................................................................... 22

Тел һәм сөйләм.............................................................................. 23

**Телнең килеп чыгышы. Телләрнең тарихи үсеше**

Телнең барлыкка килүе.................................................................. 26

Телләрнең килеп чыгуы турында теорияләр.................................. 26

Телнең килеп чыгуына карата хәзерге фәндәге карашлар.............. 29

Телләр үсешендә төп процесслар.................................................. 31

Төрле тарихи чорларда телләрнең һәм диалектларның үсеше......... 33

**Дөньядагы телләр һәм аларны төркемләү принциплары**

Дөньядагы телләр һәм аларны төркемләү...................................... 36

Телләрне төркемләү принциплары……………………………….. 37

Телләрнең генеалогик классификациясе........................................ 38

Тел гаиләләре................................................................................. 39

Телләр типологик классификациясе............................................... 47

Телләрнең ареаль классификациясе.............................................. 51

Телләрнең функциональ классификациясе.................................... 52

**Тел системасы һәм аның структурасы**

Система һәм структура төшенчәләре.............................................. 54

Тел системасы һәм структурасы…………………………………….. 55

Телнең структур берәмлекләре………………………………………. 56

Телнең структур яруслары…………………………………………… 56

**Телнең фонетик төзелеше**

Фонетика һәм фонология турында төшенчә.................................. 58

Сөйләм авазларын өйрәнү аспектлары.......................................... 59

Сөйләмдә аваз үзгәрешләре........................................................... 64

Сөйләмнең фонетик кисәкләре....................................................... 66

Басым һәм интонация.................................................................... 68

**Телнең сүзлек составы**

Лексикология фәне һәм аның тармаклары..................................... 70

Сүз турында төшенчә…………………………………………………….. 72

Лексик мәгънәләрнең типлары....................................................... 73

Телнең сүзлек составы турында мәгълүмат………………………… 75

Әдәби телнең сүзлек байлыгын тулыландыру юллары……………. 76

**Телнең грамматик төзелеше**
Морфемика. Морфема һәм аларны төркемләү................................. 77
Сүз ясалышы һәм аның төп берәмлекләре………………………….. 80
Морфология, аның өйрәнү объекты............................................... 82
Грамматик категория. Грамматик мәгънә. Грамматик форма......... 83
Синтаксис. Төп синтаксик берәмлекләр........................................ 88
Җөмлә кисәкләре турында мәгълүмат........................................... 90
**Язу. Графика һәм орфография**
Язу барлыкка килүнең алшартлары................................................. 92
Сызма язуның төп тарихи этаплары………………………………… 93
Алфавит, графика һәм орфография………………………………….. 94
Махсус язу системалары……………………………………………... 95
**Тел белеме терминнарының аңлатмалы сүзлеге**……………………… 98
**Әдәбият исемлеге**............................................................................. 117

*Уку басмасы*

**Нурмөхәммәтова** Раушания Сагдатзяновна

# ТЕЛ БЕЛЕМЕНӘ КЕРЕШ

**Уку-укыту ярдәмлеге**

Басарга кул куелды 04.12.2019.
Офсет кәгазе. Цифрлы басма.
Форматы 60х84 1/16. Гарнитурасы «Times New Roman».
Шарт. бас. таб. 6,98. Шарт. нәшр. таб. 5,61.
Тиражы 100 данә. Заказы 58/12

Әзер оригинал-макеттан Казан университеты нәшрияты
типографиясендә басылды

420008, Казан, профессор Нужин ур., 1/37
тел. (843) 233-73-59, 233-73-28